Бикә Рәхимова

**Бакый сагыш: мәкаләләр**

Казан
Татарстан китап нәшрияты
2009

Шагыйрә Бикә Рәхимованың әлеге китабына публицистик мәкаләләре туплап бирелде. Татар халкының тарихи, милли, мәдәни, дини, икътисади, сәяси һәм мәгариф мәсьәләләрен күтәреп чыккан мәкаләләр укытучыларга, студентларга, гомумән, киң катлам китап укучылар өчен дә кызыклы булыр.

ISBN 978-5-298-01824-1
© Татарстан китап нәшрияты, 2009
© Рәхимова Б.Р., 2009

## БЕР КОЯШЫМ МИНЕМ, БЕР АЕМ

*(Журналист Гөлнара Җәлилованың*
*шагыйрә Бикә Рәхимова белән әңгәмәсе)*

Әй шигърият, рәнҗетәмен,
Рәнҗетәмен мин сине,
Күңелемдә күк рәсеме,
Телләремдә –
Дөньялыкның ясине, –

дип кешелеккә дәшкән шагыйрә күңелен аңларга мөмкин дә түгел кебек. Шул ук вакытта кызык та. Аңлыйсы килә. Каршылыклы, иҗтимагый-фәлсәфи һәм дә дөньяви шигъряттә Бикә Рәхимова кебек кыю сүзләләр сирәк бит. «Мәрхәмәт», «Иделләр Казанында», «Ачыл, күңел!», «Сәрвиназ», балалар өчен «Урман радиосы», «Кырмыскалар өендә» җыентыклары аша ул укучыга яхшы таныш. Публицист һәм тәрҗемәче буларак та билгеле Бикә Рәхимова шигъриятен укыганда үзеннән-үзе: «Кирәк микән хатын-кыз өчен мондый авыр камыт кию?»– дип уйлап куясың. Ил-көн, милләт язмышын ничек тә булса аңлау, аңлау гына түгел, җиңеләйтергә, ничек тә көйләргә тырышып яшәүче шагыйрә белән күрешеп сөйләшү теләге әллә кайчан туса да, форсаты да, җае да чыкмый торды. Күрешкәч, алдан «төзеп» куйган портрет-сурәт артык үзгәрмәде. Төптән уйлап, фикерен ашыкмыйча әйтә торган ханым-шагыйрә тормышта да шулай икән. Аның үз фикере, үз сүзе, үз кыйбласы бар:

Өләшкәндәй итәм мин дә
Хатын-кыз акылымны.
Дөнья уңаенамы ул,
Әллә соң аркылымы? –

дигән шигырь юллары аша ук күңел аны тоемлап алган иде. Ялгышмаган икәнмен.

– *Язучылык авыр хезмәт бит ул,* – диде Бикә апа, сүзне әнә шул алда телгә алган татар шигъриятенә бәйләп. – *Чөнки тормышта пычрак күп. Хәзер безгә шундый заман килде, бүгенге шигърият халыкны ияртеп бара алмый. Җитмеш процентка якын халык шигъриятькә мохтаҗ түгел. Тукайга ул яктан җиңелрәк булган. Аңа халык үзе ярдәм иткән, ул вакыттагы татарның туксан тугыз проценты чын татар булып яшәгән, хәзерге безнең хәлләр белән якынрак китереп тә чагыштырып булмый.*

*Ул чорда да аптыраш булган, билгеле. Татар кадими юл белән генә барса, таш гасырда утырып калуыңны көт тә тор. Ә менә җәдитчелек юлы белән киткәч, урысча уку-сөйләшүгә барып терәлдек. Советның җиңә алуы да шул җәдитчелекнең нәтиҗәсе бит. Кадими татарлар ул инкыйлабка кушылмаслар иде. Әмма монда да бер «ләкин» бар. Мөселман халыкларын көч белән алырлар иде. Бигрәк тә дәүләте булмаган хәлдә.*

Шагыйрәнең тарихтагы үсеш-үзгәреш, хата-абынуларга үз карашы бар. Ул – сәясәтче-фәлсәфәче буларак та белемле, зыялы зат.

– Татарның иң зур хатасы нинди дип уйлыйсыз?

– *Безнең иң зур бәлабез – маңкорт дип аталган исемне йөртүчеләребезнең һәр заманда да күп булуында. Электән үк шулай булган. Алар җае чыкканда турыдан-туры үз халкына каршы көрәшә. Безнең халыкның бик күп төрле уңай сыйфатлары булуга карамастан, башкага хезмәт итү – куштанлану гадәте (менә мин бу хәлне чын маңкортлык дип исәплим дә, ягъни үз мәнфәгатеңне, үз халкыңны оныту) бар. Менә бер кечкенә генә мисал. Бүгенге көндә дә Борск дигән бер шәһәрдә торгызылып, яшәп ятучы монастырьны гына алыйк. Аны Алтын Урда чорында ук татар бае салдырган икән. Мондый гыйбрәтле хәлләрне күп китереп булыр иде.*

Бикә апаның шигъриятендә дә ул ачынып сөйләгән «яралар» төп урыннарның берсен били дисәм, ялгышмам кебек. Асылда, беркайчан да мескен булмаган татар милләте аның җанын җәрәхәтле яра кебек әрнетә. Үз «милли исеме» өчен көрәштә дә аны хатын-кыз җенесеннәндер дип уйлый алмыйсың.

Татар! Татар!.. Әй, татар...
Татардан да килештереп
Ат ялына кем ятар?!

*(«Яңгыравык исемебез»)*

кебек шигырь юллары дисеңме, әллә инде:

...Бар ул безгә дигән ирек –
Арыслан авызында.
Аны алганда канар шул
Борының, авызың да, –

*(«Безгә дигән ирек»)*

кебек киң җилкәле, нык бәдәнле ир-атларча әйтелгән фикерен аласыңмы, Бикә ханым Рәхимова иҗатында кабатлану юк. Кабатлану дигәнем фикер һәм кыюлык үлчәвендәге авырлыкны күздә тотып әйтүем.

– Татар шигъриятенә тәнкыйть җитенкерәмәве инде проблемага әйләнеп бара. Фикерегез?

*– Безнең һәрберебезнең шигъриятендә җыйнаксызлык китте. Бу хәленнән килгән кеше чыгарган китапларда гына түгел, кызганыч, исемле авторларда да күзәтелә. Әмма мин моны бүгенге көннең агышыннан чыгадыр дип уйлыйм. Тәнкыйтьчеләр совет заманында хакимияткә һәм берничә авторга хезмәт иттеләр. Ә бүгенге тәнкыйтьчеләргә яңача эшләп китү читенрәк, күрәсең...*

– Татар китабы язмышына килгәндә, аңа ихтыяҗ бар дип уйлыйсызмы, тараламы ул?

*– Монда артык сүз куертып та булмый кебек. Чөнки мәсьәлә ачык бит. Үзеңнең дәүләтең булса, шаулап мәктәпләрең, югары уку йортларың эшләп торса, татар китабын алмый нәрсә алсын татар?*

*Цензура бетте дигәч тә, татар язучылары хакимияткә матди бәйле булып яши. Бу исә әсәрнең сыйфатын яхшыртуга хезмәт итмәскә мөмкин.*

*Безгә китап тарату эшендә бөтенебез бергә тырышырга кирәк. Мин нәшриятта эшләгәндә, «КамАЗ»га татар китабын төяп, Казан урамнарында «иң яхшы», «иң кызыклы», «иң арзан» дип кычкырып рекламалап китап сатып йөргән идек. Төялгән китапның яртысы бер көндә сатылып бетә иде. Шул ук «КамАЗ» машиналарына китап төяп, Уфаларга, Ижауга кадәр барып җитә идек. Шартлары нинди, шулай итеп эшләргә кирәк инде.*

– Үзегезгә нинди исем бирер идегез, шигърияттә сезнең урыныгыз нинди дип уйлыйсыз?

*– Мин үземне әллә кемгә санамыйм. Мин бары тик ирекле кеше. Әмма үзен ирекле тойган кешенең сүзе халыкка барып ирешсә, ниндидер бер нәтиҗә, алгарыш булмасмы дип хыялланып була төсле. Үземчә, халыкка бер генә кирәкмәгән сүз дә әйтмим кебек тоела. Аннан тагын бер нәрсә бар ич әле. Дөньяда барлык низаглар да «мин әллә кем»лектән башлана. Аерым шәхесләр арасындамы ул, төрле дәүләтләр арасындамы – барысы да үзеңне генә зурга куюдан башлана. Әдәбият – әдәп тәрбияләү дигәнне онытмаска һәрбер язучының ... хакы да, бурычы да бар. Бер кояшым минем, бер аем дип яшәүләргә ни җитә?!*

Бикә ханымның тыйнаклыгы ошады – күпләр «мин – шагыйрь» дип күкрәк какканда, шапырынмыйча да шагыйрә булып яшәргә мөмкин икән бит. Сибгат ага Хәким сүзләре белән башланган шигырен генә алсак та, шагыйрәнең татар шигъриятендәге үз сүзе ачык чагыла:

«Казан әле, Казан уянмаган»,
Уянмаган безгә дигәне.
Сафа Гәрәй, Сөембикәләрнең
Рухы белән яшим дигәне.

*(«Уяныйрлар»)*

– Сезнең беренче шигырегез әни, укытучы, песи кебек темага багышланмагандыр, моның киресенә ышана да алмыйм...

*– Беренчесе «Усак» дип аталган мәсәл иде. Мин шул вакытта ук (сигезенче сыйныфта) иҗтимагый юнәлеш тотканмын, хәзер дә мин шушы юлда калдым. Балаларга язганда да мин иң беренче чиратта алар күңеленә иҗтимагый-милли орлык салырга омтылам. Мәсәлән, мәзәк итеп язылган «Әкәм-төкәм» шигырен генә алыйк. «Үземнекен үз итәм, Өем күтәреп йөртәм.» Бу – турыдан-туры олыларның да колагына ирешсен дип язылган шигырь. Без бер генә нәрсәне дә кемнән дә булса көтеп ятмаска, барысын да үзебез хәл итәргә тиешбез. Суверенлык бетә дип сөйләшә башлауга, татарлар, хәтта татар язучылары үзләренең балаларын, оныкларын татар мәктәбеннән алып, шыбыр-шыбыр урыснызына күчерүләрен мин оятсызлык дип саныйм. Кем тия сиңа, нәрсә тия, әкрен генә үз балаңны татар мәктәбендә укытып ят. Татар мәктәпләре ябыла, дисәләр дә, балаңны укырга биргәндә гаризаңны барыбер татар классына-сыйныфына бирәм дип яз. (Мәктәпне яба алмаячаклар.) Соңыннан, балам эчкече, наркоман, тагын әллә нәрсәләр дип баш авырттырмассың. Кеше төсле кеше тәрбияләү беренче максат түгелмени?*

*Татарның башы гаҗәеп куәтле акыл туплаган. Бүгенге көндә интернет, кампитрга дөньякүләм кирәкле, кызыклы программалар эшләп ятучылар да татар егетләре икән. Әле берсе белән күптән түгел генә «Азатлык» радиосы таныштырды. Шытырдатып татарча сөйли, авылда татар мәктәбен тәмамлаган да... замана фәненең иң күренекле бер белгече булып киткән.*

– Бикә апа, алай да, нилектән безнең халыкның проблемалары да чыгып тора соң?

*– Безнең халкыбызның, бик күп күркәм сыйфатлары белән бергә, холкында кайвакыт шул күркәмлекне боза торган яклар да бар. Гафу, бер мизгеллек җиңү өчен бер-берсе белән үлгәнче талашырга, бер-берсен сатарга да мөмкин. Ходай сакласын! Күлтәгин язмаларындагыча. «Мин күпме халыкларны җайлы урнаштырдым, әмма үз кавемемнең күпмесе сатылып, алданып һәлак булды», – диелгән. Димәк, беренчедән, хан үз халкын башка халыкка караганда азрак караган, икенчедән, үз халкы да аумакай булган. Кызганыч, бүгенге төрки-татарда шул хәл дәвам итә... Безне беркайчан да, беркем дә җиңмәгән, без үзебезне-үзебез «җиңгәнбез». Казан алыну хәлләрен генә искә төшерик...*

... Кайткан саен үз итәләр
кырлар –

Кырларыбыз безнең – үзәннәр.
Үзәнлектә яши киңлекләрнең
Түбәнлегенә дә түзгәннәр.

*(«Үзәнлекләр»)*

Әлбәттә, Бикә апа җанындагы тынгысызлык, яну иҗтимагый борчулар белән генә бәйле түгел. Анда хатын-кыз кичерешләре дә, фәлсәфәлек тә шактый урын били. Монда да Бикә Рәхимованың үзенчәлекле һәм каршылыклы холкын тоясың. Бер карашка аңлашылмас кебек күренгән шигырь юллары эченә ул олы бер дөнья «салган».

Сүзләреңнең тозын тоймак булам,
Төбен айкый-айкый, аптырап...
Янып сөйсәң дә син, сөймәгәндәй,
Бимазала мине, аптырат...

*(«Риза»)*

шигырен аласыңмы, әллә инде:

Баш бирмисең миңа, кирәкми дә,
Үз башың баш, минем –
Үземнең.
Рәхмәтләрем сиңа хәттин ашкан,
Син барыбер үзе түземнең, –

*(«Чын мәхәббәт»)*

кебек юлларны укыйсыңмы – шагыйрә хатын-кызга гына хас (бәлки, татар хатын-кызларына дисәң, дөресрәк буладыр) серлелек, бер сүзгә мең төрле мәгънә салу осталыгын күрәсең.

Күзәнәкләр тетри – таумы-ташмы,
Тау-таш тетрәгәндәй – куркыныч...
Ләкин үз-үземне тота беләм,
Үтәли күр, кара – мин тыныч.

*(«Тынычмын»)*

Тетрәтә, уйландыра, бимазалый торган шигърияте, шагыйрәгә бәя биреп, әнә шулай дәшә. Тау-таш ишелеп, дөнья актарылганда да үз сүзендә тора, үз-үзен кулда тота белүче корычтай холык шигърияткә күчкән.

Бикә апага: «Нигә авыр юлны сайладыгыз, иркә һәм акылсызрак хатын-кыз булып яшәү җиңелрәк булыр иде бит?» – дигән соравымны бирәм. Ә ул: *«Әгәр дә безнең халыкның үз дәүләте, үз патшасы, үз ханы булса, мин, бәлки, шул мәхәббәтне генә җырлап утырыр идем. Яисә бер мәхәббәтле ир хатыны гына булып яшәр идем. Мин аны да булдырам кебек»,* – дип җавап бирде. Артыгын әйтмәде. Аның җавабы шигърияте кебек җыйнак, кыска, төгәл иде.

*2006*

# 1. Биеклеккә чакыру

**БАКЫР ТЫШЛЫ, КӨМЕШ ТЫШЛЫ...**

Шушы елның март ахырында Татарстан Язучылар берлеге яшь талантларны барлау, аларның иҗатына бәя бирү максатыннан семинар үткәрде. Профессиональ оешмабыз, «Талант үзенә юл таба ул» гыйбарәсенә генә ышанып тормыйча, инициативаны үз кулына да алган дигән сүз бу. Шунысы да сөендерә: чынлап торып әдәби берләшмәләр эшләгән районнардан (Мөслим, Мамадыш, Балык Бистәсе һ.б.) килгән яшьләр арасында табигый сәләтләре инде күпмедер дәрәҗәдә үсеш алган укучылар да күренеп тора. Менә шул семинарга кунак булып килгән шигырь сөюче, үзе дә каләм иясе булып китәрлек берәү мәзәккә охшаган шундыйрак фикер әйтте: хәзерге заманда китап укучыга кыен, барысы да яза, барысы да китап чыгара, кайсы әйбәт, кайсы начар, аңлап булмый, шуңа күрә әйбәт шагыйрьнең беренче китабы (таныр өчен) бакыр тышлы, икенчесе – көмеш, өченчесе алтын тышлы итеп чыгарылсын иде... Уйланырлык мәзәк. Беренчедән, әле катыргы тышлысын чыгара алсалар да бик шәп булыр иде, дип әйтергә кала. Икенчедән, укучының хәле чыннан да кыенрактыр, бәлки. Өченчедән... Тик бу «өченчедән» дигәне «икенчедән» дигәнгә каршы да килә: әдәбиятны яратып, чыккан һәрбер китапны дип әйтмим, кайберсен булса да укып, көндәлек матбугатта басылган шигырьләрне күздән кичереп баручының, һичшиксез, үз фикере була, андый укучыны берни дә юлдан яздыра алмый.

Көндәлек матбугат дигәннән, гәҗит-журналлар киоскларыннан нәрсәнең күбрәк алынганын белеп торабыз булыр. Яшьләрне әйткән дә юк, хәтта безнең әби-бабайларыбызның, киоск тәрәзәсенә килеп, «Вичирнәйә Казан» дип сорауларына минем йөрәгем әрни, кулында әле «Спид-инфо» ишесе дә була. Гаҗизлектән: «Апа, нишләп үзебезнең гәзитне алмыйсың?» – дим. «Болар хөкүмәтне яхшы сүгәләр», – дигән җавап ишетәм. «Спид-инфо»сына төртеп күрсәткәч: «Алырга куштылар бит...» – дип котыла...

Башкалабыз Казанда, Аллага шөкер, берничә йөз мең татар яши дип исәплик, тик ваклап сатуга татар гәҗит-журналлары һәр киоскка өч-дүрт данә генә чыгарыла, күбрәк булса, сатылмыйча кала. Бу хәлгә дә борчылмасак, без кемнәр булырбыз?

Дөньяга чыгарылган шигырь китапларыбызның да, һәрбер татар башына бүлеп карый башласаң, күпме туры киләсен әйтүе кыен түгелдер: ноль бөтен, ноль ... нольдән соң гына бер-ике күрсәткеч санын язып куяр идек. Менә шундый халык инде без. Татарстан радиосыннан тыңлаучылар белән туры элемтәләр үткәрелә. Кайвакыт шунда катнашыр өчен йә язучыларны, йә китап басучыларны – нәширләрне дә чакыралар. «Фәлән төрле китаплар сатуда юк, кайчан чыгарасыз?» – дигән сорау яңгырый телефоннан. Тыңлаучыларның мондый активлыгы әйбәт әйбәтлеккә, ләкин бик еш кына шунысы да ачыклана: сораган китап кибетләрдә бар икән бит, барып ал гына... Һәм шундыйрак хәл тапшырудан тапшыруга кабатланып тора. Тик менә сатып алу мәсьәләсенә килгәндә, нииндидер бер сәер икейөзлелек тә килеп чыга кебек – соравын сорый, ләкин алмый. Күзенә бәреп әйтә башласаң, акча юклыгын сәбәп итә. «Нигә булганын укымыйсың?» – дисәң, вакыт юк, ди. Каурый шешәдәге буяу кушып ясалган шикле суны алырга акча бар. Сырага, аракыга акча бар да бар инде, тәмәкесен әйткән дә юк. Болары начар гадәткә әйләнгән булса, китап укуны да яхшы бер гадәткә әверелдерергә мөмкин ич. Унар ел буе тоташ экраннан төшми торган күп серияле мәгънәсез фильмнарның берсен генә дә калдырмый карап барырга да вакыт табыла бит югыйсә.

Аллага шөкер, безнең «әдәбият» дигән сүзебез «әдәп» дигән тамырдан килә. Әдәп – яхшылык, һушлык. Аны үзләштерү, кальбеңә салу өчен бераз гына рухи көч тә сарыф итү кирәктер. Ә безнең халкыбыз исә читтән кертелгән ялган демократия шаукымына бирелде, ни кыйлансам, шул ярый дигән хәлгә төште, хәтта авылларыбыз да аракы күленә чумды, башка тискәре күренешләр дә чиркангыч тамырларын җәйде. Ата-бабаларның пакьлеген, сафлыгын аяк астына салып таптарга авылга да, шәһәргә дә турыдан-туры беркем рөхсәт бирмәгәндер лә?!

Менә шундый күңелсезрәк уйлардан арынырга тырышып, соңгы вакытта үзем укыган, карап чыккан шигъри әсәрләр турында уйлана башладым.

Еш кына безнең әдәбият, әйтик, бу очракта шигърият, дөньякүләм яңгыраш ала алмый, дибез. Борчылабыз. Бу шулайдыр, хактыр. Әмма шуны икърар итәргә кирәктер: бу юнәлештә һәрвакыт һәм хәзер дә ни дә булса эшләнә. Ләкин дөньякүләм яңгырау дип әйткәндә, газиз халкыбыз хәлен һичничек тә истән чыгара алмыйбыз. Без кемнәр соң? Безнең халык кем соң ул? Ул бит бик әздән генә хәзерге Америка индеецлары хәленә калмаган халык. Индеецларны кем аңлый? Аларның хәленә кем керә? Алар кемгә кирәк? Дөньяда олы җанлы берәр чын гуманистның табылганы бармы әле? Гуманист дигәннәре дә адым саен субъективлык сазлыгына чума. Дөньяда минем сүз генә сүз булсын, минем хөкем генә хөкем булсын дигәннәре дә бар бит әле. Анысына ни дисең? Бүгенге көндә дә тәре походларының шулай тантана итүен ничек бәяләргә? Без бит күреп торабыз: дөнья җәмәгатьчелеге фикере дип аталган, дөресендә, мәгълүм халыкның бер кастасы уйдырмасы булып, гасырлардан гасырларга килгән субъектив караш төркиләр өчен бик үк объектив түгел. Чынында төркине һәм төркичелекне күрмәмешкә салышалар. Алар хәтта дөнья халыкларының бишегә саналган Ике Су (бу очракта Тигр, Евфрат) цивилизациясен дә үзләренә генә язып куялар, хәзерге галимнәре дә Бабил заманнарында һәм элегрәк тә йөргән, әйтик, «төгәл» сүзенең (башка мисаллар да күп ич) үлчәү гамәленә караганы хакында язалар, шумерларны да искә алалар, тик «төгәл»не төркигә генә китереп бәйләмиләр. Бу уңайдан төрки пассивлык үзәккә үтә. Язучы Нурихан Фәттах әсәрләре дөнья халыклары телләренә тәрҗемә ителеп, аларга кемнеңдер игътибар итәчәгенә ышанырга гына кала.

Инде үзебезнең хәсрәтле, үзебез өчен кадерле дә булган татар язмышыбызга килсәк, башкалар аны аңламыйлар да, башкаларга аның кирәге дә юктыр дип саныйлардыр, бәлки. Хәтта кайбер башка төрки кардәшләребез дә безне, безнең хәлне аңлыйлардыр дип әйтә алмыйбыз. Менә шуннан татар шигъриятенең үзенә генә хас аерым миссиясе килеп чыга да инде. Билгеле, һәркем ирекле. Рәхәтләнеп үзең теләгәннәрне генә иҗат ит. Телисең икән, рәхим ит, дөньякүләм кызыклы булган нәрсәләрне яз, дөнья халыкларының күзенә чагылырлык итеп яз. Тик менә татар бик тә үзенчәлекле халык бит әле ул. Әнә Равил Бохараев Аурупаның үзәгенә барып кунаклады да яхшы мәгънәсендә татарлыкка чумды. Яраткан шагыйрәбез Нурия Измайлова океан артына – Америка оҗмахына кадәр очып барып җитте дә үзебезнең тормыш үрнәкләрен яктыртып, тегеләрнең яшәү өлгеләрен үзебезнекен өскә чыгару өчен пичәт-мөһер итеп кенә файдалана. Инде күптән урыс әдәбиятына китте дип саналган шагыйребез Ринат Суфиевның да (Роман Солнцев) «По ту и эту сторону», «Красная лошадь на зеленых холмах» дигән әсәрләрен генә укып карасагыз да, аның кемлеген беренче җөмләләреннән үк танырсыз...

Шигырь язган һәрбер каләмдәшем минем өчен якын, кадерле, газиз. Аларның һәрберсе бу заманның Дон Кихотлары кебек тә тоелалар: хәшәрәтлек баскан дөньяны бераз гына булса да чистартмак уенда яналар, туган телебездә сөйләшүчеләр кими баруын белгән хәлдә дә, образлы-сурәтле сүз дәрьясын саектырмаска тырышалар. Шигъриятебезнең сагында торган аксакал шагыйрьләребез Гамил Афзал, Илдар Юзеев, Әхсән Баянов, Шәүкәт Галиев, Равил Фәйзуллин, Фәнис Яруллинмы, мәхәббәтнең һәм гомумән дә тормышның шигъри нурланышларын ача барган ять-яшь

Луиза Янсуармы, йә тагын да аңа аваздаш, ләкин бөтенләй башка көйдәге Резидә Әхмәтовамы – барысы да изге гамәл кылалар, җанга хаҗәт матурлык тудыралар. Һәм мин Рөстәм Мингалим шигырьләрен дә көтеп алам. Башкалар да шулайдыр. Хәер, зур шагыйрьләрнең әсәрләре һәрвакыт көтеп алына.

Татар шигърияте дәрьясы тирән һәм киң. Ул бөтен төрки шигъри диңгезенә кушыла. Миңа кайвакыт, әле моннан мең ел элек тә төрки-татар шигърияте Җир шарын чолгап алган булган кебек тоела. Югыйсә шул ук Америка индеецлары дип аталып йөртелгән халыкларның «Алып атаның үлеме» дигән дастаныннан өзек кенә укысаң да, шундый фикергә килмичә нишлисең инде? Бүгенге көндә безнең татар тарихчыларыбыз, алар төрки булганнар, дип әйтүдән тыелыбрак калдылар шикелле. Берни эшләп булмый – һәр теманың үзенең өйрәнүчесе була. Мөхтәрәм Әбрар абый Кәримуллин якты дөньяда юк шул инде.

Татар шигърияте дәрьясы тирән һәм киң дигән идек, шулай булгач, андагы агымнар да төрле. Кайбер урыннарда агым киң, салмак, кайбер урыннарда бик югарыдан шарлавыктай сикереп, тирәнгә чума. Болай дигәндә мин Равил Фәйзуллинны күз алдында тотам. Корыч пружинадай кысылган тыгыз фикерле һәм хуш исле болын чәчәкләредәй җете шигырьләр иясе ул. Автор үзенең шигырьләрен, маһир буяучы ефәк-атласларын мангандай, тылсым казаннарына чумырып-чумырып ала. Һәм биредә язылмаган канундай безнең күңелгә кереп утырган бер нәрсәне мин дә уратып үтә алмыйм. Равил Фәйзуллиннар буыны, диләр дә, аларны Ренат Харис, Рәдиф Гаташ, Рөстәм Мингалим, Гәрәй Рәхим, дип яисә бераз башкачарак тезмәдә дә саныйлар. Шулай инде, җырдагыча, «Үскән чакта үскән идек, тал тамырлары кебек...», ләкин без, җырны дәвам итеп, «таралыштык» дип әйтмибез, чөнки әлеге шагыйрьләрнең һәркайсы үз биеклеген алганын күрәбез. Шигырьнең эченә, җелегенә үтеп кереп, аның биниһая нечкәлекләрен тоеп, бераз гына иркәләнеп иҗат итүче һәм шигырь белән генә яшәүче Рәдиф Гаташмы ул, яки үзе үк табигатьтән җырлы-көйле булып яралган нәфис иҗекле Гәрәй Рәхимме, «Шаян дөнья» исемле шигыре белән генә дә шул дөньяның ни хәлдә икәнлеген укучыга көзгедәгедәй күрсәтеп биргән Рөстәм Мингалимме, яисә иҗатының колачлы һәм тирән булуы белән шаккатырган, кеше рухы чагылышларын мөмкин кадәр зуррак кысаларда теркәп бара алган рәссам шагыйрь Ренат Харисмы – болар һәрберсе үз чишмәләренең юллары буйлап аерым-аерым эз салып киттеләр.

Шигъриятне кайберәүләр хатын-кыз шигъриятенә һәм ир-ат шигъриятенә аерып карарга ярата, икенчеләр исә мондый бүленешне бик үк ошатмый, хәтта үпкәли дә. Хатын-кыз белән ир-ат табигатенең икесенең ике төрле икәнлеген онытмасак, аерымлыкның булуы гаҗәп түгеллеген аңлыйбыздыр. Еш кына хатын-кызга да тормыш агачының авыр башын күтәрешергә туры килә. Ләкин син иҗат сукмагын эзләп киткәнсең икән, «минем юлга чәнечкеләр, билчәннәр үскән иде, шуларны йолкып күпме вакытым китте, куркыныч җанварлар да чыгып куркытты» дип зарлана алмыйсың, бары тик тапканыңны гына чыгарып саласың. Зур шагыйрәләрнең иҗаты кемгә караганда да хатын-кызчарак. Моны Анна Ахматова һәм үзебездән Саҗидә Сөләйманова иҗатлары да раслый түгелме? Укучыларыбызның игътибарын әле мин Газизә Сәмитова иҗаты тарафларына ук юнәлтер идем. Шагыйрә Флера Гыйззәтуллина турында сөйләгәндә еш кына аның шахтада эшләвен, җир астында сукырайган атлар куып күмер ташуын, җир өстендә матур-матур ак күлмәкләр тегүен әйтергә яраталар. Чынында исә Флера апа табигате белән иҗатта шахтер атлардан бик еракта тора, аның шигыре башбирмәс Сабан туе атын хәтерләтә, ә күлмәк җөйләре исә энҗе кебек тезелгән шигырь юлында бер чагыштыру булып кына хезмәт итәдер. Мин Флера Гыйззәтуллина кебек гыйбрәтле бер үҗәтлек белән шигырь серенә төшенергә тырышучы башка берәүне белмим. Моны хәтта үзем белән генә булса да чагыштырып әйтә алам. Өченче сыйныфтан ук шигырь язу-сызу белән шөгыльләнгәләп килсәм дә, тормыш мине әкрен генә уйнатып йөрткәннән соң, Иҗат исемле капканың төбенә китереп куеп: «Теләсәң, кереп кара», – диде...

Вакыт үткән саен, элеккеге еллар хәтердә яңара. Хәзер минем күңелгә Әлмәттә яшәгән чор якынаеп китте. Шуңа күрәдер дә Гамил абый Афзал турындагы уйларым кәгазьгә түгелде. Флера Гыйззәтуллинаны да чынлыкта Әлмәт бирде. Биредә хәзер дә бик күп хөрмәтле каләмдәшләребез яши... Совет заманнарында мәктәп программасы буенча да, университетта да бездән очы-кырые булмаган исемлекләр биреп урыс һәм чит ил әдәбиятын укыттыралар иде. Бер кереп киткәч, иң-иң әйбәт дигәннәрен сайлап алып та бик күп укыйсың. Менә хәзер мин күбрәк үзебезнең әдәбиятны укыйм, безнең шигырь теленең камиллегенә, нечкәлегенә хәйраннар калам. Уйлап карасаң, чит телләрдә татар теле дисбесендәге мәрҗәннәрне тезәрлек матур ефәк җепләр дә безнекенә килешә торган түгел бугай әле, ягъни моңны, халыкның ачы югалтулары аркасында туган уй-гамьне күп кенә халыкларга аңлатып та булмыйдыр шикелле. Безнең үзебезгә ишетелеп торган телебезнең әчке сыкрауларын ирештерер өчен башкаларда эквивалент булмаска мөмкин шул. Тик барыбер сәбәпләрне сылтау итеп булмыйдыр. Татар шигъриятен башка халыкларга да ишеттерү бурычы безнең өстә кала. Тукаебызның «Печән базары, яхут Яңа Кисекбаш» поэмасын искә төшереп әйткәндә, бәлки, Татар Пен-үзәге зур эшләргә сукмак салыр?

...Каләмдәшләремнең иҗатын хәтеремнән үткәрүне дәвам итәм. Менә кызу канлы Нәҗибә Сафина. Аның Туфан Миңнуллин турындагы чәчмә язмасын да шәп шигырь рәвешендә кабул иттем. Менә дөньяны башкачарак үлчәмнәрдә дә – виртуаль образлылыкны да тоеп, күрсәтеп бирә алучы, аны чама белән генә әсәрләренә дә кертеп җибәрүче Рифә Рахман. Ә Эльмира Шәрифуллина гаилә җылысын, балалар дөньясын халкыбызның гомум тормыш үрнәкләре белән бергә бер челтәргә үреп иҗат итүе белән аерылып тора. Көнчыгышның серле җилләре белән сугарылып, Уралларны урап кайткан шагыйрә Салисә Гәрәева хәзер Казанның мең авазлы шигъри казанында кайный, тик үз тавышын югалтмый.

Кара төндә болыт арасыннан сарпылып кына чыккан сихри ай яктысыдай, күңелгә якын, тылсымлы шигырьләр язучы Наис Гамбәр. Дөнья искәрмәгәндә, уйламаганда, бәлки инде көтмәгәндә дә, йомшак кына килеп кагылган җылы җилне хәтерләткән, затлы шагыйрь булып җитешкән Акъегет...

Рашат Низаминың «Ике мөһаҗир» поэмасын кызыксынып укып чыктым, чөнки әсәрдә безнең өчен бик тә кадерле, көрәшче язучыбыз Гаяз Исхакый һәм шулай ук дөньякүләм танылган шагыйрь Назыйм Хикмәт турында сүз бара. Заманында Төркиягә дә кертелгән коммунистик пропагандага алданган Назыйм Хикмәтне күп кәррәләр кызганырга кала. Аның иҗатын туган илендә кабул итә алмыйлар шул. Тик төрек халкының атасы саналган Ататөрекне «диктатор» дип атауның безнең авыздан чыгуы да кызганыч. Дәүләтне коткарып калучы итеп карый аңа төрек халкы, бу олуг затка ихтирамының иге-чиге юк. Без үзебезне әлеге халык алдында һич тә купайтып күрсәтә алмыйбыз. Дәүләт тоткан халык – бөтен халык инде ул. Дәүләтле халыкның диктаторы да, демократы да буладыр инде.

Бездә, бәлки, әдәбият та югарырак баскычта торадыр, татарның күңеле дә тирәнрәктер. Шулай инде, кайгы-хәсрәтең, югалтуларың күбрәк булган саен, җырың да үзәк өзгеч моңлы, әдәбиятың да тауга таба үскәндәй буладыр. Заманында «басмачлар»ны бастырып йөргән татар тагын бер мәртәбә җилгә йодрык селкеп калып, төрек халкының теленә яратмаган сүз белән керә күрмәсен иде. Аллаһы сакласын. Кадерлебез Гаяз Исхакыйга килгәндә исә, ул Төркиядәге башка безнең атаклы татарларыбыз (Йосыф Акчура, Садри Максуди, Рәшит Рәхмәти Арат һ.б.) кебек, төрекләргә «эшкә кереп», бер генә көн дә эшләмәгән, гомере буе бары тик үз халкының азатлыгы юлында иҗтиһат иткән. Шуңа күрә төрекләр аны бик үк яхшы белми. Әйткәнемчә, ул безнең өчен кадерле. Заманында мин Гаяз Исхакый җәсәден илгә – Идел-Урал туфрагына алып кайтып җирләргә иде дип язып та чыккан идем. Аның моңа хакы зур.

Нинди генә халык булса да, ул кешелек дөньясының уртасындамы, кырыендарак торамы, һәрберсенең үзенә насыйп аерым атлант баганалары була. Әдәбиятта да шулай. Без үзебезнең әдәбиятыбызның алтын баганаларын беләбез: мәңгелеккә киткәннәрен дә, исәннәрен дә. Бездә шулай ук әлеге әдәбият фидакарьләренә һәрчак җилкә куярга әзер торучыларыбыз пәйда булып тора: заман җилләрен меңьяшәр имәндәй олпатларча үзәгеннән үткәреп иҗат итүче Зиннур Мансуров, акыл, хисне йөгәнләүче Мөдәррис Вәлиев, чәчмә әсәрләрен дә шигырьдәй язучы Марсель Галиев, халкы өчен ут йоткан Газинур Морат, куркусыз, җете талантлы Ркаил Зәйдулла, үз җилкәсенә бөтен газиз халкын таяндырырлык гайрәте булган Айдар Хәлим, татар дөньясын шигъри бишектә тирбәтергә һәрвакыт әзер атаклы шагыйрьләребез Зөлфәт белән Мөдәррис Әгъләмнәр!

Хатын-кызларыбыздан танылган шагыйрәбез Лена Шагыйрьҗанның шигъри кыңгыравы армыйча челтери... Хикмәт китап санында түгел: шагыйрь икәнлеген берәр генә китап чыгарып та исбатлаучы Фәйрүзә Мөслимова һәм Рәмис Аймәт. Үзәге өзгәләнүче Илсөяр Иксанова. Нәкъ Фираячa – хатын-кызларча кала белгән Фирая Зыятдинова. Сүзнең тәмен, төсмерен тоючы Шәмсия Җиһангирова.

Әйе, татар шигъриятенең урманы куе-тыгыз, агачлары тирән тамырлы. Чынлап та, бу урманга кереп китүләре укучыга читенрәктер дә. Ләкин бит халкыбыз «Бүредән курыксаң, урманга барма» дигән сүзне дә әйтә. Бераз гына йөрәклелеге, сизгер күңеле-хисе булган кешедә ничек инде урманның серен белү омтылышы-теләге уянмасын ди? Тик нишлисең, урманга кереп китеп юл салу өчен күрсәткечләр, агачка тамга салулар да кирәк була...

Әйе, татар шигърияте таудан шаулап төшкән шарлама да, киң дәрья да ул. Аңа күп агымнар сыйган. Мин инде ничә еллар үзебезнең Югары Советта депутат булып, татар халкының уй-теләкләрен эзлекле рәвештә ишеттереп килгән Туфан Миңнуллин, Разил Вәлиев, Роберт Миңнуллин иҗатларын да күз алдында тотам. Биредә Туфан Миңнуллин исеме шагыйрьләр рәтендә ялгыш аталмады, Туфан әфәнде безгә соңгы елларда менә дигән нәфис робагыйлар мәрҗәнен бүләк итте. Ә Разил Вәлиев һәм Роберт Миңнуллин шигърияте күптән инде халкыбызның яратып укый торган әсәрләре арасыннан урын алды.

Безнең шигъриятебездә Харрас Әюпов иҗаты да үзенә генә хас үзенчәлекле: хисле-моңлы, шул ук вакытта җитди дә. Балалар язучысы булып танылган Рафис Корбанов олылар поэзиясе капкасын да ачып керде. Ә бөтен жанрларда да диярлек көч сынаган Галимҗан Гыйльмановның олылар шигърияте болынында да эзләр салуын укучылар белә булыр. Якташым Шамил Маннаповның шигъри дөньясы күпләгән укучыларыбызга рухи азык озатып тора. Адәм баласының эчке дөньясын энҗеләп-нечкәләп фәлсәфи эчтәлектә ачарга алынучы Мөхәммәт Мирза – шулай ук үз укучысын тапкан шагыйрь.

Күп бездә шагыйрьләр. Без шундый халык инде. Җырлы, моңлы... Сабан белән каләмне дуслаштырган Илдус Гыйләҗевне ничек искә алмыйсың инде? Искиткеч якты күңелле кеше, гамьле шигырьләр иясе...

Без Дәрдемәнднең шигъри осталыгына сокланып туймыйбыз. Аның турында:

Кош тотардай теле белән
Шигырьгә җим җимләгән.
Күңле җырга тулышканга...
Күп кирәген белмәгән, –

дибез. Ә менә Тукай белгән, күп кирәген белгән. Татар тормышының бөтен якларын ачып-сурәтләп, безгә, сукырга таяк тоттыргандай, бөтен гасырларга үрнәк булырлык ориентир – маяклар бастырып калдырган. Егерме җиде ел яшәп, җиде-сигез еллык иҗат гомере эчендә олы мирас тудырып, туксан җиде яшьтәге олпат аксакалдай дөньядан киткән.

Әмма бу сүзләр Тукай белән Дәрдемәндне бер-берсенә каршы кую дип аңлашыла күрмәсен. Биредә бер олы шәхес язмышының икенче бер олы шәхес язмышыннан ничек аерылып торуы хакында гына фикер йөртергә мөмкиндер. Күләме ягыннан азрак мирас калдырган Дәрдемәнд тә шагыйрь буларак тулысынча ачылган. Әгәр дә алай булмаса, без аны шул тиклем югары күтәрә дә алмас идек. Дәрдемәнднең ачылуы-ачыклыгы хакында, формаль-шәкли яктан алганда да, әсәрләренең темалары үк сөйләп тора. Ул үзенең иҗатында татарның бөтен тормышын (диңгезе-корабы белән бергә) үзенчә чагылдырган: татар язмышы, татар теле мәсьәләсе, татарлык проблемасы, гыйшык-мәхәббәт, балалар һәм табигать манзаралары һ.б., һ.б. «Бу ике олы шагыйрьнең кайсыннан шигъри осталыкка күбрәк өйрәнәбез?» дигән кебек сорау да куярга мөмкиндер. Моңа һәркем үзенчә җавап бирер кебек. Хәер, Габдулла Тукайны, Дәрдемәндне кыйбла тарафыдай күреп, шигырь диңгезендә заманында киң колач салып йөзгән Хәсән Туфан, Нури Арсланов, Сибгат Хәким бу сорауга әллә кайчан җавапны бирделәр инде. Тукаебызның да укытучыларын беләбез. Безнең Һибәтулла Салиховның «Гәүдә ахыр локмаи маран (үтеп китеп бетүче бер кисәк) икәндер, белмәдем» дигән юлларын укыганыбыз бар. Ә бөек Тукаебыз шуны тулы бер образлар системасы итеп үстерә.

Сиксән ел буе нәшер ителмичә торган «Бакырган» китабы, ниһаять, янәдән дөнья күргәч, әллә ни шау-шу булмады шикелле, ә бит Тукаебыз «Бакырган»нан да «чыккан». Мәрхүм Рәшит Әхмәтҗан «Аккошлардан корбан чалыр идем» дип язган иде. Шәехзадә Бабич исә «Ак куй чалыр идем» дип теркәп калдырган һәм кайдан алганлыгын да язып куйган. Образның үстерелеш юлы, тарихы бу... Яңа шигъри образлар исә бик сирәк, бик авыр туа... Мәсәлән, «Аерылу тавы – иң биек тау, башка күреп булмый аръягын» дигәндә бер шәхес язмышын, буыннар язмышын гына түгел, бөтен бер халкыбыз язмышын бәгырьне телеп, кичеп чыгарга кирәк...

Борынгы заманнардан ук гарәпләр үз шагыйрьләренең утырышуларын да язып, теркәп барганнар икән. Мондый мәҗлесләрнең гаҗәеп әкияти якларын, аларның язган шигырьләрен тикшереп, үпкәләшүләрен, ахыр килеп, дуслашуларын, шигъри образның беренчел чыганагы авторлыгы өчен даулашуларын, җепнең барыбер очына чыгу юлында армау-талмауларын һәм башка кызык та, мәзәк тә кебегрәк хәлләрне әйтеп бетереп булмый.

Шунысын да искәртеп үтәсе килә: шигырьне уртага алып, аның тышкы һәм эчке хасиятләре турында сөйләшәсе урында бездә нишләптер кайчак ике генә нәрсәгә игътибар итү бер модага кереп китте кебек. Нишләп безнең яңа Тукайларыбыз юк, һәм, янәсе, нигә җыен ыбыр-чыбыр шигырь язып йөрүчеләр күбәйде? Мәсьәләнең икенчесенә килгәндә, күп түгел алар – аз. Шагыйрь Нияз Акмал әйтмешли, элек һәрбер авылның үз шагыйре булган. Һәрберсе үз урынында кирәк. Беркемне дә кулыннан тотып яздырып яисә, син язма, диеп тыеп булмыйдыр.

Тирә-юньдә бер-ике төрле генә чәчәк үскән оранжерея яисә бер-ике генә төрле агач калкып торган питомникны гына күреп тору да туйдырыр иде. (Төрек шагыйре Хөсәен Нихәл Атсызның «...Гүзәл бер көнем, бер кичем бар иде, ул да туйдырды еш искә алудан» дигән шигырь юллары бар...) Барыбер беренчеләрен – төрле чәчәкләр үскән бакчага, икенчеләрен исә урманга күчереп утыртасы була, тик шунда гына алар үзләренең матур да, көчле дә икәнлекләрен исбатлый алачаклар. Мәсьәләнең беренчесенә килгәндә дә безнең җавап уңай булыр иде, тик бер генә «бәләкәй» комачау итүче бар, ул да булса – заман. Тукаебыз турында юкка гына «Нәкъ кирәк чагында булган дөньяга килүе дә» димибез ич. Аның заманында хәтта патша хакимияте татарның эчке тормышына тыгыла алмаган, татар кызлары, хәзерге кебек, оясы-оясы белән урыска кияүгә чыкмаган, егетләре чит милләт кызына өйләнмәгән, безнең мең еллык тарихы булган хәрефләребезне дә алыштыра алмаганнар – татарның үзенең, төрле ераклыклардан җыелган булса да, эчке бер дәүләте булган. Ул заманда татарның туксан тугыз проценты чын татар булып яшәгән, татар китабы сүзе халык тарафыннан закон кебек кабул ителгән. Шагыйрь аяк терәп иҗат иткән, терәге нык булган. Урыс мәктәбендә уку харап итте безне. Шуңа карамастан хәзерге шагыйрьләребез дә барыбер заманнан өстәрәк, югарырак торалар, аңардан курыкмыйча, хак сүзне әйтәләр.

Дәүләтчелегебез офыклары янәдән актыра башлаган кебек булганда, моннан ун еллап элек, кайбер даирәләргә артыграк лояльлек күрсәткән дип, Габдулла Тукайга карата да тәнкыйть сүзе әйтү теләге сизелгәләде сыман. Менә хәзер без янәдән элеккеге хәлебезгә әйләнеп төштек. Тукайның «Тотса мәскәүләр якаң» сүзе тагын актуаль. Безнең белән шагыйребез дә идарә итә. Уйламыйча гына Тукаебызны рәнҗетә башлау ярамаганлыкны безгә Ходай Тәгалә үзе әшкәрттеме (вәхи китердеме) әллә? Тукай безнең өчен шагыйрь генә түгел икәнлеген яхшы аңлыйбыз югыйсә*.

*2002*

**БЕРЕНЧЕ ТАУ**

Сибгат абый минем күңелгә бер җылылык, яктылык булып үзенең «Тәрәзә рамнары» һәм «Клиндерләр эзлим» дигән шигырьләре белән кереп калды.

Шаулы 1960–1970 еллар. Н.С.Хрущев «җылыткан» елларның әкренләп суына барганын сизәсе килми. Яшь шагыйрьләр, бигрәк тә мин якыннан белгәннәр: Равил, Рәдиф, Гәрәй, Ренат, Рөстәм* бергә җыелышып шау-гөр киләләр, хыяллар чиксез, уйлар йөгәнсез, хисләр дөрли, ирек мәңгелек кебек. Шушы елларда аларның утырышып сөйләшкән мәҗлесләрендә Рәдиф шигырь сөйләми калмый, үзенекен генә түгел, бик күп шагыйрьләрнең шигырьләрен яттан белә, бу яктан ул шундый сәләткә ия, аңарда шагыйрьлектән тыш чын артистлык та бар.

Дөресен әйтим, Сибгат абыйның «Клиндерләр эзлим», «Тәрәзә рамнары» шигырьләрен безнең һәр утырыш саен Рәдифтән сөйләтәсе килә. Бу нияткә аны Равил иплэп кенә «көйли» белә. Соңрак инде мин дә Рәдифкә «Тәрәзә рамнары»н сөйлә әле диясе урынга, «Гыйльметдинне» сөйлә әле дия башладым, чөнки Сибгат абый бу кыска гына шигырендә Гыйльметдинне шундый яраттыра, шигырьнең исеме «Гыйльметдин» булып тоела башлый.

Гыйльметдин ясый ул
Тәрәзә рамнары,
Керә дә утыра
Авылның урамнары.
Уздыра остасын
Казанның, Өфенең...
Керә дә утыра
Шул килеш офыгың...

Рәдиф сөйли, «Гыйльметдин», «керә дә утыра» дигән урыннарын әллә ничек кенә кызык итеп әйтә, хәтердә, күз алдында кала торган үзенчәлекле хәрәкәтләр ясый. Соңыннан, Сибгат абыйның үзен күргәч, аңлашылды, бу аның интонациясе, аның ишарә-хәрәкәтләре булган икән. Билгеле, соңрак Сибгат абыйның тавышын, аның ишарәләрен нәкъ аныңча яңгыратучылар, күрсәтүчеләр тагын булды.

«Клиндерләр эзлим» шигыренең берничә куплетын бик тә, бик тә күчереп язасы килә.

Нәрсә салыйм икән әнкәйгә мин,
Аны, димен, чиксез сөендергән?
Хат ахырында гына әйтеп куя:
«Оныта күрмә, улым, клиндерләр»...

Картайды нык, тешләре дә төшкән,
Колакка хәзер ул саграк...
Нигә инде шунда сорамаска
Берәр тәмле нәрсә, йомшаграк.

Кешеләрдән миңа бик уңайсыз,
Сине баккан ич ул, киендергән.
Зурдан кубып, имеш, кучтәнәчкә
Клиндерләр җибәр, клиндерләр.

Бу кадәр дә самимилек, бу кадәр дә ана белән баланың бер сулыш кешеләре булуын күрсәткән башка әсәрләр дә бардыр, әмма минем күңелгә, һәм, мөгаен, минем күңелгә генә түгелдер, бу темага язылган шигырьләрнең иң уелып калганы шушыдыр.

Еллар үтте, заманалар үзгәрде. Бу кадәр зур илне, күрәсең, нишләтергә аптыраган Н.С. Хрущев, шәхси хуҗалыклардан сыерларны җыйган кебек кенә милләтләрне дә тиз генә бөтенесен бергә «кушып», тиз генә коммунизм төзеп булмаслыгын абайлады... Әмма бу кеше турында барыбер начар уйлыйсы килми – халыкка шәхес культының кара, коточкыч куркыныч битләрен ачты бит ул.

Без Әлмәткә күчеп яши башлагач, Сибгат абый Әлмәт Язучылар оешмасына, язучылар янына килгәндә кайвакыт безнең өйгә дә керә иде. Ул шактый миниатюр кеше иде: уртача буй, бик җыйнак гәүдә һәм кечкенәлеге белән танылган кул. Аны белгән һәркем шул кечкенә кулларга игътибар итә. Моның үзенә күрә бер сәбәбе дә бар кебек иде. Чөнки Сибгат абый шул бәләкәй куллары белән шундый олпат кул ишарәләре ясый, ихтыярсыздан аның кулларына карыйсың. Менә ул әкрен генә, вәкарь белән генә

башындагы бүреген сала, аны ашыгып хуҗага да сузмый, элгеч башына да кабаланып үрелми, ниндидер бер мизгелдә бүрек игътибар үзәгендә булып ала, хуҗа Сибгат абыйның үзе кебек ипләп тотып, бүрекне алып куя, шулай ук пәлтә, шарф салына. Бернинди ыгы-зыгы юк, кунак та кабаланмый, хуҗа да үзен уңайлы хис итә...

Аннан соң чәй эчү дә була, сөйләшү дә. Сибгат абый әкрен генә сөйли, ир-ат җәмәгате белән гәпләшә, мин тыңлап торам, чәй якларын карыйм...

Сүз гел әдәбият турында. Сибгат абыйның сәламәтлеге бик үк әйбәт булмаса да, аның сәламәтлегеннән зарланганын ишетмәдем, вак-төяк көнкүреш мәшәкатьләре хакында да сөйләшми иде. Яшьләр аның исәнлегенең әйбәт түгеллеген беләләр (ә Сибгат абыйга еш кына юлда йөрергә туры килә, анда өй ризыгы юк, Мөршидә апа ияреп йөри алмый, ул гомер буе шәфкать туташы булып эшләде), шуңа күрә «Сибгат абый, юлда уңайсыздыр инде, нәрсәләр ашыйсыз соң?» дигән кебек сораулар да бирәләр иде. Сибгат абый бу сорауга җавап биргәндә «кефир», «творог» сүзләрен үзенчә бик тә мәзәк иттереп, бик тә матур итеп әйтә: «Кефер, туурыг...». «Кефир» сүзе әле бөтенләй дә «көфер» булып ишетелә. Бу чакта яшьләрнең мыек астыннан гына елмаюларын Сибгат абый сизеп тора, үпкәләми, үзе дә елмая.

Сибгат абый күп тә сөйләми, аз да сөйләми, нәкъ олпатларча, акыл иясенчә, кирәген генә сөйли.

Бу урында икенче бер якын исем – драматург Юныс Әминев искә төшә. Ул Әлмәттә яши. Кышкы озын кичләрдә хатыны Фәһимә апа белән алар безгә килә йә без аларга барабыз. Равил белән утыралар шулай. Юныс абый: «Әйе, әйе, шулай, һе», – дип утыра. Равил сөйли. Төнге сәгать берләр узып китә, кузгала башлыйлар, шунда йомгаклап Юныс абый сүз әйтә: «Әй, рәхәтләнеп сөйләштек тә, Равил!» Юныс абый шулай ук гаҗәеп кеше иде. Аз сөйли, күп уйлый. Уйлыйсылары күп иде шул аның – Сталин күрсәткән явызлыклар аның кырыеннан түгел, үзәгеннән үткән. Ә торгынлык чоры инде бусагадан атлаган, турыдан ярып әйтәсе сүзләрне уйлап кына йөрисе чор башланган...

Янәдән Казанга әйләнеп кайткач, мин урыс мәктәбенә татар теле укытырга урнаштым. Татар теле дим, әдәбияты да дип әйтмим, чөнки район мәгариф бүлегендә эшкә керергә дип гариза язганда «... на работу учительницей татарского языка и литературы» дип язгач, «литературы» дип язмагыз, татар әдәбияты укытмыйсыз, ул юк, татар теле генә укытасыз» дип, «әдәбият» сүзен сыздырталар иде. Билгеле, аңа карап бер укытучы да тел генә укытмады, тел белән әдәбият мөмкин булган кадәр бергә алып барыла иде.

4 нче сыйныф дәреслегендә Сибгат абыйның «Беренче тау» шигыре бар. Шуны балаларга үзем укыйм, алар укый, аңлатам. Ульяновлар урамы, Комлев һәм тагын кайбер урамнарның Беренче тау дип аталып йөргән тирәләрдә урнашканын искәртәм. Шушы Беренче тауда яшәгәндә Ульянов-Ленин революцион эшен башлап җибәрә. Балалар бик үк төшенеп бетмиләр, укытучылар да шигырьне авыр диләр. Дөрестән дә, шигырьдә күпнокталар, әйтелеп бетмәгән сүзләр, мәгънәләр бар сыман. Сибгат абый бу шигырендә каядыр чакыра, нәрсәгәдер өнди сыман. Һәм шушы ишарә көтелмәгәндә генә ачылды да кебек. Моннан дүрт ел чамасы элек шушы Беренче тау дигән җиргә – бик матур архитектуралы мәһабәт бинага Татарстан Язучылар берлеге күчеп урнашты. Бу күчү 1985 елның «җылы апрель җилләреннән» соң мөмкин булды кебек. Казан ханлыгы чорында ук шул урыннарда татар бистәләре булса да, Явыз Иван татарларны рәхимсез рәвештә басып алганнан бирле, әйбәт, таулы-коры җирләргә бер генә татарның да аягы бастырылмаган, аларның исән калганнары да сазлыклы урыннарга куып төшерелгән. Шул еллардан бирле Беренче тау дигән җирдә хәтта безнең көннәрдә дә татарлар бик аз яши, ә татар милли учреждениеләреннән исә берәү генә дә юк иде шикелле. Менә шунда – Беренче тауга милли оешманың күчеп урнашуы халык өчен Беренче тау кичү сыман тоела миңа. Сибгат абый үзенең «Беренче тау» дигән шигырендә һәркемгә дә Беренче тауны үтәргә мөмкинлек калдыра, ул мөмкинлекнең булуына ишарә ясый, хәтта шушы Беренче тауны үтәргә чакыра кебек. Шигырьдә әйтеп бетерелмәгән ишарәләр, мәгънәләр, күп нокталар шуны уйлата... Күңелдә зур бер үкенеч: Сибгат абый язучыларның Беренче таудагы яңа бинасына бары тик бер-ике мәртәбә генә килә алды, диделәр.

Сибгат абыйга үземнең рәхмәт хисемне дә рәтләп белдерә алмадым. Ул минем «Сәрвиназ» исемле беренче китабыма сүз башы язган иде. Китап чыкканда Сибгат абый нык авыру иде инде. Сугыш яралары аны ычкындырырга теләмәде...

Ишетүемә, белүемә караганда, Сибгат абый күпме башлап язучыга үзенең хәер-фатихасын биргән, үзенең акыллы, зирәк киңәшләре белән аларга әдәбият дигән Беренче тауның юнәлешен күрсәткән...

*1997*

## ӘҮЛИЯНЫҢ ГОМЕР КИЧҮЛӘРЕ

«Каләм! Кальбеңдә ни сер бар?»

Адәм баласының ара-тирә бер җилләнеп, әллә кайлардан әйләнеп, йөреп кайтасы да килә. Әгәр дә ул «әллә кайлар» дигәнең туган халкың яшәгән Ыкның аръяклары да булса... Чакыручылар булгач, чыгып киттем. Пәйгамбәребез, чакырган җиргә барыгыз, дигән ич. Туган ягың кырлары буйлап, ашыкмыйча гына автобуста бару үзе бер хозурлык. Иртәдән кичкә хәтле барасың да барасың. Шулай озак итеп барырлык җөмһүриятең булу да бәхет. Кайчандыр Швеция, Германия, Чехия, Финляндия кебек илләрне дә автобуста бер көн эчендә аркылыга-буйга үткән бар иде. Димәк, кечкенә түгел ул безнең туган яклар. Ә юлның ике ягында сине озатып барган матур манзара – иген кырлары! Аларның гүзәллегенә нинди генә симфония, ода-мактаулар багышласаң да аз булыр кебек.

Юл үзенекен итә, бара-бара рельеф үзгәрә, үзәнлек-тигезлекләрне таучыклар, таулыклар, таулар алыштыра башлый. Әлмәт, Бөгелмәләрне үткәч, алар тагын да ешая. Тәбәнәк, шомарган таулар. Мондый тауларны карт таулар диләр икән. Алар, имеш, ничә миллион еллар яшәп картайганнар. Нишлисең, бәлки, нәкъ шулар безнең халыкка сабырлык теләп һәм өстәп тора торганнардыр әле. Кирәк ул сабырлык безнең халыкка, бигрәк тә бүгенге көннәрдә: бөтен христиан дөньясының өерелеп, бергәләшеп мөселман дөньясына ташланган көннәрдә, террорчылыкка каршы көрәш дигән сылтау белән дәүләт исеменнән һәм дәүләт тарафыннан тулы бер халыкка карата кылынган террорчылык заманында. Югыйсә ул сабырлык дигән нәрсә беркемгә дә артык түгелдер, хәтта мин-минлекләре тирелләренә сыешмаган агрессорларга да, башкасына да...

Әйе, бу җирләр таныш та, күңелгә якын да. Әнә, без гаилә белән барганда йә кайтканда туктап ял итә, чәй эчә торган түгәрәк күл нәкъ элеккегечә ялтырап ята, тирә-юнендәге үләннәр дә хәтфәдәй елык-елык килеп җил уңаена авыша.

...Кунак-хөрмәт күреп, кире Казанга кайтканда, мин Азнакай аша үтеп, бик азга гына Әлмәткә кереп чыктым. Бу очракта «кунак-хөрмәт» сүзен халкыбызның асыл сыйфатларыннан берсе булган кунакчыллыгына басым ясап әйтәсе килгәнгә искә алам. Ыкның аръягында бүген дә таныш булмаган кешегә дә сәлам бирү, Казаннан хәтле кодача килгән икән, дип, бер көнне өчәр җиргә мәҗлескә чакыру гадәте һич тә бетмәгән икән. Ә гөл кебек кечкенә генә Хәлимә җиңгәчәмнең кеше күреп өлгергәнче 30–40 кешегә табын корып куюы бер могҗиза кебек булды. Үз өендә табын корудан безнең халык кына шулай илһам ала бугай, чөнки башкаларда хәлләрнең үзгәрәк икәнен беләбез. Күп кенә халыклар ресторанда бергә җыелып, һәркайсы аерым түләп чыгып китәләр икән дә шул кунакта булу дип атала икән. Хәтта безнең кардәш төрекләр дә өйләрендә кунакка каһвә генә бирәләр...

Әлмәттә, Гамил Афзал фатирында (бу фатирда без дә биш ел яшәп алган идек) мине аның җәмәгате, элеккегечә үк мөлаем һәм чибәр Нәфисә ханым каршы алды. Гамил абыйны берничә еллар күргәнем юк иде, Нәфисә апа: «Ятып тора әле, хәзер алып чыгыйм Гамил абыеңны», – дип, бүлмәгә кереп киткәч, күңелдән «әллә чирлиме икән» дигән борчулы уй да үтеп китте. Әмма әкрен генә, үзенә генә хас адымнар белән атлап килеп, каршыма туктаган шагыйрь нәкъ элеккеге Гамил Афзал иде. Шул ук шаян йөзле, үткер сүзле Гамил Афзал, тик менә чәчләр һәм сакал-мыек кына ап-ак. Хәзрәти Хозыр Ильясмыни! Йөзендә, күзләрендә пәйгамбәрлек зирәклеге, акылы, хәтта шаянлыгы да чагыла. Бөтен йөрәге-күңеле, төбе-тамыры белән әдәбиятка кирәк булган өчен генә тормышны яшәргә яраклы дип санаучы, аны тирәнтен аңлап, чичәнлек һәм Хозыр Ильяслык куәсе вә куәте белән гади һәм көчле итеп бәһа бирүче, үзенең 80 яшьлек юбилей бәйрәмнәрен исән-сау килеш үткәреп җибәргән Гамил Афзал каршында басып торам.

Гамил Афзал, адәм балалары бу тормышта никадәр генә чәбәләнеп, мәш килеп, нәрсәдер кырып йөргәндәй кыланмасыннар, яшәүнең бар яме табигать белән бер булып яшәүдә икәнен бик яхшы белә:

...Базар сәясәтен эт ашасын,
Бу йөрәккә нәфис моң кирәк.
Табигатьне күреп моң табасың,
Сәясәтсез үсә тал-тирәк.

Җор күңелле, хөр күңелле, күпме авыру-сырхауларны да көлеп-елмаеп үткәргән, әйткәнебезчә, көндәлек тормыш мәшәкатьләренә әдәбият-шигърият тудыру өчен генә тереклек итү – җан асрау дәрәҗәсендә генә кызыксыну күрсәткән әдипнең дә без белмәгән, гадәттән тыш күңел төшенкелеге кичергән чаклары да булган икән:

Тарих юлы – кара урмандыр ул,
Пәйгамбәрләр тамга куйгандыр,
Иң каһәрле, иң кадерсез кеше –
Татар язучысы булгандыр.

Гамил Афзал кебек зур талант иясе, билгеле, үз кичерешләрен генә язмагандыр. Әлеге юлларны укыгач, бүгенге күпчелек татар язучыларының хәл-хәяты хакында уйлау белән бергә, колониаль режим урнашкан чорда ук социаль һәм сәяси изелүгә дучар ителгән, күпмесе вәйран булган язучыларыбыз турында да уйландыра. Һәм, билгеле, халык турында да, чөнки язучыларыбыз артында халкыбыз тора. Каның белән язып дигәндәй, аннан соң да көч-хәл белән дөньяга чыгарган китабыңны милләттәшләреңнең зур күпчелеге укый белмәвен күрү яисә андый китапның чыгуы хакында бихәбәр-

битараф булган «урыс телле» кардәшләреңнең көн саен, сәгать саен артуын күреп, белеп тору иң аянычлы, иң әрнүле сүзләрне язарга мәҗбүр итә торгандыр.

Әйе, Гамил Афзал табигать җырчысы гына түгел, ул социаль-иҗтимагый, сәяси-җәмгыяви үзгәрешләргә үтә сизгер, өйдә генә диярлек тереклек алып барса да, күңеле белән сизеп, тоеп, белеп тора. Кешегә, бигрәк тә үз халкына кагылышлы хәлләргә, мәзәк-көлкеле, аяныч-сатирик күренешләргә дә шагыйрь шунда ук үзенең шигъри мөнәсәбәтен белдерә:

Мескен булып тору бетте,
Менә ипи, әнә кояш!
Туры сөйләр вакыт җитте,
Безнең тормыш, безнең влач!
...Халык кыюланып китте,
Югарыдан рөхсәт булгач...

Гамил Афзал иҗаты киң диапазонлы. Гомерен җырлап үткәргән шагыйрь – шигырь телендә һич тә сандугачтан ким сайрамаган сүз остасы – шулай да нигәдер болай дип яза:

Кар сулары кебек акты гомер,
Былбыл булалмадым тирәктә...

Әдипнең үз-үзенә тәнкыйди карашымы бу, әллә җәмгыятькә, укучыга киная дә бармы монда? Хәер, шагыйрь күңеле үтеп чыга алмаслык карурман инде ул.

Сәфәремнән кайткач, Гамил абыйның үз кулы белән язып бүләк иткән китабын укыйм. Мин китапның теләсә кайсы битен ачып укырга яратам. Аннан соң гына аның эчтәлеге белән таныша, өйрәнә башлыйм. Бәй (Ыкның аръягына чыгып керденме, бу матур сүз телдә кабатлана башлый. Сөйләмнәрен матурлап, аңа бер җанлылык биреп, андагы милләттәшләребез рәхәтләнеп кулланалар аны), сүз башын, дөресрәге, шагыйрьнең иҗатына анализны язучы һәм тәнкыйтьче Галимҗан Гыйльманов язган икән ич. Гамил Афзал иҗатындагы образлар системасын матур бер сәйләндәй тезеп куйган каләмдәшебез. Шул мәкалә-анализда авторның «Халык шагыйре» дигән төшенчәнең асылын ачып бирергә омтылышы да күңелгә хуш килде. Ул аны бирелгән дәрәҗә генә түгел, ә олы иҗатчының табигый халәте итеп күрсәтә алган. Җыентыкны төзүче дә Г.Гыйльманов үзе икән. Төзү мантыйкый һәм шигъри берлек табып эшләнгән. «Гомер кичүләре» исемле бу асыл мәҗмуга – «Рухият» нәшриятының изге гамәле. Минем белән сөйләшеп утырганда да «Рухият» нәшриятына чиксез рәхмәтле булуы хакында әйткән иде Гамил абый.

...Нәфисә ханым чәйне яңартып-кайнарлатып тора. Ул Гамил абыйның гомерлек хәләл җефете, багып-карап, тәрбияләп торучы, балаларының яраткан әнисе һәм оныкларының дәү әнисе. Шуның белән бергә аны Гамил Афзалның иҗатыннан да аерып карап булмый. Гамил абыйның барлык әсәрләрен үз кулыннан үткәреп, аларны күп тапкырлар машинкада басып, матбугатка әзерләшүче дә, шигырьләренең күбесен яттан белүче дә, һәм, гомумән, бөтен татар әдәбияты белән даими рәвештә танышып баручы да ул Нәфисә апа.

Гамил Афзалга ясалма тыйнаклык хас түгел. Ул үзенең әүлиялар нәселеннән икәнлеген дә белеп яши:

Җыр китабым минем – бар булганым,
Җыеп-көеп салдым изге хисне.
Акыл үсеп азган бу дөньяның
Әүлиясы булыр минем төсле.

Биредә сурәтләү нәкъ Гамил Афзалча: йөрәкне әрнеткән азгын дөнья хакында әйткәндә дә сабыйларча елмаю, янәсе, гафу итегез, азгын дөньяның әүлиясы шундый инде. Шагыйрьнең әдәби осталыгының әле бөтенләй эченә кереп җентекләмәгән очракта да, аның шигырьләренең ритмы гадәттән тыш тигез булуы, адәм баласының табигый сулыш алуына бик тә тәңгәл килүе (Коръән Кәримдәге мәртәбә!) күзгә чалына.

Гамил Афзал – шигъриятебезне гаҗәеп зур ачышлар белән баеткан шагыйрь. Бүгенге көннәргә килеп җиткән Гамил Афзалдай чичәннең телендә яшәгән сүзләр бетмәс-төкәнмәс мәңгелек чишмәләрдән көмеш тәңкәләр кебек тәгәрәшеп агып чыгалар сыман.

Без шауладык инде көлә-көлә,
Халык тыңлап торды... җилкә кашып.
Матур заманнарга килә-килә
Туры сүзне әйтик, горур басып.

Менә бу дүрт юлда көтелмәгән фикер борылышлары, ирония, сарказм һәм шул ук вакытта шапырынучы адәм баласына сак кагылырга тырышу, хәтта аны кызгану хисе ярылып ята. Гамил Афзал поэзиясенең бер яңалыгы – матур гына лирик шигырь кебегрәк башланып киткән әсәргә көтелмәгәндә ирония, сатира-сарказм элементлары килеп керүе яисә бөтенләй дә каһкаһәле ачы көлүгә әйләнүедер, бәлки. Югарыдагы шигырьдә дә яңалык юк кебек, ә без белгән Россиядә гомер-гомергә матур заманны

зарыгып көтү галәмәте генә бар. Өстәвенә әлеге дүртьюллык тач фигыльләрдән һәм фигыль рифмалардан тора кебек. Әмма максатка ирешелгән (гади сөйләп чыгу түгел), туктап уйландыра торган шигырь туган. Ничек туры китерәсең бит.

Гамил абыйның «Гомер кичүләре» китабын укыгач, бу игелекле иҗатның сүрәнләнгән күңелләрне дә балкытып, җанландырып, яктыртып җибәрү көченә ия булуына ышанасың. Минем үземнең дә җөмһүриятебезнең көнчыгыш районнары буйлап үткән сәяхәтем вакытында кичергән тәэсирләрем тагын да матураеп, диңгездәй шаулап офыкларга хәтле киткән иген кырларыбыздай киң сулыш алып, бигрәк тә җанлана төштеләр, ә кайбер караңгы якларыбыз-җитешсезлекләребез тоныкланып, тормышның ыбыр-чыбыр ваклыкларына әйләнеп, эреп югалдылар.

*2001*

## УЛ БЕРЕНЧЕ ИДЕ

Иң мөкатдәс, мәгънәле яшәлә торган гомер – тарихи Ватанда узганы, иң зур мактауга лаек хезмәт – туган халкыңа багышланганы.

*Т. Әйди*

Борынгы заманнарда ук төрле миссия белән дөнья буйлап йөрүче кешеләр булган. Аларны кодрәтле хакимият ияләренең канцелярия хезмәткәрләре, эшлеклеләре зур юлларга әзерләгәннәр, кирәкле һәрнәрсә белән тәэмин иткәннәр, кулларына ышаныч хатлары тоттырганнар. Әлеге сәяхәтчеләр өчен махсус кәрваннар, экспедицияләр төзегәннәр, үзләренең хәер-догаларын биреп, кайсыларын тантаналы рәвештә, ә кайберләрен шыпын гына озатып җибәргәннәр.

Ә менә безнең көннәрдә горбәтлектә җәфа чиккән газиз халкының дөнья буйлап сибелгән бөртекләрен барып табу-барлау, күрешү-хәл белешү, татарлыгы җуелмаганнарының ничек тә рухларын күтәрү, ә татарлыгы югалып баручыларына үзләренең кемлеген исләренә төшерергә омтылу, тарихи Ватан турында хәтерләрен яңарту, бер уңайдан, гомумән дә башка халыкларга да мәгърифәтле татар милләте барлыгын белгертергә тырышу миссиясе белән ирекле баштан, төп эшеннән аерылмыйча, үзенең шәхси ялы хисабына ерак юлларга чыгып китүчене батыр димичә, кем дисең инде? Әйе, татар әдәбиятының күренекле вәкиле Тәуфикъ Әйдине әле тора-тора да батыр дип атарлар...

Совет чорында, 1970–1980 елларда (үзебезнең XX гасырга шулкадәр дә ияләшелгән, аны үткән гасыр дип әйтергә тел дә әйләнми) без – татар әдәбиятын сөючеләр чит илләр турындагы мәгълүматларны күбрәк Миргазиян Юныс әсәрләрен укып ала идек. Хәзер менә шундый икенче бер төрле заман килеп ята ки, Тәүфикъ Әйди йөреп чыккан илләр (кайберләреннән кала) һәм элеккеге СССР җөмһүриятләре хакында ни генә белербез икән? Анда бүленеп калган милләттәшләребез хакында ни ишетербез? Күз күрмәгән, колак ишетмәгән юл чыгымнары аркасында ул яклардагы якын туганнар белән дә күрешә алмас булдык. Элек «күгәрчендәй гөрләшкән» Болгария, Румыния, Венгрия, Польшаны да «оныталар» бугай инде – анда, ул илләрдә дә безнең милләттәшләр байтак диләр бит. Менә бу очракта безгә Тәуфикъ Әйди әсәрләре ярдәмгә килергә мөмкин, һич югы, андагы милләттәшләребезне онытмаска бер кыңгырау булып торыр, әгәр дә алар һәртөрле кысу-җәберләү яисә үзләренең ваемсызлыклары аркасында бөтенләй юкка чыгып бетмәсәләр...

Хәер, кая инде ул чит илләр, татарның бүгенге көндә дәүләтчелек билгеләре булган җирлектә – Татарстанда – халкыбызны упкынга аккандай йотылудан бергәләп саклыйсы, саклашасы иде. Тәүфикъ Әйди бу эшне нәкъ үзебезнең җөмһүрияттән башлаган да.

Искиткеч кызыксынучан һәм шул ук вакытта төгәл мантыйк, аек акыл белән эш йөртүче сәяхәтчебез күзеннән татар тормышының, татар авылларының бер генә детале дә читтә калмый. Әйтик, авылда ничә йорт бар, ничә кеше яши, мәктәп нинди, укучылар ничәү, укытучылар җитәрлекме? Авылда китапханә бармы? Анда ничә китап җыелган? Иң мөһиме – татарчасы күпме? Клуб эше ничек? Анда җыр-бию генәме? Әллә профессиональ сәнгатьнең нигез ташы булган фольклорга да игътибар бармы? Бу игътибар конферансье – алып баручының бер-ике мәзәк әйтүе белән бетәме, әллә төрле жанрлар буенча кичәләр үтәме? Әйе-әйе, мәсәлән, мәкаль, әйтем, табышмаклар кичәсе, бәет кичәсе һ.б. Тәуфикъ Әйди хәтта аерым фольклор клублары оештырырга тәкъдим итә: театр түгәрәге, хор, ансамбльләрне оештырган кебек. (Т.Әйди. Сайланма әсәрләр.«Сәхнәгә мәзәк кирәкме?» 11 т., 4–10б.) Бүгенге мораль-этик хәлләрнең авылларыбызда да чигенә җитеп начарланганын күз алдында тотсак, фольклор клублары оештыру көнүзәк мәсьәләгә әйләнгән икән бит! Үз халкыбызның хикмәтле сүзләре белән «чыбыклап» тәрбияләү ихтыяҗы туганлыгын һәрберебез күреп торабыз – шундый «пеше чыбык» бик күпләребезнең «аркасын эзли» түгелме?

Тәүфикъ Әйди өчен авыл кешесенең бер проблемасы да чит түгел. Авыл кешесенең кереме бармы? Ул ничек яши, очын очка ялгый аламы? Әмма аны иң борчыган мәсьәлә – татар китапларын, татар гәҗит-журналларын татарларның уку мәсьәләсе.

Менә шунда ул үзенең үгетләү-пропагандалау эшен осталарча, хәтта ки, тылсымчыларча башкара да инде.Очрашуга килгән халык алдында аркасында, кулында күтәреп алып килгән зур сумкалардан

«Казан утлары», «Ялкын» журналлары, ул вакыттагы «Яшь ленинчы», «Ватаным Татарстан» гәҗитләре, бик күп татар китаплары чыга башлый һәм... «сорау алу» башлана:«Бусын укыйсызмы? Бусын алдыртасызмы?» Гәҗит-журналларны яздыртып алмасалар, китаплар укымасалар, Тәүфикъ Әйдидән рәхим-шәфкать көтә алмыйлар, үтергеч тәнкыйть утына тотылалар, соңыннан гына, йомгаклау сүзендә генә «төзәлүләренә» өмет белдерелергә мөмкин...

Ләкин чын йөрәктән әйтелгән тәнкыйть, агит-үгетләүгә кеше үпкәләми, киресенчә, күңеле йомшара. Нәкъ шул 1970–1980 елларда «Казан утлары» журналының тиражы нык үсеп китүендә Тәүфикъ Әйдинең өлеше барлыгын танымый мөмкин түгелдер.

Агит-үгетләү дип яздым да Тәүфикъ Әйдинең «үгетбригада» сүзе искә төште. Язучы, галимнең яңа сүзләр барлыкка китерү, аларны куллану хакында да фикере кызыклы. Ул үзебезнең төрки телләр җирлегендә, татар җирлегендә үсеп чыкканнарын куллануны бигрәк тә хуплый. Яңа сүз башта гына чит сыман тоелырга мөмкин, тора-бара ул үзләшә, чит булып тоелмый башлый, мәгънәсе тирәнәя, киңәя, гомумиләшә дигән фикер үткәрә автор. «Үгетбригада», «уймасын» (бусын сәнгать белгечләребез куллана да башлады) һәм башка байтак сүзләрдән тыш, Тәүфикъ Әйди язган, татар колагын иркәли торган «шөрек» (слива), «кирәз» (черешня) дигән сүзләрне дә кабул итеп аласы иде. Шөрек җимешенең исемен һаман да тырыша-тырмаша «слива» дип язабыз да, әйткәндә, «ыслива» дибез. Көне-төне дигәндәй, «гәҗит» дип сөйләп, язганда, «газет» йә «гәзит» дип язган шикелле. «Шөрек» һәм «гәҗит» матур, татарча яңгырый. Ләкин бездә яңа сүзләргә яисә янәдән кулланылышка кереп китәргә мөмкин булган саф татарча яңгырашлы сүзләргә кайвакыт галимнәребез дә, ә кайчакта аны-моны бик аңлап бетермичә, әмма күңелендә ниндидер амбиция – галилек тузаны йөрткән укучыларыбыз да ташланучан була...

Тәүфикъ Әйди әкренләп үзенең эшчәнлеген – татарны барлауны, ягъни сәяхәтләрен киңәйтә-җәелдерә бара, бер үк вакытта аның каләменнән хикәяләр, мәкаләләр, романнар, юлъязмалар коела тора. Аның һәр язмасын эзлеклелек, кайнар үгетләү характерлый. Татарга татар энциклопедиясе кирәклеген исбатлаган мәкалә 1977 елда ук язылган. (Сайланма әсәрләр. 11 т., 11–26 б.) Автономиягә генә ия булган республика милләтенә совет заманында энциклопедия тәтемәде – рөхсәт булмады. Әле дә хәтердә, бервакыт Бакыдан яшь азәрбайҗан галимәсенә: «Бездә татар энциклопедиясе дә, аның институты да юк», – дигәч, бик тә исе китеп, аларда шул институтта биш йөз фәнни хезмәткәр эшләвен шактый һавалы итеп белдергән иде. Ул елларда без, сездә энциклопедия институты юкмыни, дигән сүзләрне ишеткәләп кенә яшәсәк, безнең Тәүфикъ Әйдиебез дөнья буйлап сәяхәт дәвамында башка халыкларның – бигрәк тә заманында татарлардан мәгърифәт юнәлешендә бик зур ярдәмнәр күргәннәренең – союздаш республика шартларында шактый нык алга китүләрен күреп бер шатланса, үзебезнең читен хәлләр өчен йөрәге кысылуын, каны бозылуын һәрбер әсәрендә, һәрбер җөмләсендә күрергә мөмкин.

Язучы, галим Тәүфикъ Әйди чын-чынлап югары кимәлдәге иҗатчы иде. Әгәр дә ул дөнья әдәбияты, мәдәнияте югарылыгында һәм бер үк вакытта үз халкының үсеш ноктaларын ачык билгеләп, хәбәр бирерлек дәрәҗәдә булмаса, аны Мюнхен шәһәрендә Бавария Язучылар оешмасының рәисе Аста Шайб исе китеп, авызын ачып дигәндәй тыңлап торыр идемени? «Әгәр мин эстон язучысы булсам, Шайб ханыма немес теленә тәрҗемә ителгән дүрт йөз битле «Эстон әдәбияты» белешмәлеген, «Эстон новеллалары»н, эстон шагыйрьләренең махсус тәрҗемәгә дип әзерләнгән җыентыгын, реклама брошюраларын, берничә классик язучының буклетларын бүләк итәр идем», – ди Тәүфикъ Әйди. Безнең милләтпәрвәребезгә электә бөек дәүләте булган татарның кем икәнлеген нольдән башлап – өр-яңадан аңлатырга туры килә.

Тәүфикъ Әйди әсәрләрен укыйсың да, аның хезмәттәшлек иткән киңлекләренең колачлыгын күрәсең дә: «Тәүфикъ Әйди үзгәртеп кору җилләрен тизләтүчеләрнең берсе булган икән», – дип хәйран каласың. Үзгәртеп корудан безгә килгән чагыштырмача ирек әлегә кадәр соңгы елларда ирешелгән безнең уңышларны билгеләсә, үзгәртеп коруның уңай җилләрен бүгенге көндә кире якка борып җибәрү өчен бездә генә түгел, хәтта бөтен дөнья күләмендә йөгерешеп йөрүчеләрне күрсә, Тәүфикъ Әйдинең йөрәге тагын әрнер, тагын кысылыр иде. Дөньяда капитализм гына җиңеп чыккач, ике төрле системаның каршылыгы бетүгә эчләре пошучыларның ислам динен, ислам динендәге милләтләрне, ислам мәдәниятен мишень итеп алуын иблислек димичә, бүтәнчә ничек тә атап та, аңлатып та булмыйдыр, ягъни ул көчләрнең үз иблислеген яшерү өчен, дөньякүләм яңа дошман уйлап табу тырышлыгымы дип аптырыйсың.

Ләкин, хәтта бер кешенең дә бөтен дөнья халкы белән дусларча мөнәсәбәт коруның зур мөмкинчелекләре хакында ташка басылган – китап булып дөнья күргән инде. Бу – Тәүфикъ Әйди әсәрләре. Аларны кешеләр укыр, халыклар арасында аңлашып яшәүдән дә кадерлерәк нәрсә юклыгын аңлаучылар, иншаллаһ, табылыр.

Бер кешенең гаделлек, хаклык өчен, ирек өчен бик зур өлеш кертә алуын Тәүфикъ Әйдинең гагаузлар иленә барып кылган гамәлләре аша да күрсәтеп була. Гаҗәеп матур исемле Бишалма авылындагы (шагыйрьләр авылы дип тә йөртәләр икән) күптән түгел төзелгән этнографик музейдан

һәм Молдованың башкаласы Кишиневтагы Фәннәр академиясендә берничә генә кеше эшләүче гагауз халкы бүлекчәсеннән башка бернинди дәүләтчелек билгеләре булмаган милләт үзенең Гагауз халык республикасын игълан итә, әле нинди генә каршылыкларны җиңеп! Һәм әлифбаны, һәм мәктәпне, һәм гәҗит-журналны, һәм радиоинформацияне, һәм калган барлык нәрсәне өр-яңадан башлап. Шул эшчәнлекләрнең байтагын күреп торган, үзе дә катнашып ярдәм иткән Тәүфикъ Әйди гагауз халкының ул көннәрдәге геройларын һәм бөтен гагауз халкын да сөекле персонажлар дәрәҗәсендәге югарылыкка күтәреп илһам фантазиясе белән тасвирлый. («Оҗмах утравы». 177–253 б.)

Автор гагаузлар турындагы язмаларын тәмамлаганда, ул, халык өчен шатлык хисләре кичерү белән бергә, үзебезне алардан үрнәк алырга да чакыра: «Әгәр дә алар шулай уңышлы дәвам итсәләр, билләһи, «җиде миллион» дип кабатларга яраткан татарны узып та китәргә мөмкин, чөнки ахыр чиктә эшне сан түгел, сыйфат хәл итә», – ди.

«Оҗмах утравы» китабының «Гөлчәчәкләр илендә кара болыт» бүлегендә тасвирланган милләттәшебез Фатыйма исемле кызның татар әдәбиятына тартылуы, ерак Туна (Дунай) буенда яшәсә дә, «Казан утлары» журналын яздыртып алуы, андагы сөйләм теле белән әдәби тел арасында шактый зур аермалыклар да булу сәбәпле, ярдәмлек сүзлекләр дә соратып алуы хакында хискә бирелмичә, күзгә яшьне китермичә укуы да мөмкин түгел. Шул бүлекне бу мәкаләгә дә тулысынча күчереп язасы килә башлый... Билгеле, күчереп язып булмый, әмма бу кыз бала гамәле хакында бөтен кешеләргә дә укытасы килә... Аннан, гомумән дә, китапны тулысы белән укытасы килә... Һәм бер «Оҗмах утравы»н гына түгел, «Йөртә безне язмышлар»ны да, «Без батырган саен калыккан» китабын да, «Аһ, туган каумем газиз!» исемлесен дә һәм барлык башкаларын да, чөнки ул китапларның һәрберсендә безнең турында язылган.

Алда әйтеп үтелгән Фатыйма исемле кыз Болгариянең Толбухин каласында яши. Тодор Живков заманында милли азчылыкларны кысу, бетерү, мөселманнарны көчләп паспортка христиан исеме белән яздырту газапларыннан да куркып калмыйча, «Казан утлары»н яздырта да инде ул. Тәүфикъ абыйсыннан сүзлекләр, китаплар да сорап ала. Кияүгә чыгып ире Сәгъдәт белән берсе – Тимер, икенчесе Алтай исемле ике малай үстерә. Болгариягә беренче мәртәбә Тәүфикъ Әйдине шушы яшь гаилә чакыра да инде, шулай ук гаиләсе белән бергә.

Дунай буендагы болгарлар белән Идел буендагы болгарларның кардәшлеге хакында бераз үз халкының тарихы белән кызыксынган казан татары белә булыр. Җае туры килгәндә бу хакта әйтәбез, язабыз. Тәүфикъ Әйди, Болгариягә баргач, билгеле инде, болгар вәкилләре белән дә очраша.

Шулар арасыннан язучы Николай Хайтов белән очрашуы истәлекле була.

Тәүфикъ Әйди Дунай буе болгарлары белән Идел буе татарларының кардәшлеге турында бер унбиш минутлык нотык сөйләп ташлагач:

– Кызы-ык, – ди Николай Хайтов.

– Сез боларны белә идегезме?

– Күбесен беренче ишетүем.

Николай Хайтов Татарстанның аерым республика булуын һәм аның кайда урнашканлыгын белмәвен дә таный:

– Менә кардәшле-ек! Боларны элегрәк белсәм, Әрмәнстанга, Грузиягә барганчы, мин, әлбәттә, сезгә килгән булыр идем. Бүтәннәр дә юл салган булыр иде...

Н. Хайтов – чын демократ язучы, мөселман болгарларны, төрекләрне, татарларны нык кысрыклаган елларда, ул аларны яклап, телевидениегә ундүрт серияле фильм сценарием эшләп бирә. Николай Хайтовның 1970 елда «Казан утлары»ның беренче санында «Хикмәтле хикәяләр» исеме белән ике хикәясе басылган булган икән, чынлап та, бик тә хикмәтле, гаҗәп кызыклы хикәяләр...

Бер караганда, Т.Әйди рәхәтләнеп йөргән икән кунакларда дигән фикер дә туарга мөмкин кебек. Ләкин алай ук микән? Беренчедән, Т.Әйди, юлга чыкканчы, фәнни экспедициягә баргандагы шикелле, гамәли һәм гыйльми әзерлек эшләре алып бара, икенчедән, юлда татар китапларын, гәҗит-журналларын тутырган авыр йөген күтәреп, бер дә таныш булмаган җирләргә аяк басулар, кайвакыт каршыларга тиеш булып та, аңлашылмаучылык аркасында беркемнең дә каршы алмавы, шуннан соң, йөген күтәреп, сыгылып килеп, ары-бире йөрүләр, тагын да уйламаганда килеп чыккан башка төрле стресслар дисеңме – безнең сәяхәтче, галим язучыбызны берни дә өркетмәгән. Хәер, безнең борынгы бабаларыбыз: «Юл газабы – гүр газабы», – дип юкка гына әйтмәгәннәрдер шул инде.

Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга Румыниядән килгән татар кызлары Нәдрәт белән Шөкрананы күреп калган идек, без беренче курста чакта алар бишенчедә иде. Алар укуны тәмамлап киттеләр дә суга төшкәндәй юк булдылар. Шуннан соң Румыниядән безгә килеп укучы татарлар булмады. Алар укып киткән елларда Румыниядә дә Болгариядәге шикелле шаукым чыккан – азчылык милләтләрне кысу, аларның мәктәпләрен, башка төрле уку йортларын бетерү – юкка чыгару, үз телеңдә сөйләшергә ярамаулар башланган булган икән. Тик ирле-хатынлы Әнвәр (ул шулай ук Казанда укыган) белән Нәдрәт бирешмиләр, бер генә җирдә дә татар китабын бастырып чыгарырга җай булмаса да, татар әдәбияты, фольклоры мәсьәләләре белән шөгыльләнәләр. Менә шул ике галим

һәм Румыниядә яшәгән татар халкы тормышы белән безнең Тәүфикъ Әйдиебез барып таныша һәм алар турында яза да инде. Бер-берсе белән узыша-узыша эшләүче ике галимне – Әнвәр белән Нәдрәт Мәхмүтләрне автор яратып, хәтта ки шактый персонажлаштырып бирә, ягъни һәр ике галимнең аңа гына хас табигать-холык үзенчәлекләрен ассызыклый, гомумән дә, Тәүфикъ Әйдинең иҗат фантазиясе публицистикасында да уйнап тора: бу жанрда «коры» телгә ул бик сирәк күчә. Гадәттә, авторның һәрбер публицистик яисә юлъязма әсәрләрендә дә геройлар «матурланган» – җете, җанлы, кабарынкы – һәрберсен аерым танырлык итеп сурәтләнгән. Ул геройларны исәпли башласаң, ничә йөзләргә тула икән? Оноре де Бальзак француз тормышыннан образлар галереясын тудырган кебек, безнең Тәүфикъ Әйдиебез татар кешесенә белергә тиешле күпме күренекле вәкилләребез һәм үзләренең барлыклары белән генә дә татар милләтенең яшәвен раслап торучыларыбыз хакында язып, бик тә үзенчәлекле геройлар галереясы тудырды. Тәүфикъ Әйди шуларның барысын да күңел киңлегенә сыйдырган. Аларның барысын да зиһен капкачы астына сыйдырып та бетереп булмыйдыр, бәлки.

Кайнар үгетче, ялкынлы өндәүче Тәүфикъ Әйди кайчакта үзенең позициясенең кайсы якта икәнлеген ачып та салмый. Бу бигрәк тә әдәби әсәрләрендә шулай. Биредә автор тормыш чоңгылларының кайнавына читтән караш ташлагандай яза. «Елан угы»нда, «Иблискә ришвәт»ендә шулай. Байга ялланып («Елан угы»), эсседә какланып, суыгында күгәреп көтү көтүчеләр кызганыч, Бохара дәүләтен саклап каласы иде, бәйсез итәсе иде дип көрәшүчеләрнең җиңелүе кызганыч, Фрунзе турында да иптәш Фрунзе дип сөйләнелә, игелек эшлибез – кан кардәшләребезгә якты көн китерешәбез дип, шунда эшлеклелек күрсәтеп йөрүче безнең милләттәшләр шулай ук кызганыч. Ә чынында кемнең кем икәнлеген ачыклау күбрәк укучының үз ихтыярына куела, ягъни әсәрнең юл араларын укый белү мөмкинлеге дә аңа (укучыга) бирелә. Тәүфикъ Әйдине укучыдан шактый әзерлекле булу сорала.

Талантлы язучыбызның публицистикасында сәнгатьлелеккә ирешүнең күзгә бәрелеп торган ике зур алымы бар. Ул юлъязмаларында, әдәби әсәрләрендәгечә үк, геройларның эчке дөньясын ачу өчен, үткен, җете-җанлы диалоглардан гаять оста файдалана. Нәкъ менә шул кызыклы диалоглар укучыны «котыртып», әсәрнең бер битеннән икенчесенә әйди, чакыра, өнди, ялыктырмый укыта да инде. Икенче үзенчәлек: әсәрдәге бай фактик материал, сирәк очрый торган кыйммәтле информация. Тәүфикъ Әйдинең юлъязмаларын нәкъ менә шул сыйфатлары өчен, иң кызыклы сюжетлы әсәрләрне укыган кебек мавыгып, туктап торырга кирәк булганда да, менә тагын бер генә битне укыйм да, тагын берне генә дип... туктала алмый укыйсың. Һәм ул әсәрләрдән эстетик ләззәт кенә түгел, ә күпме гамь, күпме кичереш, күпме акыл көче, күпме мәгънә, күпме көтелмәгән фәнни-информатик мәгълүмат, күпме милли аң, милли дәрәҗәлелек, милли аянычлылык та, милли үсеш тә аласың. Бәһаләп бетереп булмый. Аның әсәрләренә торып-торып та алдагы буыннар да югары бәһа бирер әле. Хәзерге вакытта, татарны татар итәр өчен, арабыздан вакытсыз киткән авторның әсәрләрен күбрәк укытасы килә. Бу бигрәк тә мәктәп балаларының милли аңын формалаштыруда җитди уңышларга китерер иде...

Тәүфикъ Әйди кызыксынучан язучы дисәк, билгеле, бу гына бик аз булыр. Аның Морат Аҗи фикер-фантазияләрен күтәреп алуы да бер дә гаҗәп түгел. Башларына кирегә әйләндерелгән «тарих гыйлеме» көчләп тутырылган адәм балаларының башкача фикерне дә ишетәсе килүе табигый хәлдер. Башкачарак фикер әйтүчегә, бәлки, Морат Аҗины да кертергә мөмкиндер. Безнең милли байлыгыбыз булып хисапланырга хакы булган тарихчы галимебез Миркасыйм Госманов: «Әлбәттә, тарих дигән гыйлемнең күп очракта ярты ялган белән ярты дөреслек дигән ике өлештән торуы мәгълүм нәрсә», – ди. Морат Аҗи язмаларында да яртысы дөреслек булган очракта бик кызыклы нәрсәләр килеп чыга бит әле. Без әллә ничаклы халык җырларыбызда «кара кашлар, кара күзләр» дип җырласак, байтагында еш кына «аһ, бәгърем, зәңгәр күз» дип тә өзеләбез түгелме?! Ярый, болары, бәлки, шаяру гына да булсын ди. Ә менә хәзер славян булып саналып йөрүче, шул ук вакытта нишләптер хохол кушаматы алган украиннарның кара күзләре, кара кашлары, урыслардан үзгә җырлары, биюләре, киенүләре белән галимнәрне кызыксындырмый мөмкин түгелдер. «Киев Русе»нең асылын ачарга тырышуы белән Морат Аҗи хикәяләү-язмалары игътибарга лаек кебек. Тәүфикъ Әйди моны анык тойган, билгеле.

Шулай инде, тою-сизү зур әһәмияткә ия. Ләкин Тәүфикъ Әйдигә болардан тыш, иң беренче чиратта, ышандыргыч дәлилләр белән эш итү хас. Бу уңайдан язучының үзенең оппонентлары белән сөйләшү-диалогларын тәкъдим итәр идек. Андый сөйләшүләрнең дусларчасы да, бәхәсләшү рәвешендәгесе дә, нык каршы тору шәкелендәгесе дә авторның һәр унбер китабында тулып ята.

Үз халкыңны ышандыру, үз халкыңны син бер халыктан да ким-хур түгел, башкаларда башка булса, бездә бүтән әйбәт сыйфатлар бар дип рухландыру ул – бик авыр эш. Адәм баласы үзенең фактик урынын гына белеп тоярга гадәтләнгән. Ә татарны үткәне белән горурландыру өчен сандугачтай сайрап күрсәтсәң дә бик аз булыр кебек. Шактый газаплы, читен эш бу. Намуслы, фәнни тарих урынына бөтен дөнья күләмендә диярлек ясалма, ялган тарих белән даим-даим җиңеп, иблистәй тантана итүләрен күреп тору йөрәкне әрнетә. Карагыз инде ә, цивилизациянең зур бер өлешен дөньяга бүләк иткән төркиләрне бөтенләй күрмәгәнгә, белмәгәнгә салышып яшәп ятуларын?! Безнең үзебезнең артык дөреслек белән бару галәмәтенең бер нәтиҗәсе дә бит әле бу. Фантазиябезне тамырдан кисәбез... Шул фантазияне элек гөрҗиләрдә, молдаваннарда, әрмәннәрдә күреп шакката идек без, янәсе, ничек

инде алай?.. Шаккатып, авыз күтәреп калучы тагын да без булдык. Шуңа да әйтәсе килә, безнең халыкның рухын күтәрү, милли аңын үстерү өчен, бер түгел, мең дә бер Тәүфикъ Әйдиләребез булса да, бик тәгаен генә булыр иде әле. Үзенең сәяхәтләрендә – элеккеге СССР җирендәме яисә башка чит илләрдәме – кайда гына булмасын, Тәүфикъ Әйди татар милләтен барлау, аңа карата башка милләтләрдә ихтирам, ярату уятырга тырышып йөрүче булды. Ул бу өлкәдә киң күләмдә эш алып баручыларның беренчесе иде. Кая гына барса да, кайда гына сөйләшсә дә, аның уенда, телендә бер генә нәрсә: без үзебезнең зур халык вәкилләре икәнлегебезне тоеп, белеп яшибезме, үзебезне-үзебез ярата беләбезме? Сез, башка халыклар, Аурупада иң беренче булып корыч эретүче, үзәктән җылытудан файдаланучы мәгърифәтле татар халкы барын беләсезме? Җелекләренә төшә тегеләрнең...

Т.Әйди хезмәтләреннән бик күп шәхесләребез хакында да тулы мәгълүмат алып була, чөнки ул алар турында җентекләп өйрәнгән, ирәймичә башкаларны укыган, аннан соң ул бөекләребезнең күбесен үзе барып күргән, шуннан соң гына үз нәтиҗәләрен чыгарып язган. Ул безнең күбебезгә таныш өлкә – әдәбият-мәдәният өлкәсендә эшләүчеләр хакында гына язмаган, дөньяның төрле кыйтгасында яшәп, тормышның, фәннең төрле-төрле юнәлешләрендә казганган татар бөекләре хакында яза. Мәсәлән, Шәүкәт Шиһабетдин улы Ибраһимов турында татарның киң массасы беләдер дип әйтеп булмыйдыр, мөгаен. Ә ул исә СССР чорында радиацион физика буенча иң күренекле галимнәрнең берсе булган икән. Атом-төш реакциясе казаннарының ныклыгы Шәүкәт Ибраһимовның теоретик һәм практик эшчәнлегенә дә барып тоташкан булган икән... Шундый дәрәҗәдәге галимнең 1923 елда Казанда тууын, Завод дигән урамда уйнап үсүен, Исмәгыйль Гаспринский исемендәге 12 нче мәктәптә укуын әйтеп үтәсе килә... Тәүфикъ Әйдинең «Без батырган саен калыккан» исемле китабы татар бөекләрен сурәтләүгә багышланган. «Күк механигы» исемен алган галим-астроном Шәфика Шәрәф, аңлашыла ки, атаклы Шәрәфләр нәселеннән. Галимә белән күрешеп сөйләшкән Тәүфикъ Әйди аның киң карашлы, эрудицияле, яшәешнең бик күп өлкәләре белән кызыксынучы һәм белүче икәнлегенә гаҗәпләнеп сөенә. Иң мөһиме, Шәфика Шәрәф тә, югарыда сүрәтләнгән Шәүкәт Ибраһимов та, туган җирдән еракта яшәсәләр дә, чын татарлыкларын һич кенә дә җуймыйлар. Һәрхәлдә, үзе барып күргән, әңгәмәләшкән бу геройлар хакында авторның фикере шундый. Мондый уңай тәэсирләрне Тәүфикъ Әйди, Мәскәү галимнәре әйткәнчә, механика фәнен «басып алган», берничә буын Нигъмәтуллиннар белән аралашудан да, Әстерханда туып үсеп, Бакуда СССРның халык артисткасы исемен алган Мәрзия Даутованы яхшы белгән кешеләрнең аның турында истәлекләреннән дә ала. Азәрбайҗанда, Бакуда яшәгән татарлар өчен таяныч, ярдәмче булып торган артистка ханым. Тәүфикъ Әйди әсәрләрендә сурәтләнгән Галия Измайлова, Әхмәт Кытаев, Латыйф Хәмиди, Мөслим һәм Ришат Абдуллиннар һәм тагын башка күпләр безнең горурлыгыбыз булып торырга тиешле, билгеле. Ул кешеләрнең даннарын татар файдасына да борып җибәрү безнең үзебездән дә тора. Кайбер халыклар шундый мөмкинчелектән ничек оста файдаланалар. Ул халыкларның безнең тирәдә үк булганнарын әйтеп үтеп тә була: гөрҗиләр, әрмәннәр, яһүдләр. Төрекләр дә ул җәһәттән бигүк төшеп калганнардан түгел бугай. Төркиләрдән без, татарлар, бер-беренә елышу ягыннан әлегә бер дә мактана алырлык урында түгел.

Тәүфикъ Әйдигә Урта Азия, Кытай эчендә калган Көнчыгыш Уйгырстан турында язу да җиңел бирелә, чөнки ул аларның телен белә, казах, үзбәк, уйгырларның китапларын төп нөсхәсендә укый, аларның холык-фигыле аңа якын, аңлаешлы. Билгеле, иң беренче итеп язучы үзенең игътибарын анда яшәгән милләттәшләребезгә юнәлтә.

Тынгысыз язучыбыз әсәрләреннән төрек кардәшләребез хакында да күп мәгълүмат алып була. Бүгенге көндә төрек теле безгә якыная төшсә дә, һәркем аны белеп бетерә алмас инде, белгән очракта да шагыйрьләре турында гына да берәр нәрсә ачыкларга теләсәң дә, йөзләрчә төрле шәкелдә чыккан антологияләрен актарырга туры килер иде, бу гел дә мөмкин эш түгел, әлеге очракта да безнең язучыбыз китапларында байтак материал бар.

Авторның Балтыйк буе җөмһүриятләре хакындагы язмалары да кызыклы. Укы гына, әллә никадәр мәгълүмат, эстетик ләззәт ал. Аз санлы латыш, эстон, литва халыклары милли гәҗит-журналларын СССР заманында бер үк исемдәгесен гаилә саен бер генә данә түгел, икешәрне яздыртып алган өчен дә әле хәзер үз дәүләтләрен торгызып яталар дисәк, ялгыш ук булмас, чөнки алар калган барлык башка гамәлләрендә дә нәкъ менә шул милли гәҗит-журналларына карата булган мөнәсәбәттән чыгып эш иттеләр. Әйе, күп сөйләшми генә үзләре өчен кирәкле эшләр башкардылар.

Тәүфикъ Әйди иҗат юлының башында ук бу зур эшләргә үзенең көче җитәсенә, максатына ирешәсенә ышанып, белеп, әзерләнеп керешкән дигән идек. Аңарда хыял белән тормышчанлык икесе бергә органик, бер-берсенә карышмыйча, бергә үрелгән. Әйе шул, туган халкың өчен эчеңдә янар утың таудай булса, ул сине нинди генә Раштуа салкыннарында да суытмый, җылытып тора, ләкин җылытып кына да калмый шул, яна-яна бөртегеңә хәтле яндырып та бетерә. Гөлт итте дә сүнде Тәүфикъ Әйди, янудан яктылык булып әсәрләре калды, ләкин кызганыч ки, күпмесе менә-менә каләмнән төшәм дигәндә язучының гомере белән бергә өзелгәндер, кәгазьгә төшми дә калгандыр.

Әгәр дә татар халкы алга таба да үзен зур халык итеп күрсәтәсе килә икән, Тәүфикъ Әйдине онытмау, хөрмәтләү, кадерләү белән бергә, аның турында башкаларның да исләренә төшергәләп тору

хәерле булыр иде. Ул булган җирләргә, халыкларга моны җиткереп тору безнең үзебезгә дә отышлы булачак. Ул эшләр киләчәктә Тәүфикъ Әйди укулары шәкелендә дә булырга мөмкиндер. Язучыбыз булган җирләрнең берәр генә булса да вәкилен шундый мәҗлесләргә чакыру, күңеле чуарлыктан онытырга гына торган дөньяның зиһенен безнең тарафлардан да уратуга бер сәбәп тә булыр иде.

Язманы Сибгат Хәкимнең «беренчеләр өзә үзәкне» дигән шигъри юлларын искә төшереп тәмамлыйсы килә. Бөтен дөнья татарларын барлау эшен Тәүфикъ Әйди башлады. Әйе, ул беренче иде. Татар өчен әле күпме эшләгән булыр иде дисең дә, йөрәк кысыла...

*2004*

**АЯЗ АБЫЙ ҺӘМ...**

Беркөнне төштән соң, кичкә таба, бакча сукмагыннан Равилнең кем беләндер сөйләшеп, өйгә таба якынлашуы ишетелде. Җәйнең хозурында мин дә җәй эчендә – ишек төбендәге өстәлдә яшелчәләр тазартам.

Алар килеп тә җиттеләр. Равил янында җыйнак бодай көлтәсенә охшаган дияр идем... берәү, юк, бу кешедә алтынсу төсләрдән башка кызгылт бакыр җирлекләр дә бар иде, гүяки бодай белән тары катыш урып бәйләнгән көлтә. Ни өчен көлтә? Чөнки тышкы охшашлыктан башка, әллә кайдан эчтән бәреп сизелеп тора – бу уңыш кешесе, тук башаклы, ашлы... Кунак бер кулы белән ишек яңагына таянып, мин аңга килгәнче, Равил берәр сүз әйткәнче: «Сәлам, килен!» – диде. Шуннан соң Равил: «Аяз абый Гыйләҗев», – дип атады яңа танышыбызны. Әйе, ишеткән бар андый язучыны, укыган да бар. Таныш исем, таныш.

Аяз абый дигән кеше синең өеңә хәтле үк килеп җиткәч, матур, үткен сүзләрен тәгәрәтеп җибәрмичә калмый икән:

– Чибәр татар кызына өйләнгәнсең, парин, шәп!

Аннан борын яфракларын чак кына киереп, һаваны иснәгәндәй (артист та икән әле үзе) итте дә:

– У-у, итле аш пешерәсез, уңган икәнсез. Хәзерге заманда итле аш пешерү инде ул, парин, үзең беләсең...

Ул вакытта бу сүзләр мәзәк кебек тоелса да, хәзерге акыл белән уйлаганда искә төшә. Базарда ит чиратында торганда апайлар, түтәйләр сөйләшәләр иде, бер сум биш тиенгә кысыр аш – итсез аш пешерәләр икән. Кысыр ашның бәһасен шулай төгәл әйтәләр иде. Ә менә итле аш пешерү аерым очракларда гына. Димәк ки, Аяз абыйның «артистлануы» тышкы бизәк кенә түгел, халык тормышын ул эчтән белгән.

Бу көнне итле аш пешкәнен шулай артистланып күрсәтсә дә, ай-вайлап чакырсак та, табынга калмады:

– Нәкыя апагызның токмачы казанда сикереп калды, булмый, парин.

Шул көннән соң, Аяз абый, аның гаиләсе белән шактый гына аралашып яши башладык. Иделдән тоткан балыкны бик ныклап салкын суда чистартып-тазартып, ипигә сипкән хәтле тоз сибеп тозлап, биш-алты сәгатьләп салкын урында тотып алып кыздырсаң, бик тәмле була икән. Әгәр дә көнбагыш маенда кыздырмыйча, ак майда кыздырсаң, балык телемнәре-кисәкләренең төсе матур алтынсу була икән. Балыкны алдан бераз тозлап торуны Аяз абый үзе өйрәтә, ә менә матур алтынсуны – Нәкыя апа. Хәер, безнең өйгә көнбагыш мае бөтенләй дә керми – исен яратмыйлар. Ләкин балыкны Нәкыя апа барыбер матуррак итеп кыздыра, өйрәнәсең инде үзең дә, өйрәтүче булып торганда. Аяз абый белән Нәкыя ападан шифалы белемнәр, тормыш белемнәре сөзелеп-сөзелеп керде безгә ул заманнарда. Чөнки Аяз абый белмәгән нәрсә бик сирәк иде бугай. Үзе туплаган тормыш тәҗрибәсе белән гаять дәрәҗәдә юмарт уртаклаша белгән сирәк кешеләрнең берсе иде ул Аяз абый. Бергәләп балык каптырулар да, Нәкыя апаның матур, тәмле итеп кыздырган балыгын ничәмә мәртәбәләр авыз итүләр дә булды. Өстәл тирәли тезелешеп утырабыз. Безнең белән бергә Аяз абый белән Нәкыя апаның өч улы утыра. Байлык та байлык, өч малай тагын да зуррак байлык. ...Аларның бакчасында помидорлар да кешенекеннән эрерәк... Безнең бакча исә үзебез Әлмәттә яшәгән арада нык куерган, алмагачлар ифрат та үсеп, ябалдашланып күкне томалаган, күләгәләнгән – яшелчәгә әллә ни уңайлык калмаган. Шулай да агачларны кисәргә кул бармый – үссеннәр... Аяз абыйның кече улы Рашат, Вакыйф Нуруллинның улы Нияз белән безнең улыбыз Алмаз озын җәй көннәрендә хозурда бергәләп уйнап үстеләр. Аллага шөкер, борчу китермәделәр. Сорамыйча Иделгә барып төшмәделәр, тамырларын җәеп яткан тимер юл ягына чыкмадылар. Күршеләрнең капка-коймасына зыян-зәрәт салмадылар. «Улым, матур уйнагыз», – дип җибәрә идем. Бусы инде минем әнием сүзләре. Безнең балачакта иртәдән үк тә, көндезен дә безгә йөкләнгән эш күп иде. Кичен исә соңгы сарык бәрәнен, каз-үрдәк бәбкәсен, бозауны, сыерны алып кайтып әни хозурына тапшырмыйча, безнең эш бетми, тик бары шуннан соң гына авыл баласы шаулап-гөрләп уйный иде. «Матур уйнагыз, кызым», – дия иде әни. Бу өч сүзгә, кеше каралты-курасы тирәсендә йөрмәгез, артык шаулашмагыз, бер-берегез белән әрләшә, үпкәләшә күрмәгез һәм

әниебезнең сөт чүлмәкләрен, чиләкләрен урнаштырып, җыеп-юып бетергәндә урыныбызга кереп яту мәгънәләре дә сыйган иде...

Аяз абыйның пьесалары буенча куелган спектакльләргә йөрибез. «Эңгер-меңгер»не карыйбыз. Безгә ошый, бик ошый. Авторның һәр сүзе мәгънәле, тирән, аскорма белән каймаланган, хасиятләнгән. Ә менә тамашачы авыррак кабул итә кебек. Тамаша залының сулышыннан шул нәрсәне сизәргә була иде шикелле. Безнең халыкның бәласе дә шунда бугай. Җиңелрәк килеп кергәнне ярата. Тамашачы бездә бертөслерәк, аслам-катламнары аерылып торганы бигүк күренми. Бу нәрсә безнең язмышыбызны да билгели бугай, тарихыбызны да яза... Табигатьтә кыска гына вакытта булып ала торган эңгер-меңгернең татар тормышына билгесез бер озак вакытка төшеп утыруы Аяз абыйның эчен пошыра, аны үрти, җанын кыйный иде. Үз тормышына җете буяулар гына салып яшәүче язучыбызның сорылыкны җене сөйми иде. Шуңа күрә ул иҗатында һәрвакыт андый нәрсәләрне халкыбыз күңеленнән алып ташларга, татар тормышына җетерәк буяулар сеңдерергә тырышып эшләде. Көндәлек тормышта гади, гадәттән тыш җор күңелле, үткен телле Аяз абый әдәбиятка көнкүреш объекты итеп карамый иде, ул әдәбиятның татарның идеологиясе, фәлсәфәсе нигезе, өскормасы икәнлеген җаны белән аңлый, тоя, үзен шул корылманың ташчысы-төзүчесе икәнлеген белеп яза иде. Соңыннан Аяз абыйның халык яратып кабул иткән пьеса-спектакльләре күп булды, ләкин автор тамашачы артыннан киткәндер дип әйтергә тел әйләнми.

«Өч аршын җир»не качырып-посыбрак укуыбыз хәтердә калган. Бу әсәрнең язмышы гыйбрәтле булуын беләбез инде – безнекеләр басарга курыкты, әсәр башта... Мәскәүдә чыкты... Ә менә «Җомга көн, кич белән» шаулап-гөрләп безнең тормышыбызга килеп керде – аны рәхәтләнеп «Казан утлары»ннан укыдык. Бибинур карчыкның яшь рәискә гашыйк булуын язучының әсәрендә кулланган бер шартлы алым икәнлеген тоеп укыйсың. Гомер йөзендә бер генә дә яхшылык-яктылык, миһербанлылык күрмәгән, ә үзендә исә шул сыйфатларны саф-таза килеш саклаган изге җан буларак, әгәр дә ул хыялланган, өмет иткән яхшылык, яктылык, миһербанлылык һәм мәхәббәт аның алдына тау сурәтендә килсә, Бибинур тауны да хасиятли, тәрбияли, бага, чын күңеленнән ярата башлар иде... Аяз абый безгә – укучыларына – шуны тоярга, аңларга, күрергә, алай гына да түгел, Бибинур карчыкның (!) хисләре белән янарга мөмкинлек бирде. Язучының үтәлгән төп бурычыдыр һәм җыеп алган уңышыдыр инде бу. Бибинур карчыкның хисе-холкы минем үземә дә якын. Бибинур карчык кебек мин дә яктылык-яхшылык күрсәм, шуны бага, хасиятли, йомырка өстендә утырган каз кебек өф-өф итә башлыйм, һәм ул өф-өф иткәнем адәм баласы булып, артык иркәләп, «бозып» та куям... Ә Нәкыя апа, бөтен уңганлыгы, мөлаемлыгы, чибәрлеге белән бергә, үзенә авызлык кидертергә бер дә ашкынып тормаган Аяз абыйны да, бик сирәк-сирәк кенә булса да, йөгәнләбрәк алырга да кулыннан килә иде...

Аяз абыйның «Җомга көн, кич белән» әсәре татар тормышында киң яңгыраш алды. Шул исемдә телевизорда тапшырулар башлап җибәрү һәм аның байтак еллар милли агарту программасы булып танылуы үзе ни тора! Татар кешесе шул сөйкемле-интеллектуаль тапшыруны көтеп алып, тантаналы-горур рәвештә телевизор каршына килеп утыра иде! Ә менә хәзер аптырау дисәң дә аптырау – безнең тамашачы тавыклар белән бергә ятып йокларга тиеш буламы? Ник дисәң, кич белән безнең телдә, безнең тормыштан тапшырулар юк. Көндез, әби-сәбиләргәдер диптер инде, туган телебез бераз яңгыраштыргалый да, шуның белән вәссәлам. Кичен туган телдә яшьләрне кем тәрбияләргә, аларга матур, чын татарча эстетик ләззәтне кем бирергә тиеш икән? Кырык яшьлекләр, илле яшьлекләр нишләсен? Үтерергә-бетерергә өйрәткән чит ил фильмнарын бертуктаусыз карасыннармыни? Кайчакларда бөтенләй дә аптырап каласың. Рәшит Ваһапов, Хәйдәр Бигичев, Илһам Шакировның классик һәм шул ук вакытта халыкчан традицияләрен дәвам иттерүче көчле, моңлы тавышлы җырчы, Татарстанның халык артисты Мирсәет Сөнгатуллинның нык әзерлек, зәвык белән үткәрелгән юбилей кичәсе концертын телевидениенең яздыртып алмавын ни дип тә атап бетереп булмый. Моңлы җырларны яраткан халкыбыз әле һаман ул концертны телевизордан күрәбез дип ышанып көтеп тора... Мондый җитлекмәгән караш бер М.Сөнгатуллин иҗатына гына кагылмый, бөтен чын халыкчан сәнгатькярләребез, язучы-шагыйрьләребез шундый үги бала хәлендә. Ни әйтәсең, Аяз абыйның җитмеш биш яшьлек юбилей кичәсен дә зәңгәр экранда күрү насыйп булмады. Чын әдәбият-сәнгатьне әйдәләүне (пропагандалауны) оныту – татар халкының яшәү һәм яшәп калу проблемасын оныту ул. Бүгенге көндә татар халкының илдәге хәле безнең тарафтан аның рухи тормышына гаять игътибарлы булуны сорый. Бу мәсьәләләр нәкъ менә А.Гыйләҗев иҗаты биеклегендә, аның рухы югарылыгында чишелеш көтә...

Менә шулай, Аяз абый турында сөйли, уйлый, искә ала башласаң, милли моңнарың-проблемаларың үзәкне өзеп калка да чыга, калка да чыга. Үзе булмаса, аның әсәрләре безнең йокымсыраргa торган күңелләребезне уятучы милли чаң-кыңгырау икәнлеген беребез дә онытмасак иде. Колакларыбыз шул тарафны тыңлаудан күңелләребездә милли хисләр даим кузгалып торсын иде.

*2004*

**РУХИ БӘЙЛӘНЕШ**

Нурихан Фәттах дигән дөнья бар. Бу дөнья бөтен татар тормышын үз эченә ала...

Нурихан абый әдип буларак иң беренче булып безгә болгар дөньясын кайтарды. Бу эшне ул «Әтил суы ака торур» романын язып, безгә – татар укучысына бүләк итү рәвешендә башкарды. Шул елларда бу романны укуның кызыклары, мавыктырулары, өр-яңа бер тәэсир бирүләре әсәрне басылып чыккан көннәрендә укучы гаять көчле кичерде. Агай-эне, интеллигенция, язучылар, сәнгать әһелләре арасында борынгы Болгар дәүләтенең башкаласы Болгар шәһәре калдыкларын-хәрабәләрен барып күрү теләге шул вакыйгадан соң нык көчәеп китте, дөресрәге, бу хәл шуннан соң башланды дисәң дә, хак булыр. Без дә бардык. Хәйраннарга калып, вәйраннарга калган тарихыбызны карап йөрдек.

Мин үзем, Болгар артындагы Әлки районыннан булуым сәбәпле, бәләкәйрәк чактан ук, Болгар турында безнең әби-апаның, әнинең, бабайларның сөйләүләрен ишеткәли идем. Болгарга һәм әле тагын Биләргә барып, баерак елларны – сарык, ябыграк елларны әтәч-тавыклар чалып кайтулары турында да сөйләшүләр була иде. Бу эшләр яшертен эшләнә. Сарык белән ничегрәк үткәннәрдер, белмим, ә култыгына тавык кыстырган әби-сәбинең җәяүләп кенә Болгарга элдертүен, аерым саклап торып кумасалар (андый хәлләр дә булган), кем сизсен?..

Соңрак тагын да Болгарга барып, яңгыр белән бергәләп күз яшьләрен коюлар булды. Шулай йөрәк әрнетеп кайткannан соң, безнең Болгар яклары һәм Болгар шәһәре хәрабәләре хакында шактый күләмле мәкалә язып, «Идел» журналында бастырган идем. «Әтил суы ака торур» романы кузгатып җибәргән безнең хәтер елгасы менә шулай яңарып, тирәнәеп китә башлады. Нурихан абыйдан соң, гомумән дә, Болгар турында язу инде ачылган, тазартылган бер плацдармда, мәйданда эш алып бару кебек күренешкә әйләнде. Нурихан абый *б е р е н ч е* иде.

Нурихан абый миңа үзенең «Шәҗәрә» китабын автограф белән бүләк иткән иде. Бу хезмәттә галим авторыбыз тарихи-лингвистик этимология чытырманлыкларын аралап, безнең төрки-татар дөньясы өчен дә тәрәзәләр уеп йөри. Бу өлкәдә дә бик күп төрки-татар тамыр-эзләребез тарих тарафыннан комга күмдерелергә, суга чумдырылырга тырышылган. Моңа чаклы тарихи-этимологик лингвистика өлкәсендә дөнья туплаган гыйлем һәм тәҗрибә белән коралланып, Нурихан абыйда гына булган интуициягә таянып язылган хезмәт ул «Шәҗәрә».

Үзенең эзләнүләренең башында безне «молоко» – мал агы, «творог» туар агы дип, галим әдибебез и канатландырган, шатландырган иде. Шатланырсың да, бигрәк тә совет елларында төркиләрдән, төрки-татарлардан, сездән он суы да калмаган, тоз суы да калмаган дигәндәй, сездән бернәрсә дә калмаган, сез беркем дә булмаган, ә әшәкелек оясы булгансыз дип, безнең башка тарих дәреслекләреннән җай булган саен тукып торалар иде, үзебез гомер буе товарищ – тауарда иш булып яшәгән сыман булсак та. Аннан соң Нурихан абый ачкан сүзләр күп булды. Ә менә бервакыт Нурихан Фәттах «мал агы», «туар агы» дигән сүзләрдән, ягъни «молоко», «творог» төрки тамырдан яралган дигән фикереннән баш тарткан дип әйттеләр. Мин түзмәдем, моны үзеннән сорадым. Ул бу хәлне раслады. Монда инглиз теле дә килеп керә, дип әйтте. Инглизләрдә «милк» – молоко – сөт. Дөньякүләм белемне үзләштергән, күп фактик материаллар белән эш иткән галим-әдибебезнең фикерләү, чагыштыру мөмкинлеге, энҗеләүнечкәләү үлчәве сизгер иде, билгеле. Ә шулай да миндә «мал агы», «туар агы» үзебезнекедер дигән үҗәтлек калды әле. Безнең якларда бу гыйбарәләр бөтенләй үк төшеп калмаган әле. «Сыер агы» дип әйтү гадәти санала. Терлек-туарга мал дип карау, әйтү нык сакланса да, нишләптер, «мал агы»н ташлап, «сыер агы» диләр. Аннан соң бит инглизләр дә әллә кем түгел. Шуларның бер галиме «Библийские холмы» исемле китабында шулай ук сүз мәгънәләре турында гәп кора. Ул тикшергән сүзләр арасында төрки булганнары аз түгел, күзгә бәрелеп торалар. Бу галим аларның берсен генә дә төрки дип авыз ачмый, әллә кемнәргә китереп бәйли, төрки дип атарга уена да килми. Искиткеч евроцентризм дигән авыру!

Бездә «яхшылык эшлә дә суга сал» дигән әйбәт мәкаль кайвакыт артыграк та тормышка ашырылган, ахрысы. Алтын Урда ханнарының үзләре, халкы мөселман була торып, чиркәүмонастырьларны өф-өф итеп саклауларын гына кара инде син. Ахыры ни белән бетте... Мәскәүләрнең Казан ханлыгын, башка татар ханлыкларын кулга төшерүдә беренче булып оештыручы, катнашучыларның кемнәр икәнлеге искә төшә... Яисә борынгы төркиләрнең эзлекле тарих язмаулары. Корычны иң беренче коюың, кәгазь акчаны иң беренче куллануыңны булса да ташка басып калдыр идең, ичмаса... Ә менә Көнбатыш дигән җир мактанчык. Алар гына барысын да эшләгән, булдырган икән. Монгол, төрки гаскәрләрнең, аларның ханнарының ерак көнчыгыштан хәтле тәре күтәреп килмәүләре, Болгар – Идел буйларына, Урта һәм Үзәк Азия турыларына җиткәч, мәҗүсилектән тоташ мөселманлыкка күчүләре өчен, Монгол иленә, Ерак Төркестанга, Кытайга хәтле миссионер булып йөргән Папа монахларының тырышлыклары юкка чыкканы өчен төркиләргә каршы тоташ дошманлык юлына басканнар икәнлеге килеп чыга. Төркиләр христиан (бигрәк тә католик) булып килсәләр, бер дә варвар дип сүз чүбеге чәйнәмәсләр иде әле.

Бер эгоистик караш хакында гына дөнья цивилизациясе киштәләрендә төркиләргә урын бирмәскә тырышу каршылыгы белән бергә, халкыңның шул дөнья алгарышында шактый гына өлеше барлыгын исбатларга тырышып, исәпсез-хисапсыз тарихи катламнарга чуму печән кибәненнән югалган инәне

эзләү белән бер дип әйтү генә дә аз булыр. Нурихан Фәттахның лингвистик эзләнүләре таш гасырдан алып бүгенге көннәргә хәтле вакыт чикләрен үз эченә ала. Бу эзләнүләрнең объекты – бөтен дөнья халыкларының теле. Таш гасырдан бүгенгегә кадәр. Шуңа бәйләнгән рәвештә килеп чыккан сорауларга җаваплар эзләү юлында тагын да күпме башка фәннәр катламын актару.

Шулай итеп, галим язучының дистә еллар буе эзләнүләре нәтиҗәсе булып, «Шәҗәрә»дән соң «Язык богов и фараонов» дигән хезмәте дөньяга килә. Әле кайчан гына «Шәҗәрә»дәге Фест дисбесен борынгы авазыбыз – хәбәребез итеп күтәреп йөргән идек, «Язык богов и фараонов» хезмәте белән Нурихан Фәттах безне бөтен дөнья киңлекләренә алып чыкты, аның да вакыт ягыннан иксез-чиксез гасырларны эченә алганына.

Тарихи-лингвистик этимология юнәлешендә эшләвен дәвам иткән хәлдә, Нурихан абый безне ике китаптан торган «Сызгыра торган уклар» исемле романын язып шаккатырды, үсендерде, үстерде, чөнки бу әсәрдә безне борынгы заманда кендегебез береккән җиргә – ерак Төркестанга һәм Кытайларга хәтле алып барып җиткерде. Моңа чаклы кырык йозак белән бикләнгән кебек тоелган җирләр, юллар, хәлләрнең шаһиты булгандай тойдык үзебезне. Бу совет чорында, татар бетә, бетә дигән елларда язылганын искә алсак, Нурихан Фәттахның иҗатына бәһа биреп бетерә алмаячагыбызны аңларбыз. Бүгенге көндә дә бернинди информация бирмәскә тырышып яшәгән кытайларның да үткән-киткәннәренә дә күз салып кара әле. Нурихан абый тагын беренче булды.

Нурихан абый күбрәк өйдә булып, өйдә язып утырыр иде. Ул сирәгрәк күренер иде. Күренер иде дим, чөнки совет заманында дөнья хәтле нәрсәләр була иде: профсоюз, комсомол, коммунистлар җыелышыннан алып үзара ярдәмләшү кассасы җыелышларына кадәр йөрисе иде. Син бөтенләй дә комсомол яисә коммунист булмасаң да. Язучылар өчен бу җыеннар, билгеле, Язучылар берлеге бинасында үтә иде. Ләкин кызыгы шунда: Нурихан абый үзе булмаса да, аның рухи энергетикасы Дәрвишләр бистәсеннән үк сизелеп, тоелып тора иде. Язучылар җыелышында Нурихан Фәттах ни әйтер дигән сыманрак сүз чыкмый калмый иде. Татар язучыларына (бу – татар халкына дигән сүз) аның тәэсире искиткеч зур булды. Бу тәэсирне, шикләнмичә, Нәкый Исәнбәт, Әмирхан Еникиләрнең энергетик көче белән тигез дип хисапларга мөмкиндер.

Җае чыккан саен мин бахырыгыз да Нурихан абый ышыгына-яктылыгына елышканмын булып чыга. «Милли түбәтәй... һәм...» исемле бер мәкаләм Нурихан Фәттах дип башлана. Әле күптән түгел, быелгы елның июль аенда, «Татарстан» радиосында үткән бер әңгәмәдә дә мин сүзне туган телебездә сүз мәсьәләсендә Нурихан Фәттах кебек принципиаль буласы иде дип тәмамладым. Редактор-мөхәррирләрнең үзләрен чиновник сыман тотканнары да Нурихан абыйдан бераз шүрлиләр иде, дөресрәге, сүз, туган телебездәге әдәби сүз мәсьәләсендә Нурихан Фәттахның принципиальлегеннән җиңеләләр иде. Минем Нурихан абыйның «Сызгыра торган уклар» романындагы кайбер детектив алымнар турында язасым да килеп китә иде. Кызык бит. Тарихи роман. Ә детектив элементлары тулып ята кебек тоела миңа. Курыктым. Хата ясарсың да, аннан Нурихан Фәттах каршында җавап бир...

Мин, үземнең бер поэмамның исемен инстинктив рәвештә «Шәҗәрә» дип язып куйганнан соң, Нурихан абыйның «Шәҗәрә» китабын тагын бер кат кулыма алып, мондый исемне кушарга лаекмы минем әсәрем дигәндәй, әйләндерә-әйләндерә караганымны төгәл хәтерлим. Казан ауганнан соң, ундүрт яшьлек бер кыз баланың трагик маҗаралар кичерә-кичерә Ходай рәхмәте белән исән калып, Казаннан еракта, Чулман елгасы ягындагы бер авылда безнең шәҗәрәне янәдән тудыручылар сафына басуы хакындагы әсәрем турыдан-туры Нурихан Фәттах иҗаты тәэсиренә килеп бәйләнгәнен тәнем-каным белән тоям.

*2007*

**БИЕКЛЕККӘ ЧАКЫРУ**

Бүгенге татар шигъриятен укып, аның үсеш тенденцияләрен белеп, чамалап баручылар шагыйрь Зиннур Мансуров иҗатының үзенчәлекле, эчтәлекле, хисси-фикри яктан чакырулы, әсәрләренең әдәби эшләнеше гүзәллек кануннарына хыянәт итмәве белән аерылып торуын төшенәләр булыр.

Көфер сүзләр килсә ялгыш,
Авызга ... икмәк тула.

«Дәһрилек» исемле шигырьнең шул ике юлын укыгач, әллә нишләп китәсең, шәраб белән шәрәф-ләнмәсәң дә, айнып киткәндәй буласың. Икмәкнең олылыгын бу хәтле дә өздереп, кисәтеп һәм тетрәндерерлек итеп әйтүче юк иде шикелле әле. Икмәк күтәрмәс сүз сөйләп, икмәк хакын хурлаучы гамәлләр кылучы адәм баласына утырып, озак итеп уйларлык хәл бу. Гомумән дә, икмәк кадерен санламаучы заманнар килеп яткан да, шигырь юллары чаң булып та яңгырый. Әсәргә исем булган дәһрилек сүзенең мәгънәсе дә, нык киңәеп, гомумиләшә.

Тагын да шигырьгә сүз бирик әле:

Тарихтан да картрак лачын күзләрендә
Чагылмыйдыр нинди видеоязмалар!..

Тере шаһит булганнары өчендерме,
Хәтта шушы аулакта да аз алар.

*(«Иске Казан»)*

Шигырьне укудан туган хисләр бизәкле-ялкынлы, уйлар – катлаулы. Иң беренче тарихтан да элгәрерәк заманның табигате күз алдына килә. Әле кеше юк. Ә менә кошлар бар! Алар мәңгелек. Һәрберсе галибанә-горуранә агачтамы, тау кыясындамы утыра, тик кешесез дөнья үзәк өзгеч күңелсез булган кебек тоела... Хисләр шулай кайнаганда, уйларыбыз үзебезнең хәлгә – тарихыбызга әйләнеп кайта: кирмәнне җимергәндә күреп торучы шаһитләр булмасын дип, гүяки борынгы кошлар – лачыннар да кырылган... Югыйсә күзләрендә сурәтләнеп калган вәхши дәһшәт күренешләрен кемнеңдер укый алуы мөмкин. Уйлап карасаң, чыннан да, бар андый кешеләр. Ул – шагыйрьләр. Борынгы кош күзендәге искәртүләрне шагыйрьнең күзләре генә түгел, йөрәге дә күрә.

Зиннур Мансуровның бик күп шигырьләре хәтер яңарту булып яңгырый. Адәм баласына хәтер яңартып тору табигатьтән килгән бер бурычтыр ул. Ә безнең халыкта бу гамәл бабаларыбызның иң тәэсирле мөрәҗәгате кебек яши. Тарихыбыз да шуңа өнди:

Ачындырды: очындагы
алтын ае ... киселгән!

Югарыдагы юллар «Беренче киселгән ярым ай» шигыреннән. Бәгырьләребезне телгән атаклы Казан бүрегенең аяныч-ачы хатирәсе бу.

Мин «Күңел сәфәре» китабын укуны дәвам итәм. Шигырьләр, шигырьләр. Алар дүрт кәрванга тутырып сәяхәткә озатылган. Дүрт кәрванга ияреп-кушылып, берсеннән икенчесенә күчә-күчә сәяхәт итәм, аерылып китә алмыйм, әйләнәм дә тагын килеп кушылам. Беренче кәрвандагы шигырьләрне кабат-кабат укыйм.

Менә «Дүнү» шигыре. Биредә шагыйрь тарихи-чагыштыру алымын эшкә җигә. Безгә бик таныш Йосыф пәйгамбәр, Шекспирның король Лиры, үзебезнең милли геройларыбыз Җанзәһрә белән Җантаһир, бик тә билгеле Иисус – Гайсә пәйгамбәр.

Безнең заманда да боларның һәрберсенең кабатлану-дәвамнары-игезәкләре бар икән ич. Әмма аларның хәле хәзер кызганыч-мескен, ә элек булган галибанә сыйфатларының бу вакчыллык заманында эзе дә калмаган. Алай гына да түгел, Гайсә пәйгамбәр, мәсәлән, бөтенләй деградация кичергән: ул инде хаклык өчен җәзаланучы түгел, мескен рольгә кергән – кадакланучы түгел, ә кадак сатучы. Ләкин безнең төрки-татар күңеленә иң тигәне:

Әллә кайда җиде баҗа улый:
«Борадәрләр идек бүрегә...»

«Дүнү»дә яралар төрле төеннән чишелеп ачылса, «Ачык рояль»дә игътибарны бер ноктага – рояль эчендәге дулкын-упкынга каратып, юнәлтеп, җәрәхәтле сеңер – кеше күңелен янар тау авызы куышлыгында күргәндәй буласың.

Кош очар биеклеккә менү авырмы? Юктыр, бүгенге заманда авыр түгелдер. Тик без ул биеклеккә күңелебез белән менәргә тиештер. Кайчак каты бәгырьле кеше дә бер мизгелдә күңеле йомшарып, рухланып, биеклеккә – изгелеккә омтылырга мөмкиндер. Ә менә йөрәгеңне изге гамәлләр генә кылу хасиятендә тоту – һәрвакыт биеклектә тору – фидакарьләр батырлыгы («Кош очар биеклек»).

Шагыйрьнең «Күңел сәфәре»нең беренче кәрванына кайсы шигырен куюы да кызыклы. Тугыз гына мисраг-юлдан торган ул шигырьнең исеме «Яшьлек кайтавазы». Яшьлек кайтавазы үткәннәргә: яшьлеккә, балачакка хыянәт итмәскә чакыра. Анда сурәтләнгән каен башындагы – кояшка якынрак торган малай күз алдыннан китми. Шигырь сискәндерә, кисәтә, аянычы шул: кырыс укытучы – тормыш каен башындагы малайны аннан сыпырып төшерергә тырыша, әмма адәм баласы бәләкәч чагындагы сафлыгын сакларга омтылырга тиеш. Алай булмаса, нигә кеше булып яратылган соң ул? Кешелек дөньясының төп бурычы да шул түгелме соң? Шагыйрьләр дөньяны төзәтмәк утында яналар дигән фикерне З.Мансуров менә шулай үзенчә һәм бик тә үтемле итеп раслый.

Сүз уңаеннан шуны да әйтеп үтәргә кирәк: шигырьләрендә генә түгел, зур күләмле әсәрләренә – поэмаларына салган төп җегәр дә – дөньяны төзәтмәк уе. «Ике еглау» поэмасы да бу яктан бик гыйбрәтле һәм тәэсирле.

Шигырьләрендә авторның фикер һәм хис диапазонының киңлегенә гаҗәпләнәсең. Алардагы тирәнлек, шигырьнең тышкы бизәкләре, көй-рифманың көтелмәгәнчә төрле, алай гына да түгел, еш кына өр-яңалыгы укучыны кабат-кабат әсәргә әйләнеп кайтырга чакыра, кызыксынуын арттыра. Шул ук вакытта үзенең генетик-психологик үзенчәлеге аркасында, күрәсең, кайвакыт милли-тарихи хаталар да ясап яшәүче халкыбыз турында бүгенге көндә булса да«Нигә без Зиннур Мансуров шигырьләренә салынган акыл көче белән ныграк сугарылмыйбыз икән?» дигән наив уйлар да килә кайчакта... Тик автор акыл сатмый, ул безнең үз гамәлләребезне генә ачып сала, пәрдәсе кормаган ачык тәрәзә шикелле – барысы да күренеп тора, әйбәте дә, бигүк алай түгеле дә...

З.Мансуров рәсем шигырьләр остасы да. Биредә аның максаты укучының хис-тойгысына тәэсир итү. Көз. Җилдә тирәк чайкала. Аһ, тирәк башында аның белән бергә буш калган оя да чайкала. Һавада өн тора: «Оям калды туган илдә...» Җир-җәя таралган татар шигырьне укысын да утырып еласын...

Тик шагыйрь барыбер һәм, әйтергә кирәк, күпчелек очракта, укучының хисе һәм акыл-фикеренә бердәй кагылырга омтыла. «Җыр тәлинкәсен юу» шигыре нәкъ шундыйлардан. Бу шигырь укучыны татар җырының тарихлардан килгән рухы хакында гына уйландырып калмыйча, үзенең дә «үксез моң» икәнлеген искәртеп, тетрәтер, шунда ук бүгенге җырларның байтагының кат-кат «юылганга» күрә, куян шулпасының шулпасы икәнлеген искә төшерер, җырларыбызга карата бик сак булырга кирәклегенә дә өндәр.

Карлыгач төкереге белән балчык ябыштырып, бернинди җил-давылларга да бирешмәстәй итеп үз оясын төзесә, З.Мансуровның шигырьләре йөрәк уты белән эретеп ябыштыргандай:

Һавадан кош моңы иңсә дә,
Тузганак тоталмый үз таҗын.
Ап-ачык күрдем мин бу илдә
Көннәрнең таҗ кебек тузганын.

*(«Борынгы хәрабәләр янында»)*

Бу мисал әле шунысы белән дә кызыклы бугай. Биредә эфемер – бары тик шагыйрь йөрәге генә тоя-күрә торган нечкә күренешне («һавадан кош моңы иңүе») «калын» – меңәр елларны тутырган көннәр-нең дә таҗ кебек тузуына күчерүе хиснең гаять тә киеренке кылда уйналганын күрсәтә.

Әйе, З.Мансуров нечкә, экспрессив, аңа бераз элитарлык та хас кебек. Ләкин бу һич тә халыкка аңлаешсыз элитарлык түгел. Халыкның бәгыреннән өзелеп чыккан үз авазы. Бу – шагыйрьнең үз укучысын биеклеккә чакыруы, аңа ышануы, хөрмәт итүе.

Халык арасында ишетелгәләп китә торган «Тукай белән кемне рәттән утыртырга була?» дигән сорауга да З.Мансуровның җавабы кызыклы, үзенчәлекле:

...Кыенсынмый утырт көрсиеңә –
Зәйтүнәдәй анда... кыз тора...

Гомумән дә, шагыйрь Зиннур Мансуровның хатын-кызга мөнәсәбәте галибанә, илаһи, аларның гү-зәллеге каршында ир-атның чарасызлыгын берсүзсез тану кирәклеге ягында.

Инеш буенда карт туктап калган. Куаклар артында кызлар су керә. «Кызкайларның тере сурәтләре агып төшә инеш суында». Бу шигырьгә «Сулкылдау» дигән исем кушылган...

Шулай итеп, без, әкренләп, шагыйрьнең мәхәббәт лирикасына күчәр идек, әмма ул серле шигырьләрне укыганда укучыны китап белән бергә-бер калдырасы килә, укучы үзе ләззәтләнсен, канатлансын, ә бәлки, уфтансын-үкенсен дә... Шагыйрь мәхәббәт лирикасында шундый изге хисләрен белдерә. Бу хисләр кайсы адәм баласын читләтеп үтә алыр икән?

«Күңел сәфәре» китабына тупланган шигырьләрнең тематикасы бай. Кешелек дөньясына хас хәл-әхвәлләр, проблема-мәсьәләләр шагыйрь күңелендә урын алып, һәрвакыт очарга әзер булып торган уктай («Иске Казан»), йөрәген борчып, җәрәхәтләп, сүз сорап, сүз алып, якты дөньяга шигырь булып туа торалар. Ләкин авторның төп темасы барыбер татар тормышы, татар язмышы, аның үткәне, бүгенгесе, киләчәге – борчылу, яну, ышаныч, гасабилану, чарасызлыктан юл эзләү, башкалар белән бергә татар халкына да алдагы көннәрдә матур кояш чыгуын теләү. Татарның милләтпәрвәрләре өчен Тукайдан ук килә торган ихлас, кадерле хисләр түгелмени бу? Шундый хисләр белән янучы талант иясен бөтен халкыбыз белән бергә кадерли, хөрмәт итә белсәк иде. Бу безнең үзебезне-үзебез хөрмәтләү билгесе дә булып торыр иде.

*2004*

**ЯКТЫ ШӘМ**

Шундый кешеләр була, кайсы гына мохиттә сүз әйтсә дә, һәрбер сүзе кабул ителә, күңелгә, йөрәккә үтеп керә. Әле шунысы да бар: ул сүз синең уңайга-җайга әйтеләме, әллә сиңа каршымы – барыбер. Андый кешеләр сирәк була, әмма алар бар. Андыйлар сүз әйткәндә бөтенесе колагын шомрайтып тыңлый, ә язганнарын, зур игътибар белән нечкәләп укый, ишеткәненнән, укыганыннан үзенә дә тагын да зуррак көч ала, күңеленә күркәмлек җыя, хушланып, иркен сулап җибәрә. Гаҗәеп талантларга бай булган татар халкының шундый улларыннан мин үземнең күңелемә якын булган әдәбият-сәнгать өлкәсеннән Габдулла Тукайны, Салих Сәйдәшевне, Бакый Урманчены, Әмирхан Еникине, Сибгат Хәкимне атар идем. Андый кадерле исемнәр бездә тагын да бар.

Тормыштан фаҗигале рәвештә яшьли китеп барган Фәез Зөлкарнәйне дә мин шундый ышанычлы, бөтен татар халкы таянырга мөмкин булган ир-егет, киң эрудицияле журналист һәм мөхәррир, үтә дә

нечкә сиземле әдәбият белгече, бәллүр каләмнән генә төшәргә мөмкин булган шигъри үрнәкләр дә язып калдыручы кешелекле зур каләм иясе дип атар идем.

...Менә бер елны нәшриятта (Татарстан китап нәшрияты. Мин үзем дә шунда эшли идем.) «Фәез Зөлкарнәев безгә эшкә килә икән!» дигән сүз чыкты. Бу вакытта ук әле яшь кенә булган Фәезнең әдәбиятта, язма сүздә җиңелдән генә баручыларга карата бик тә принципиаль, килешмәүчән фикердә торуы хакында гомумсүз таралган иде инде. Нәшриятта булачак мөхәррир белән авторлар арасында килешмәүчәнлекләр күп булыр дигән сүзләр дә әйтелде. Әмма барысы да бик әйбәт булды. Күз алдына китерегез. Мөлаем йөзле, мөлаем карашлы мөхәррир Фәез Зөлкарнәй авторның әсәрен чын галим биеклегендә укып чыккан, тик әле ул һаман да үз фикерен әйтми, бик тә игътибар белән язучы-авторны тыңлый: сүз уңаенда килешеп баш селеккәләп елмаеп куя, шуннан соң гына үзенең сүзен әйтә. Ә менә үзенең бәһасен автор әсәренең чын бәһасеннән күтәрми дә, төшерми дә, бигайбә, чын дөресен генә әйтеп бирә. Ләкин биредә бер кызык нәрсә бар. Башка мөхәррир белән эш иткәндә, автор килешмәскә дә мөмкин. Ә Фәез белән алай килеп чыкмый: дөреслекне автор колагына, күңеленә дөреслеккә хилафлык китермичә ирештерә белүнең гаҗәеп нечкә осталыгыдыр бу. Сүз егәрен җигә белеп, аның көчен сөйләмгә, җөмлә төзелешенә кирәкле юнәлештә күркәм бүлеп файдалана белүнең гүзәл үрнәгедер бу. Ә бит Фәез күп сөйләшүче түгел иде. Күбрәк вакыт ул сүз әйтү урынына сизелер-сизелмәс кенә елмаеп куяр иде. Нәшриятта ул, хәзерге заман язучылары әсәрләре белән беррәттән, күбрәк фундаменталь китапларны редакциялəп эшләп чыгарды, галим-мөхәррирне шул максаттан чыгып та эшкә чакырганнар иде. «Татар әдәбияты тарихы» биш томлыгы, «Татар поэзиясе антологиясе» шундыйлардан.

«Идел» журналына Фәез Зөлкарнәй Римзил Вәлиевтән соң баш мөхәррир булып килгән иде. Әйтергә кирәк, яшьләрнең, яшь язучыларның, бөтен татар язучыларының да җитмеш ел буена совет хакимиятеннән ачарга рөхсәт сорап та ачтырылмаган, бары тик 1985 елдан соң килгән икенче «җепшетү» чорында гына гамәлгә куелган яңа журналның эшен баштагы мөхәррирләр дә киң итеп башлап җибәргәннәр иде. Басмага баш мөхәррир булып Фәез Зөлкарнәй килгәч, эшләр шаулап-гөрләп, зур энтузиазм белән тагын да алга китте. Энтузиазм дигән сүзне юкка гына әйтмим. Татар халкы өчен, аның әдәбияты, мәдәнияте, сәнгате өчен эшләнә торган эшләр бүген дә, нигездә, энтузиазм-фидакарьлек белән генә алып барыла. Бүген дә бу өлкәдә хәлләр аерым кешеләрнең халкы өчен янып-көеп эшләп йөрүләреннән тора. Үз вакытында Фәез Зөлкарнәй – халкы өчен шундый янып-көеп эшләп йөрүчеләрне бер фокуска җыючы, үзе исә шуның генераторы – энергия-егәрлек биреп торучысы иде. Бу чордагы «Идел» журналының темалары, рубрика – бүлем-бүлекләре тарихчыларыбызның, әдәбият белгечләребезнең аерым өйрәнүенә лаеклы. Шулай ук студентлар, аспирантлар, фәнни темалар сайлаган очракта «Идел» журналы алар өчен зур өйрәнү мәйданы була ала.

Хәл кадәри каләм иясе буларак, мин үзем дә ул чорларда «Идел» журналының шактый гына актив авторларының берсе идем. Үзеңнең балаң кебек кадерле, күңелдән уелып чыккан кулъязмаңны шундый да таләпчән мөхәррир кулына тапшыру һәм аның фатихасын алу үзе бер горурлык хисе тудыра иде.

Тик татар дөньясының якты шәмнәренең берсе булган Фәез Зөлкарнәйнең гомере, һәлакәткә очрап, бик тә аянычлы рәвештә сынып сүнде. Әдәбият гыйлемен тагын бер баскыч югары күтәреп, Фәез безгә «Кешем, асылың кем?» (Казан: Татар. кит. нәшр., 1984), «Әверелеш» (1989), «Чакма чакмый ут чыкмый» (1992) һәм үзеннән соң дуслары нәшер иткән «Күләгә күбәләге» (2001) дигән китапларын калдырып китте. Соңгысында авторның шигъри әсәрләре дә урын алган.

*2001*

**БЕЗ КЕМНӘР?**

Әбүгалисина кайбер сырхауларны карый да, моңа үләннәрдән ясалган дару шифа булмас, моңа күңел даруы кирәк, ди икән.

Күңел даруы... Күңелем ярсыган вакытта, моңсуланган яисә, киресенчә, сүрелеп-битарафланып калганда, мин чынлап та күңел даруы эзли башлыйм һәм... кулыма китап алам. Менә әле дә Фәннур Сафинның яңа гына басылып чыккан «Сез кемнәр?» исемле китабы кулымда.

Җыентык беренче битләреннән үк:

Шартлаулар, янгыннар яктыртса,
Барыбер караңгы ул төннәр...
Шул төндә яндыгыз, туганнар,
Менә бит сез кемнәр, сез кемнәр! –

дигән ярсулы юллары белән күңелне биләп ала, йөрәккә гөлт итеп ут кабына. Шушы дүрт юлны укуга, бөтен тарихыбыз күз алдына килә, берсеннән-берсе дәһшәтлерәк картиналар пәйда була. Шул ук вакытта бу шигырь бөтен дөньяның катлаулы тарихы вә бүгенгесе турында да.

Әйе, үлән-яфракларны җылы яңгыр юып киткән кебек, чын шигърият белән очрашу кеше күңелен аклый, пакьли. Әгәр дә шигырь яшәү шатлыгын тагын да ныграк тояргa ярдәм итсә, кешенең рухын күтәрсә, хезмәт-көрәшкә чакырса, шундый шигърият белән очрашудан кеше икеләтә ота.

Фәннур Сафинның бу җыентыгы дүрт «бакча»дан – бүлектән тора. Бүлекләрнең берсе чынлап та «Алма бакчасында» дип атала да. Калганнары: «Без кемнәр?», «Ак күбәләк патшалыгы», «Ярсу тынлык». Һәр бакчаның үз яме, үз матурлыгы, үз җимеше. Бүлекләрнең һәрберсенә шагыйрьнең йөзен кызартмый торган, көчле, хисле, ә кайберләре, безнең карашка, иң югары сәнгати таләпләргә җавап бирерлек шигырьләр кергән. Алар шагыйрьнең иҗат юлында сизелерлек эз калдырыр дип ышанасы килә.

Әгәр дә кеше киләчәк буыннар хәтерендә калсам иде дип яши икән, ул үз чорын узып китәргә тиеш, кешелеккә файдалы эше, уе-идеалы белән киләчәктә яшәргә тиеш. «Безнең токым» шигыре әнә шул турыда:

Узган буын утка кергән чакта
Якты җиңү җырын җырлады –
Без очарга тиеш чорны узып,
Алга әйдәп гаҗәп дөньяны.

Фәннур Сафин җете төсләр кулланырга ярата, ләкин шул төс-сүзләрдән туган рәсем-шигырь укучыны шагыйрь фикеренең тышкы катламында гына туктатып калдырмый, ә аның фәлсәфи тирәнлегенә чакыра.

Менә «Ярсу ат» шигыре. Яшел болынлы су буйлары, кичке шәфәкъ. Шагыйрь көтелмәгән тәңгәллеккә омтыла кебек: ярсып, уйнаклап йөргән ат вә кичке шәфәкъ. Әмма уйлап карасаң, «ат» үзе – туган ил символы булырлык мәһабәт җан иясе, һәм, гомумән, ышанычлы җан иясе, табигатьнең бер бизәге. Шунысы кызык: «шәфәкъ» сүзенең күңелгә бераз шом салырлык хасияте булса да, биредә алай түгел, күңелгә һич шом-шөбһә килми, чөнки ат (гәрчә ул ярсу булса да) рәхәтләнеп уйнаклап йөри, һәм тиңлек-гармониялек күренешенә шул бер сүз – «уйнаклый» сүзе белән ирешелә дә: ат уйнаклый, шәфәкъ уйнаклый. Табигатьтәге шул гармония саклнса, җир дә имин булыр дигән уй күңелгә килә.

Шагыйрьләребезнең күбесенә хас бер күренеш бар: моң сүзенә мөрәҗәгать итү гадәте. Соңгы елларда моң төшенчәсенең эчтәлеге киңәя кебек. Бу төшенчә безнең халыкның холык-характер үзенчәлеген күрсәтә: шагыйрьнең шигырь байлыгы – халык күңеле, барысы да шуннан килә... Ф.Сафинда әлеге моңның төсе бар: йә ул ал (күбрәк), йә зәңгәр, әмма һәрвакыт якты. Ә шулай да моң моң инде ул, барыбер йөрәкнең әллә кайсы бер җирен чеметеп ала:

...Мөмкинме соң миңа янмаска,
Көне буе янган кояш сыман,
Ал моң булып җиргә таммаска?!

Шул рәвешле кеше фидакарьлеге кояш фидакарьлеге белән чагыштырыла.

Матурлыкны бүтәннәргә караганда күп мәртәбә артыграк тою сәләте кешене шагыйрь итә, диләр. Фәннур өчен тормышта матурлык бик күп төрле, кеше хезмәт күрсәттеме – бу матурлык, шаулап язлар килсә – матурлык. Җирдә тынычлык сакланса – матурлык, җир яшәрсә, җир өстендә төзелешләр күбәйсә дә – матурлык. Шагыйрь матурлыкка табына, аны кешеләргә күрсәтүдә бөтен көчен куя.

...Матурлыкның бөтен капкаларын
Ачарга һәм алга барырга!

...Чәчәк кыры, иген кыры булган кебек, бу дөньяда гамь кыры да бар. Чын шагыйрьләр шуннан килә... Тирә-юньдәге җитешсезлекләрне, күңелне рәнҗеткән күренешләрне Ф.Сафин кешенең табигатькә мөнәсәбәте аша бирергә ярата, чөнки табигатькә булган мөнәсәбәт – адәм баласының үз-үзенә, кешеләргә, илгә-көнгә, гомумән, җәмгыятькә мөнәсәбәте ул:

...Бу ярларны – бу талларны
кемнәр саклый алмаган?
Ә кошчыгым андыйларны
Мактап сайрый алмый шул,
Җире өчен янмаганнар
Ил өчен дә янмый шул!

Шагыйрьне мизгел һәм мәңгелек категорияләре борчый, һәм бу борчулы уйларына үзе үк тормышчан җавап бирә:

...Эшнең башы йә дәвамы гына
булып кала икән һәр нокта!

Җыентыктагы күп кенә шигырьләр («Чулпан», «Яшьлек каласы», «Кама» һ.б.) туган якка, андагы үзгәреш-яңарышларга багышланган. Бу үзгәрешләр республикабызның бигрәк тә көньяк-көнчыгыш

районнарына, Чулман-Кама бассейнына карый. Биредә яңа шәһәрләр үсеп чыкты. Шагыйрь шул үзгәрешләрне романтик соклану белән сурәтли:

Калыкты таң балкышында
Яшьлегем шәһәрләре.
Юк иде бит әле Җирнең
Болай ук яшәргәне.

Ф.Сафин иҗатында алма, алма бакчасы образы шактый еш очрый. Халкыбыз күңелендә бу җимешнең төрле символик мәгънәләре бар. Матур кызны багалмасы дип атау; кеше эшенең нәтиҗәлелеген күрсәтеп, «бакчасы җимешле» дигәндә дә алма бакчасы күз алдында тотыла. «Алма агачыннан ерак төшмәс» һ.б. Кыскасы, алма бездә аерым шигъри игътибарга лаек.

Ф.Сафин бу образга фәлсәфи мәгънә сала:

Кызыл алма ак чәчәктән
Истәлек булып калган...
Синең өчен мин дә чәчәк,
И киләчәк – күзалмам!

Әйе, кешенең үткән гомере җирдә эзсез калмасын, чәчәк булып ачылган яшь кеше гомере киләчәккә кызыл алма булып барсын, җимеше-хезмәте киләчәккә ядкарь булсын.

Кеше күңелен гаҗиз уйландыра торган туу һәм үлем, шушы фәлсәфи категорияләр турындагы фикерен дә Ф.Сафин алмага бәйләп әйтә:

Өз, сеңелем, алсу алмаларны,
Сөйгәнеңә илт син аларны.
Алмада ул таң һәм шәфәкъ күрер,
Чын сөюне аңлар аннары!

Алмага бәйләп иҗат ителгән мәхәббәт турындагы шигырьләреннән тагы ике генә юл китерик:

Туп-туп итеп алма төшә,
«Син!» дип барсам – җил исә...

Шигырьне дәвам иттермәсәң дә була, чөнки биредә бербөтен киеренкелек салынган инде.

Шагыйрьнең күңеле һәрчак якты, күкләрдә оча, сабый кебек беркатлы:

Бар дөньяны тутырып киләсең, яз,
Сүнмәс ал таң булып көләсең.
Бәхет кенә кирәк миңа бүген,
Ни бәхетләр алып киләсең?

Шигырьнең аһәңе шундый табигый – кешенең бәхет даулавы эгоистик теләк түгел, ә романтик якты хыял итеп кабул ителә.

Фәннурның бәхет турындагы төпле, җитди фикере халкыбызның бәхет турындагы уе белән тәңгәл килә:

Кырларда ялгызым калганда,
Арышлар башымнан сыйпаган...

Бу шигырьдә гомер-гомергә игенчелек белән шөгыльләнгән халкыбызны хезмәте җимеше – тук башаклар чын-чынлап бәхетле итсә, икенче яктан, аның гадәттән тыш тыйнаклыгы күренә: шатлык яшьләрен дә ялгызы гына калган чакларында чыгара ул. Безнең халыкта кайгыны сабыр кичерә белмәү хәтта гаептән санала бит.

Ф.Сафинның шигырьләре җиңел укыла, күңелгә тиз сеңә, шул ук вакытта аларның эчке мәгънәләре тирән, аларга салынган егәр, фикер укучыны озак уйланырга мәҗбүр итә:

Ныклык теләп безгә, йөрәк кушкан
Хаклык якларына чакырып,
Таш өстендә борын төртә үлән –
Җирдән безгә дигән Яхшылык.

Шагыйрьнең күңеле еш кына борчулы, бүгенге буынның язмышы турында уйлана ул. Ныкмы ул буын?..

Янды төн, янды кан – җан калды,
Шуңамы якты бу ак көннәр?
Һәм шуңа ни булыр җавабың?
Без кемнәр? Без кемнәр? Без кемнәр?..

*1981*

**ӘДӘПЛЕ ӘДӘБИЯТ**

Эльмира Шәрифуллина шигърияткә тормышның эченнән, аның яралы ярларыннан очып һавага күтәрелгән коштай килде. Ире – үзенчәлекле талант иясе, күренекле язучы Фаил Шәфигуллинның фаҗигасеннән соң «Мизгел» исемле повестенда яралы җанын ачып салганнан гайре күпме шигырьләр туды, әмма аның иҗатында тормышка үпкәләү түгел, әрнү генә бар. Шул көенчә дә ул үзенең укучысын оптимизм дулкынына көйләргә тырыша, кояшлы аланнарга чакыра, туган авылына мәдхия җырлый.

Шагыйрәнең «Яңгыр җиле» исемле шигырь китабы Зөлфәтнең кереш сүзе белән 1984 елда гына дөнья күрде. Бу беренче шигырь китабының аягы җиңел булды, бер-бер артлы дигәндәй, «Гөлләр елы», «Зәңгәр эңгер», «Таң чыгы» китаплары туды.

Эльмираның үзенә генә хас бер үзенчәлеге бар: ул балалар дөньясын искиткеч органик-табигый рәвештә зурлар тормышы белән бергә үреп бирә белә. Хәер, бу хәл шулай булырга тиештер дә. Адәм балалары яшь бүленеше буенча түгел, ә гаилә эчендә әти-әни, әби-баба, апа-абый, ул-кыз, оныклар булып бергә яши. «Балам баласы», «Улым-улым», «Оныгым биргән бәхет», «Сабыем», «Онытмагыз»... Бу шигырьләр, югарыда әйткәннәребезне раслап, рәхәтләндерә, шатландыра.

Шагыйрәнең каләме үткенәя бара, дөньяны кабул итү офыклары да киңәя. Эльмира бүгенге көн фаҗигаләренең дә үтергеч дөрес сәбәбен күрсәтеп бирә.

Җир йөзендә өсте-өстенә золым,
Бер Ходаем, үзең ярлыка.
Кеше өчен җаныбыз көймәгәнгә
Шушы мәсхәрәгә калдык та.

*(«Мордар» поэмасы)*

Адәм баласы бер-берсен сакламый да, саклашмый да башласа, гадиләрнең кимчелеген түрәләр гафу итә белмәсә, түрәләрнең гаделсезлекләреннән түбәндәгеләр үрнәк алса, чынлап та, кеше кадерсезгә кала шул. Безгәме соң моны белмәскә – тормышыбызны шул хәлләр басты.

Шагыйрәнең күңеле бөтен җир йөзе өчен әрнесә, авылы Зөбәер өчен бөтенләй дә өзелеп китә. «Мордар» поэмасы бүгенге авылның һәлакәтле якларын әрнеп сурәтләү генә түгел, автор җан авазы белән «Акылга килегез, туктагыз, авылдашлар, бу хәшәрәтлекләрдән» дип кычкыра сыман. Кычкырырсың да, татар авылы бүгенгә кадәр безнең бердәнбер таянычыбыз иде ич. Соңгы ун елда чак кына безнеңчә дә яши башлаган шәһәрләребез дә «вертикаль власть» чыгуга, кирегә таба тәгәри дә башлады. Авылларыбыз аракы парында эреп бетсә, нәрсә калыр, нәрсә булыр? Әстәгъфирулла, Ходай язмасын!

Шагыйрәнең сулышы киң, иҗат тармак-сукмаклары төрле-төрле. Әмма төп ориентир-юнәлеше чын татарларча. Эльмира да, күпчелек татарыбыз кебек үк, безнең Тукайга ябышып-тотынып яшәвебезне яхшы аңлый, ул моны «Без – Тукайлы халык» поэмасында күрсәтеп тә бирә.

Шулай инде, әйе, Тукай безнең өчен иң исәннәрнең дә исәне, күңел аны мәңге тере итеп кабул итә. Ул безнең арада.

Эльмираның тагын бер поэмасына игътибар итәсе килә. «Каюм коесы». Әсәрдә кое суы чишмәсе, гыйлем чишмәсе, кеше күңелендәге тәрбия чишмәсе барысы бер рәткә тезелеп, бер үк кыйммәткә ия булып яңгырый. Чынлап та, эчәр су табар өчен чишмә эзләүченең – кое казучының да күңеле-уе рухи чишмәләр эзләүченеке кебек үк ак-пакь, саф булырга тиеш. Безнең бөек галимебез, табигать белгечебез, халык әдәбиятын җыеп туплаучыбыз, астроном, математигыбыз, җәгърафия фәне дә халкының белем киштәсенә, күңеленә-аңына керсен дип, ана телендә шул фәннән дәреслекләр төзүчебез, ә инде татар теле һәм әдәбияты дәреслекләрен төзүне үзенең беренче бурычы һәм эше итеп хисаплап гамәл кылучы әдибебез хөрмәтле Каюм Насыйри әнә шундый ак-пакь, саф күңелле шәхесләрдән. Билгеле, поэма безнең күбебез белгән фактларга нигезләнеп язылган, әмма эзләнеп язылган. Галимнең күңел яктысыннан – гыйлем учагыннан рух алып, тагын да тирәнрәк гыйлем коесына күңел күзен төшерерлек итеп язылган. Инде әйтеп үтелгәнчә, поэмада Каюм Насыйриның эчәр су өчен үз кулы белән казыган коесы әдипнең халкына калдырып киткән белем коесы-чишмәсе – фәнни хезмәтләре белән тиң итеп бәяләнә.

Кое төпләренә җиткәч, Каюм
Хәбәр биргән: «Тартып алыгыз!»

Ягъни, белемнәрнең төбенә җиттем, әйдәгез, тартып алыгыз, белем байлыгын сезгә озатмак булам, ди галим. Халыкка белем күндерү, белем өләшү уе белән янган әдип бу юлда шактый киртәләргә дә юлыга шул. Бу урында шундый бер нәрсәне дә әйтеп китмичә булмый. Үз вакытында татар халкы Аурупача яшәүгә күчүгә (урысча яшәү дә шуның эченә керә), ягъни ассимиляциягә шактый нык каршы торырга тырышкан. Аның (халыкның) хәле җиңел булмаган – балалары урыс телен дә өйрәнеп, урыс мәктәбендә укып чыкса, телен-милләтен югалтасын яхшы аңлаган. Каюм Насыйриның урысча укырга кирәк дип, үзе үк бу эшне эшләп каравын – урысча укытуын – халык шуңа күрә кабул итмәгән дә. Ләкин бу эшне галим дә аптыраганнан эшләгән – башка юлы булмагач, үз халкын дөньяви белемле

итүнең бу чарасын да файдаланырга мәҗбүр булган. Поэмага әйләнеп кайтканда исә, Эльмира Шәрифуллина «Каюм коесы» дигәндә галимнең бөтен гыйльми байлыгын-мирасын саклау, өйрәнү, өйрәтүне күз алдында тотып, безнең бурычыбыз икәнлеген ассызыклап күрсәтә, хәтта бөек шәхесебезнең үз кулы белән хәстәрләп калдырган авылындагы коесын яшәтү дә символик мәгънәгә иялегенә басым ясый. Чын хаклык шундый булырга тиеш.

Эльмира – тормышның матур якларын күбрәк күрүче. Моны аның шигырьләре раслый.

Син – патшасы безнең яшәешнең,
Күпме йөрәк сиңа тоташа.

*(«Галиҗәнап әнкәй»)*

Эльмира Ананы, әле беркем атамаганча, яшәешнең патшасы дип атый, әмма шигырьдәге сүзләрнең тезелү тәртибе, яңгырашы пафослы түгел, нәкъ халыкча, гади, һәм әйтергә теләгәнлекнең иң кыска юлы сайланган.

Эльмира турыдан-туры сәясәткә кагылып язмый кебек. Ә менә бу юллар:

...Нечкә күңел никтер тиз тула.
Болай да бит авыр безнең тормыш,
Ни шәригать юк илдә, ни йола.

*(«Йолдызымны калдыр»)*

Шигырьдә илдәге тормышның авырлыгы хакында гына әйтелә кебек. Ләкин илдә ни дин, ни йола йөрми икән, димәк, аның нигезе черек, аварга тора. Менә бусы сәясәт була бит инде... Шагыйрәнең «Чөгендерле катык» шигыре минем дә хатирәләремне яңартты. Безгә – мәктәп балаларына көзен кырда чөгендер, кишер, кәбестә, ә бигрәк тә карбыз (!) җыйганда бирәләр иде куе сөттән оетылып, чөгендер сыгынтысы белән төсләндергән тәмле катыкны. Хәзерге йогурт-могурт дип сөйләнгәләп йөрелгән тәгамне без әллә кайчан белгән! Эльмирага чөгендерле катыкны, шулай ук байтак балаларны тезеп утыртып, әбисе ашаткан.

«Баланың баласы балдан татлы» дигән гыйбарәне без гел ишетә киләбез. Ә менә оныклары хакында әдәби сүз әйтү – әдип-әдибәләргә генә бирелгән бәхет. Эльмира ханымның бер шигыре «Оныгым биргән бәхет» дип атала да. Андый шигырьләр тагын бар: «Балам баласы», «Улым-улым», «Сабыем», «Онытмагыз».

...Әби булдым бүгеннән.
Бар йолдызлар кояш булып
Балкый кебек күгемнән.

*(«Оныгым биргән бәхет»)*

Югарыдагы шигырь юллары – вакыты җиткәч, бөтен хатын-кызларга да оныклы әби булуны – бәхетле кеше булуны теләү. Оныклы кешенең Кояшы да бер генә түгел, бөтен күк тулы икән. Бирсен Ходай!

Шагыйрәнең стиль үзенчәлекләре дә эчтәлек-максат кебек үк халыкчан. Шигъри алымнары электән килгән чарланган тел чаралары. Халкыбызда «тач иттереп әйтеп бирә» дигән сүз бар. Шуны мин Эльмира иҗатына карата да әйтер идем:

Саташты күп йомры башлар,
Голәмәсе, дин хадиме.
Көрәштең син берьялгызың,
Татар теле мөгаллиме!

Бик яхшы беләм һәм хәтерлим: мин үзем дә, татар мәктәпләре бетерелгәч, урыс мәктәпләрендә татар телен ничек итеп кенә әле көрәшепләр укытып йөрүне. Ул көрәшләрнең җимеше татлы булды – татар барыбер үзенең телен саклап калды. Соңгы ун елда көрәшмичәрәк кенә укыта башлаганнар иде, инде тагын безнең өскә ябырылып килгән хәлләр көрәшкә чакыра...

Шагыйрә Эльмира ханым үзе дә мәгърифәт өлкәсендә хезмәт итеп яшәгән зат. «Мәгариф» журналында эшлиме ул яисә көллияттә татар теле һәм әдәбияты укытамы, татар әдибәсенең яшь буынга изге уй-теләкләрне сеңдерергә тырышуның практик үрнәге, эше ул. Читенлекләр, кыенлыклар алдында сыгылып төшмәү дигәндә дә Эльмира ханымны үрнәк итеп күрсәтмичә булмый. Татар китабын нәшер итү буенча беркем дә җавап бирми торган заман килгәч тә (әле ярый, дәреслекләр басу бераз оештырыла), китап чыгаруның да үзе генә белгән юлларын табып, хәстәрен күреп, нәни укучыларыбызга бер-бер артлы «Иң матур әни», « Нәниләргә әлифба», «Ничек, нинди, ни төсле», «Алтын балык» исемле төсле-рәсемле җыентыкларын бүләк итте.

Әйе инде, уңганлык көн дә кирәк. Ялгыз калып, һәр көнендә тигез багып-тәрбияләп үстергән кызлары буй җиттеләр. Тупырдап торган оныклары үсә дигән идек шагыйрә ханымның. Әтиләре – язучы Фаил Шәфигуллин исән булса, ничекләр генә шатланыр иде, кадерле бабакай булып та йөрер

иде, юмор өлкәсендә аны беркем алыштыра алмаган кебек, оныкларының бабасын да алыштырып булмый шул. Ә Элмираның гаилә традициясе барыбер дәвам итә. Олы кызы Рушания әтисе Фаил Шәфигуллин иҗатын өйрәнә, аны халыкка җиткерү юнәлешендә эшли, талант иҗаты буенча уңышлы итеп кандидатлык диссертациясе дә яклады.

Шагыйрә ханымның иҗат һәм тормыш пәрдәләрен сак кына ачкалап күз салсак та, аның хатын-кыз буларак күңел кылларының ничек чирткәнен күзәтмәдек-тыңламадык та бугай, сәхифәнең ул ягына да чыгып, бер-ике мисраг бирик әле. Иң беренче шуны кабатлап әйтик: шагыйрәнең йөрәк ярасы – вафат булган ире Фаил Шәфигуллин. Ул яраны ачарга теләмәсәк тә, шигырь әйтсен әле:

Мин парлы –
Гомергә моң-зарлы,
Ә кемнең буш икән сарае?
...Каберең чәчәкләр илтәмен,
Син туган ай иде – май ае!

*(«Мин парлы»)*

«Син үлмәдең», «Сагынуым белән яшәттем», «Һәлакәт», «Бер исем», «Әй сулкылдый җаным», «Ышана алмыйм», «Гомерлек бәхетемне» – мондый шигырьләр Эльмираның язмыш билгесе.

Тик барыбер җил исү, яфрак селкенү хәлләре дә бар шул:

Табы бетми искергәнче
Кара тамса ап-ак бүзгә.
Нахак сүзгә, гайбәтләргә
Тол хатыннар ничек түзә?

*(«Ни әйтәсең, аңламагач»)*

Бу үткән гасырның 80–90 нчы еллар тормышы. Халыкның әле уттан курыккан кебек гайбәттән курыккан чагы. Ул торгынлык дигән чорлар, бер яктан, бүгенге әхлакны күз алдына китереп әйткәндә, киләчәктә алтын чор дип бәһаләнергә дә мөмкиндер әле. Кем белә?..

Эльмира ханым – татар хатын-кызларының гаилә эчендә традицион сабырлыгын яклаучы-хаклаучы автор.

Җәмәгатең тик эш аты булды, җаным.
Сине күтәп алалмыйча атты таңым.
Гомер әзрәк калган саен артты аңым,
Тыелдым гел, сабыр итим диеп тагын.

*(«Көтә-көтә»)*

Бу түгелме татар хатын-кызы фикерләве? Тик бүгенге көндә шул нәрсәнең җимерелә баруы кызганычлы уйлар уйлата. Татар хатын-кызының психологиясе күршеләр-өйдәшләр булып яшәп яткан халык хатын-кызы холкыннан җир белән күк аерылган кебек аерымланып тора иде ич. Урыс шагыйрәсе эш турында, сабырлык турында әйтәме соң инде ир-атка мөрәҗәгать итеп шигырь язганда? Булмаганны...

Сүземне Эльмира ханымга сәламәтлек, уңышлар теләп, шагыйрәнең «Әдәпле әдәбият» мәкаләсендәге сүзләр белән тәмамлыйсым килә: «Сәнгатьтә матурлык мәҗбүри. Димәк, безнең дә бер генә әсәребезне дә, әсәрдәге бер генә җөмләне дә ямьсез, әдәпсез итеп язарга хакыбыз юк».

*2002*

## ХАЛЫК КИТАБЫ*

Әй язмышлар, язмышлар, ачы да, гыйбрәтле дә, моңсу да, якты да һәм кадерле дә. Әйе-әйе, кадерле. Чөнки алар олы бер кадер-хөрмәт белән укучы күңеленә җиткерелә, әле өстәвенә кешенең, бу очракта әдәби геройның, хис-кичерешләренең, уй-фикерләренең кечкенә генә, үзе дә сизер-сизмәс кузгалган нюанслары да, туфанланып, давыллап алган мизгелләре дә автор өчен кадерле, ул шул халәтләрне бөртекли-энҗели һәм күңеленнән ак кәгазьгә төшерә... Әйе, мин әдәби әсәр укыйм, дөресрәге, хикәяләр. Бу хикәяләрне аягөсте генә укырга ярамый, бу хикәяләр – поэзия, шигърият, кеше күңеленең тирәнлекләренә төшеп, нәзберек-нечкәлекләренә төшенеп һәм тәрелеп язылган әсәрләр. Дөрес, бер караганда безнең тормышта сирәк була торган күренешләр тасвирланмый анда, вакыйгалар безнең көннәрне дә үз эченә ала, сугыштан соңгы еллар, сугыш еллары. Күбрәк авыл тормышы, билгеле, шәһәр дә бар. Әйе, автор яхшы белгән хәл-әхвәлләр. Шул хәл-әхвәлләр әсәрдә җанлана, терелә, сулый, яши һәм укучыны да үзенең тормышы белән яшәтә башлый.

Әйе, язучы Роза Мулланурова, мин үзем яхшы белгән вакыйгаларны язам, ди. Чынлап та, йөрәктә кадерле урын алган нәрсә турында шулай яратып, сөеп үз күргәнгә, башкалар белән уртаклашырга мөмкиндер, ягъни китап укучының зәвыгын бозмый торган рухи азык тәкъдим итәргә мөмкин. Алдан ук әйтеп үтик, бу хикәяләрне әдәбиятның хасиятен, мәгънәсен аңлаган укучы укымый калса, кызганыч булыр...

Кайвакыт, хикәяләр укыганда, әйбәт хикәяләр укыганда, аһ, бер бәянлык, романлык материал әрәм булган дип тә уйлап куясың. Ләкин бу болай гына уйлау, ничектер күләм чагыштыру кебек кенә бер мизгел, дөресрәге, хикәя олы бер бәян укыгандагы кебек тәэсир иткән. Димәк ки, шул бер кечкенә хикәяне укып, андагы геройларның тулы бер тормышлары белән яшәп алгансың, чын тормышның чын геройлары белән виртуаль дөньяда йөргәнсең. Бер хикәядә романдагы кебек хис, дәрт, кодрәт, омтылыш, максат, нәтиҗә кебек плацдармның бөтен почмакларын йөреп чыккансың, ягъни автор аз әйтеп, укучының фантазиясен уятырга, кабызырга, очыртырга, канат куярга реактив аппаратлар очып китәрдәй көчтән аз көч салмагандыр... Ләкин шулай да бу фикерләр һич тә хикәяне роман жанрына каршы кую түгел, әйбәт озын романны укыганда күз дә рәхәтләнә, шуннан күңел күзе байый...

Әйе, язмышлар, язмышлар, әллә ялгышлар, ялгышулар? Катлам-катлам салкын карлармы соң алар, әллә бура-бура буралган тирән сулармы?..

Шатлыклары азрак инде, нишлисең, автор тормышны ясалма бизәкләүдән бик ерак тора, аңа дөреслек булсын. Гомумән дә Роза Мулланурова хикәяләрендә ике үлчәү тәлинкәсе чәбәләнә, әйе, берсенә – бәхет, икенчесенә бәхетсезлек төялгән яисә берсенә – шатлык, икенчесенә кайгы салынган диеп әйтсәк тә була. Шатлык белән бәхет үз ягына басып китәм дип артык каударланмаса да, тигезлек сакларга тырышса да, юк шул, дөнья андый беркатлылык өчен яралтылмаган... Дөньяда гаҗизлек, аптырау, сынау, сыналу, сыну, сынмау, җиңү, җиңелмәү, сатылу... сатылмау бәһасенә торган фикер хөрлеге – барысы бергә чорналган бер йомгак. Менә шундый авырлык-читенлекләр чыбылдыгын, ятьмәсен рухны сындырмыйча, әмма кыйналып-сугылып, җәберләнеп-үксезләнеп, җәзаланып-җәфаланып, еш кына соңгы сулышларга калып үтеп чыккан геройлар бу хикәяләрдә. Әгәр дә пафоссыз гына әйтсәк, бу – тормыш, безнең халык тормышы, татар кешесенең социализм боламыгын һәм инде янәдән әйләнеп кайткан капитализмның ачы җимешләреннән авызы пешүе. Халыкка дигән балы-мае читтән агып үтә, хәтта әкиятләрдәгечә дә түгел – мыекка да эләкми...

Әй, Галикәй, әй, Саракай!.. («Галикәй белән Саракаем») Сезме соң бәхетле тормышка лаек түгел? Ә күпме кыйналгансыз, җәберләнгәнсез. Сугыш гарасатыннан бер кулын югалтып, маҗаралы хәлләр аркасында гына исән калган Галикәйнең буш күлмәк җиңенең ярсып-ярсып талпынуы, очып китәргә үрсәләнүе – аның эчендә, җанында аккош тыпырчынуын, аккош җаны ярсуын күрсәтмимени? Әйе, ялгыз аккош ул, Саракаеннан ялгыз калган аккош. Сугыш елларында яшь кыз бала торф чыгаруга куы-лып, анда ярты сәламәтлеген калдырып кайткан затлы, эчке культурасы йөзенә мөлаемлык булып чыккан Саракае белән шул ярым-ярты гәүдә һәм исәнлек белән эш аты булып тормышны тартканда тукталып уйланырга да, бер-берсенә карашып сокланырга да вакытлары да, чаралары да булмаган икән ич. Галикәйнең Саракае исәнлеккә мантымыйча иртә китеп бара. Ә ялгыз калган Галикәйне яшьләргәме соң аңларга?.. Җанында аккош тыпырчына, ә тыштан ул үзе яратып асраган усал ата казы кебек. Ата казының ачыргаланып кычкырган соңгы авазында аның өчен бу дөньяда бөтен нәрсәнең тәмамлануын, соңгы чиккә җитүен тәне белән дерелдәп тоя (чалынган ата каз тырпылдаган кебек), әмма күңел күзендә бер нур уйный: Саракае белән алар барыбер бәхетле булганнар! Менә шуны аңлау бәхетенә ирешә Галикәй. Хикәянең сюжет-композиция сызыгы гади генә кебек, әмма автор әсәрдә бик матур символик алымнар, бизәкләүләр күндереп, укучыны бик тә сагаеп кына, уйланып кына укырга мәҗбүр итә. Галикәй ата казының соңгы авазын ишеткәч (ата казны Галикәй өйдә югында чалалар), «Юлладылар!» ди үз-үзенә. Менә шушы төенләнеш хикәядәге геройларның – Галикәй белән Саракайның язмышларының драматик булачагы укучы күңелен дертләп куярга мәҗбүр итә. «Сизенүе хак булган! Ата каз кырпак кар өстендә гырылдап ята, кияве чалгы пычагын комгандагы су белән юып маташа иде...» Ата каз тавык чебие генә түгел, чалганнан соң да әле җаны чыгып бетмәгән... Монда да символик мәгънә. Әйе, сугыш чоры һәм сугыштан соңгы Галикәйләр буыны ул сәрсән, бирешмәс буын, болар мәгълүм шигырьгә – «...сделать бы гвоздей из этих людей, крепче не было бы гвоздей...»гә экспозиция булып торырлык...

Хикәядә хәтта сугыштагы командир да символик-кинаяле сөйләшә, атакага керәсе солдат Гали-кәйнең «Ичмаса, итегем дә юк» дип көенүенә «Иртәгә барысы да булыр...» ди. Баксаң, мылтыксыз, итексез, котелоксыз солдат кырылышта исән калса, аңа үлгән иптәшенең нәрсәләре буласы икән... Алга таба хикәя Саракаеннан ялгыз калган Галикәйнең үткән тормышларын күз алдыннан, аңыннан кабат үткәрү буларак сүтелә. Хикәянең башындагы «Юлладылар!» сүзе бер үк вакытта чишелешнең ничек булачагына да ишарәле... Тик әле хикәя ахырында да Галикәй исән, үзенең бөтен уйларын, хәсрәтен-кайгысын, булган кадәр шатлыгын да яландагы муртайган өянкегә сөйли. Тагын символик алым, өянке дә символ – ул муртайган, аварга тора – Галикәйнең пары.

Алар бер-берсен ничек аңламасыннар инде...

Авторның хикәяләренә кешеләр арасындагы, хәтта туганнар, ана – бала, ата мөгамәләсендәге иң нечкә, нәзберек җепләрнең бәйләнешләрен гадәттән тыш сизгерлек, такт, аңлау, аңлату белән тасвирлау хас. Бу сүзләргә куәт итеп, «Юшкын», «Бүре чагасы», «Күктәтәй», «Башсыз балан куагы», «Таһир хатыны», «Биш сумлык мунча» һәм башка әсәрләрне атарга мөмкин.

«Туйда» хикәясендә «Зур өметләр, ак хыяллар белән тырышып-тырышып теккән аклы ефәк күлмәге, атылган аккош кебек, идәнгә таралып төште дә җансыз, хәрәкәтсез ята бирде. Юк, атылган аккош кыймылдый башлады, бәргәләнергә тотынды. Тик оча алмый – канат очлары киселгән...» өземтәсе Фәйрүзәнең эчке халәтен тулысы белән ача да бирә...

Әй тормышлар-язмышлар! Әфган сугышы дип калыпланган басып алу сугышына илтеп тыгылган Ирек, шулай ук маҗаралы хәлләр аркасында исән калып, аннан әсирлеккә эләккәннән соң, җәберләнүләрен үзе генә белсә, берзаман илгә янгын эчендә көеп бетсә дә, янып бетмәгән бер сәер табылдык кебек кайтып төшә, аны туздырылган туган нигезендә айдан төшкән бер шәүлә, буш урын итеп каршы алалар, чөнки ул алып кайтып күптән җирләнгән булып санала икән, ә нигезенә утырган яшьтәшләре елгыр бизнесменнарга, шактый ук кансыз адәм кисәкләренә әйләнгәннәр, әнисе күтәрә алмаслык кайгыдан вафат, сөйгән кызы елгырларның азыгы икән...

Роза ханымның әсәрләренең теле матур, нәзберек-нечкә, шул ук вакытта халыкчан бай, тәвәккәл дә. Гомумән дә бу халык китабы... Бу тәвәккәллек фикер белдергәндә сүзләрне иркен куллана белүдә генә түгел, кайбер диалекталь дип әйтимме, әллә билгесезрәк сүзләрнеме куллануда да чагыла. Миңа үземә «чарача» дигән сүз ошады, югыйсә безнең халык һәртөрле кумырык, бүлем, бүлемтек кебек урыннарны предбанник дип әйтеп җибәрергә өйрәнде. Ә андый җирләр чарача дип атала икән. Нинди матур! Күбрәк иген арасында үсәргә яраткан зәңгәр чәчәкне ничек кенә җайсыз итеп атамыйлар: буынтыклы дип тә, урысчалап василек дип тә, зәңгәр дип тә. Ә ул күктәтәй икән ич!

Билгеле, хикәяләрдә кайвакыт тырмалырга теләгән сүз гыйбарәләре дә бар. Шундыйлардан берничә калька куллану бик үк уңышлы түгел кебек. Аннан килеп, тагын: «... Казлар Рим дигән би-и-ик олы каланы саклап калган бит, беләсегез килсә...» дигән әкият-гыйбарә дә кереп киткән, ә чынына килсәк исә, Римны Атилланың мәрхәмәтлелеге коткарып калган...

Югарыда әйтелгән сүзләр хикәяләрнең һич тә чынлыгын киметә икән дигән фикергә китерүдән бик ерак торалар, болар капылт кына кергән кебек, авторга аларны алып кую да мәшәкать тудыра торган эш түгел, әйтүебезчә, аның (авторның) сөйләм-язу куәсен җигәр өчен көчәнүнең хаҗәте юклыгы болай да күренеп тора.

Ә укучы исә әсәрләрне укыганда ялгызлык, ятимлек, кардәшлек, туганлык, сөю-сәгадәт, үткенлек, юашлык, сагыш-саргаю, тәвәккәллек, читенсенү, читсенү кебек тормыш дулкыннары эчендә тирбәлгән, кайнаган геройларның күбесенең яхшы мәгънәсендә намус колы булган язмышларын йөрәк әрнүе белән кабул итәр...

*2006*

**СИҢА ИЕЛӘБЕЗ, ТАБИГАТЬ-АНА!**

Безнең Дания Гайнетдинова дигән бер атавыбыз бар. Тик атау дигәч тә, буш җир түгел бу, киресенчә, дөньяның бер җанлы, җылы почмагы, әйтерсең лә биредә бөтен җәнлек, кошларның, күбәләкләрнең йомры-йомшак бәбчекләре җыелган да матур пипелдәү, сайрашу, мырлау авазлары, хәтта күбәләк канатларының тибрәнүе дә ишетелеп тора кебек. Әйе, бу – балалар дөньясы. Дания ханым инде менә ничә еллар сабыйлар дөньясында, халкыбыз әйтмешли, әвәрә килә, дөресрәге, ничә еллар буе «Татарстан» радиосында балалар өчен тапшырулар әзерли. Әйе, әзерли. Үзе оештыручы, үзе җитәкче, үзе репортер, редактор һәм еш кына алып баручы да.

Татарстан авыллары, шәһәрләре арасын кат-кат йөреп чыгудан тыш, Дания Гайнетдинова, татар балаларының, ә кайчакта хәтта бер генә баланың да күркәм, күренекле, милли гамәлләрен радиодулкыннар аша бөтен татарга ирештерү өчен, Россиянең иң ерак өлкәләрен дә әйләнеп чыга. Йә әле үзенең аерым тапшыруларын әллә кайсы шәһәрләрдә оештырыла торган төрле фестивальләргә алып барып тыңлатып, күркәм җиңүләр, призлар алып кайта.

Дания Гайнетдинова татар әдәбиятын халыкка ирештерүчеләрнең иң даими, актив эшләүчеләрнең берсе икәнлеген дә белеп торабыз. Аның «Татарстан» радиосыннан дистә еллар буе алып барылучы «Язучылар – балаларга» тапшыруы яңгыр дими, усал җилләр дими, яңгыравын белә. Даниянең бу гамәле бигрәк тә игътибар үзәгеннән төшеп калмаска тиеш кебек тоела. Заманында балаларга йөрәген ярып бирердәй булып иҗат иткән каһарман язучыбыз Абдулла Алиш мондый хезмәтне югары бәһаләр иде...

Дания Гайнетдинова тапшыруларының информацион кыры да киң. Бу зур илдә сибелеп яшәгән татар балаларының тормыш-көнкүреш хәлләре турында, аларның милли омтылышлары, уңышлары, халкыбыз традицияләрен нинди генә шартларда да яшәтергә тырышулары хакында сөйли ул

тапшырулар. Әби-бабайлар, әти-әниләр, билгеле, балалар да бик тә көтеп ала бу сәгадәтле сәгатьләрне. Нишлисең, бөтен татар балаларына да шул бер «Татарстан» радиосы гына атнага берничә сәгатьне багышлый. Дөресрәге, «нишлисең» дип түгел, «әле ярый» дип әйтергә кирәктер.

Теләсә кайсы өлкәдә талант бөреләрен күрсәткән бала хөрмәтле редакторның игътибар үзәгендә. Дания Гайнетдинова ачкан бәләкәй «йолдызчыклар»ның исемнәрен санап китә башласаң да шактый озакка сузылыр иде.

Дания ханымның үзенең әдәби иҗаты да балаларга багышланган. Аның күңел күзе бу очракта да балалар дөньясына төбәлгән.

Татарстан китап нәшрияты 2007 елда дөньяга чыгарган «Каен җиле» исемле хикәяләр китабы геройлары да балалар, әтиләр, әниләр, әбиләр, бабайлар. Автор бу хикәяләрдә бүгенге тәрбия гамәлләрен гуманлаштыруга ярдәмгә табигатьне ала. Табигать кайгы-шатлыкларны кичерешә, үгетли, чакыра, канатландыра...

Табигать белән бергә кушылып китү очраклары «Каен җиле» китабы геройларының байтагына хас («Бахбайларым», «Елан каргышы»). Карагыз инде, бәләкәй Назлыгөлгә генә («Назлыгөл»). Табигать белән икесен аерып алып булмый. Икесе дә самими, беркатлы, риясыз, хисчән, ышанучан, хыялый. Ә «Уяну» исемле хикәя исә татар халкының борынгыдан табигать белән керешеп яшәү үрнәгенең кәгазьгә төшерелгән гүяки бәләкәй генә энциклопедиясе.

Язучының башка хикәяләрендә дә, геройлар табигатькә карата саңгыраурак, аны аңлап бетермәгән очракларда да, табигать үзе һәрвакыт янәшәдә, аңа кул гына суз, ул һәрчак ярдәмгә килергә әзер... Әйе, авторның бөтен хикәяләрендә диярлек табигать һәрвакыт кешеләр белән янәшә («Бала-бәгырь», «Ике дус»). Бигрәк тә «Бала-бәгырь» хикәясе тетрәндереп уйландыра. Хикәядә тулы бер буынга туры килгән бу илдәге тарихи һәлакәтнең уйламаганда-көтмәгәндә алдагы буыннарга әйләнеп килеп икенче бер сыйфатта каты итеп китереп сугуы автор тарафыннан ышандыргыч художестволы алымнар белән бирелгән. Шул тарихи фаҗигаләр аркасында золымга юлыккан кешеләрнең күз алдына китерүе читен булган гомерләре белән, без әйтергә күнеккән тыныч тормышта, бала фаҗигасенә юлыккан икенче берәүне дә миһербанлы табигать бергә китереп күрештерә. Гомумән дә, хикәядән хикәягә миһербанлыкка, мәрхәмәткә чакыру «Каен җиле» китабында бала күңеленә үтеп керү мөмкинчелеген арттыру ысулы буларак тәкъдим ителә. Тормышның күрексез, хыялсыз, тонык, кешелексез яклары да бар бит әле. Аның шундый яклары объектив язучы каләменнән читкә тибәрелми, һәм бу очракта автор бөтен күңеле-иҗаты белән педагог («Урам малае», «Син зур инде», «Очучы булам», «Мәктәптән кайтканда» һ.б.).

Әйе, китапның темасы гел бала тәрбиясе, ата-ана мөнәсәбәтләре, мәктәп тормышы, гыйбрәтле хәлләр, язмышлар белән бәйле. Бер хикәя «Гыйбрәтле язмыш» дип атала да. Кыска гына «Акмаңгай» хикәясендә дә тормыш гыйбрәте – безнең көннәрдә типик хәлгә әйләнгән күренеш: балалары шәһәрдә, ә авылда калган карт белән карчыкның сыер асрарлык мөмкинлекләре калмаган. Алар татар авылы ишегалдының бер җанлы бизәге, символы булган сыердан калулары белән гаҗиз. Азмыни бездә гомер чылбырының соңгы буыннары китереп кыскан фаҗигале язмышлар...

Шунысы кызык: Дания Гайнетдинованың табигатькә омтылышы тагын бер өлкәдә – рәсем сәнгате өлкәсендә ачыла. Биредә табигать буяулар ярдәмендә тергезелеп, җанландырып, бүлмәләргә килеп керә, күңелләрне били. Бу сәнгатьне бездә юкка гына нәкыш сәнгате дип атамыйлардыр. Чигү чигүдәге кебек, биредә останың күз нурлары турыдан-туры рәсемгә күчә. Даниядә ул нурлар якты, әйдәүче, илһамландыручы. Шул ук вакытта бер хисләнеп алгач, тукталып уйларга салучы да. Карыйсың да: «Нинди изге теләкләр теләп утыралар бит бу тирәкләр, каеннар, чыршылар», – дисең. Әйе, рәссам тормыш каралыгын, караңгылыгын рәсемнәренә кертми. Чынлап та, тирәкләрнең җиргә кадәр иелгән ботаклары рәхимлек, шәфкать, мәрхәмәт юллап торганы ачык йөрәкле, асыл күңелле һәркемгә күренә. Эх, дисең, бүгенге телевизор программаларында шул каеннар, тирәкләр арасында күбәләкләр белән уйнап йөрүче балалар күренсә, бала тәрбияләүнең бермә-бер җиңеләячәген аңлау кыен эшмени... Әлегә экраннарда кан-яшьне законлы бер стихия иттереп аңлатырга, сеңдерергә тырышып, шуларны телепрограммаларга шыплап тутырып, кемнәрдер канлы акчалар эшли, ә безнең алданучан, күндәм халык бу галәмәтләрне сәнгать дип карап утыра. Аптыраганнан, халык – балык, диярсең... Тик барыбер теләкне тормышка ашырасы килә: Дания ясаган кешелекле рәсемнәр йөзеп йөрсен иде экраннарда аккошлар булып, офыктан офыкларга китеп, аклыкка, сафлыкка чакырып...

*2008*

## 2. Ил тотмыйча, тел тоту

**ҖЫРЛЫЙК ӘЛЕ МӘҖЛЕСТӘ,**
**ИҢНЕ ИҢНӘРГӘ КУЕП**

Нихәл итәсең, тормышыбызда күңелсез хәлләр дә күп шул, бигрәк тә соңгы елларда. Кайвакыт алар шундый куркыта, талчыктыра, ялыктыра, аптырата, чарасыз итә. Барысын ташлап каядыр чыгып китәсе, качасы, һичьюгы, колакны-күзне томалап, күрмичә, ишетмичә торасы килә башлый.

Ә шулай да... Ә шулай да тормышыбызда тоташ гел начарлык дисәм, хаклы булмас идем. Бар икән әле безнең тормышта да күңелле, якты яклар. Тормышның андый мизгелләрен дә безгә, каләм әһеле дигәннәребезгә, безнең халкыбыз бирә, бүләк итә, бөтен күңеле белән, җаны белән.

Менә Казан шәһәренең бер татар гаиләсендә үткәрелгән аш мәҗлесен күз алдына китерик әле. Кибетләрдә сатып алырга шактый гына тәм-томнарның булуына карамастан, өстәлләрдә хуҗа ханымнар-хуҗабикәләр тарафыннан бөтен күңелләрен биреп, барлык осталыкларын куеп әзерләнгән берсеннән-берсе тәмле, милли һәм шулай ук хәзерге заманча итеп тә көйләнгән ашлар. Өстәлләрдә дерелдәвек-селкенҗедән алып, төрле төр салатларны кушып, дистә катламлы һәртөрле баллы катламалар, тәмен авызың белән тоеп бетерә алсаң да, тел белән әйтеп бетерә алмаслык матур, кәрәзләп өелгән, чәчәктәй чәкчәкләр, шулай ук чәчәк кебек матур купшы гөбәдия һәм башка тәмлеләрне санасаң, санау озакка китәчәк. Безнең халык борынгыдан килгән гадәтенә тугры: аш-суны мул әзерли, үзе әзерли, ул иренми, аңарда ялкаулык юк. Үз кулы белән әзерләгән азыкның күңелгә хуш килгәнен, ләззәтле икәнен яхшы аңлап эш итә. Дөнья халыклары арасында, бигрәк тә безгә бик ерак булмаган Аурупа халыкларында, үз кулың белән сый-хөрмәт әзерләп, үз өеңә кунак чакыру бөтенләй булмастай эш дисәң дә ярыйдыр. Хәтта безгә кардәш төрекләр дә өйләрендә гадәттә кунакка чәй һәм каһвә тәкъдим итәргә мөмкиннәр, ә бик тә сыйлыйсылары килсә генә ресторанга чакыралар... Мин исә бу мәҗлескә, туганнарым булса да, бераз куркыбрак, икеләнебрәк барган идем. Уйлыйсың, җыела торганнардыр, акыртып музыка куя торганнардыр (акыртып музыка куя торганнардыр дигәндә, нинди музыканы истә тотканым аңлашыла булыр – безгә хас булмаган тимер-томыр тавышлы чит авазлар...), эчә торганнардыр (мәҗлес һич тә Коръән ашы түгел иде), кирәкмәгән, шырдый-бырдыйрак дигәндәй сүзләр сөйлиләрдер... Чөнки болай уйлауга сәбәпләр дә бар ич. Әйтик, телевизорны тоташтырырга куркып торасың, тоташтырсаң, йә шырдый-бырдый, йә мылтыктан пух та пах, йә экранны тутырып БТР гөрселди... Урамга чыксаң да шундыйрак хәлләр...

Ходай рәхмәте! Андый куркыныч нәрсәләрне искә дә алырга туры килмәде бу мәҗлестә. Ачык йөзле кунаклар, җылы карашлар, ягымлы сүзләр, матур җырлар, ут чыгарып дигәндәй, үзебезчә биюләр булды. Ә бит кунаклар чуар – төрле-төрле иде, яшь ягыннан да, кемнең нинди хезмәттә булуы ягыннан да. Пенсиядәгеләр – әмәкләләр, урта яшьтәгеләр, яшь кызлар, егетләр һәм бөтенләй дә бәләкәч балалар – һәммәсе бергә кулга-кул тотынышып биеделәр, үзебезчә әйлән-бәйлән, түгәрәк уеннары уйнадылар, «матур җырларны сайлап кына, сайрап кына» җырладылар. Рәттән тезелеп барган безнең җырлар, бию көйләре арасына сирәк-мирәк кенә кереп киткән башка халык җырлары, биюләре алай ук куркыныч нәрсә түгел икән, чама белү шул буладыр инде. Аннан күңелләргә җылы биреп, тәүлек буе диярлек, «Курай», «Дулкын» дигән матур исемле радиолардан да үзебезнең музыка агыла бит әле, мәҗлеснең нәкъ уртасында, нәкъ кирәк сәгатендә, юбилярның нечкәргән күңелен тагын да нечкәртеп, «Дулкын»нан өй хуҗасы Хәйруллин Галимулла исеменә атап татар халык җыры яңгырый. Сөекле хатыны Зәйтүнә, кызлары Венера, Гөлнара, туганнары котлый гаилә башлыгын... Ә мин безнең халыкның тәмле итеп сөйләшүен күңелем эреп тыңлыйм. Әйе, ашлар матур һәм тәмле иде, әмма алардан да затлысы, тәмлесе сөйләнгән сүзләр иде. Мин шул тәмле сүзләрне җийдем, әйе-әйе, бу сүз «ашадым» дигән мәгънәдә йөргән бездә, кайбер төркиләрдә хәзер дә шул мәгънәдә кулланыла. Әйе, нәкъ шулай, ашаган кебек җанымны тукландырдым, нур эчкәндәй эчтем. Шулай итеп, минем «музыка акыртырлар» дигән гөманым, Аллаһуга шөкер, акланмады, юкка чыкты. Нинди шатлык! «Эчәрләр» дигән шикле уем да акланып бетмәде. Беренчедән, хатын-кызлар чия компотыннан башка нәрсәне тотмадылар да, ә ир-атлардан берничәсе генә рюмка кузгаткалады...

Матур. Мин бу мәҗлесне шул бер сүз белән атар идем. Һәркем үзебезчә – татарча – төртелмичә, кесәгә сүз эзләп кереп китмичә генә, матур итеп котлау сүзләрен әйтте. Эзләгәннәр, тапканнар: матур-матур (булсын, тагы шул сүз булсын. Бездә ул сүз төрекләрнең «гүзәл» дигән сүзенә тиң булып йөри бугай. Төрек кешесе, гадәттә, сүзен гүзәл дип башлый, гүзәл дип тәмамлый: гүзәл, тәмам, ди) шигырьләр күчереп алганнар, өйрәнгәннәр.

Укучыда, нишләп бу кадәр гүзәл соң бу мәҗлес? дигән сорау да туарга мөмкин. Мин дә үз-үземә куйдым ул сорауны. Бер сәбәбе күренеп тә тора бугай: егерме биш-утыз кеше арасында чит халык белән никахлашканнар юк иде. Шуның өчен дә туган телдә сөйләшү, җырлашу, биешү, рәхәтләнеп бер-берең белән аралашу. Сәбәпләрнең икенчесе, бәлки, шулдыр: кунакларның бер өлеше авылдан килүчеләр. Нинди генә авылдан әле! Кышкардан! Элек заманда атаклы мәдрәсәсе булган авылдан. Каюм Насыйрилар һәм башкалар барып укып йөргән мәдрәсә ич ул. Арча яклары бүген дә бәхетле яктыр. Арчада педагогия училищесы (хәзер көллият) эшли. Хәтта Казанда, безнең көннәрдә Казанда ачылган татар мәктәпләрендә шул уку йортын тәмамлаган сылу яшь кызлар укытып йөри.

Безнең яклар – Болгар ягы. Болгарның шанлы гасырлары артта калды. Безнең якларда да атаклы мәдрәсәләр булган. Инде күптән бер район үзәге кадәр генә калган Болгардагы бердәнбер педагогия

училищесын да, Куйбышев сусаклагычы төзегәндә бинасы су астында калды дип (?!), ябалар. Дәүләт исеменнән икеләтә җинаять кылына...«Эх, ул училищены бүген булса да янәдән ачарга вакыт җиткәндер бит инде...» дип, мин күңелем белән туган якларыма кайтып (кунакларның икенче яртысы Әлки-Болгар ягыннан килеп Казанда яшәүчеләр) уйлап алам.

...Кунакларны авызына каратып, йомры сүзне сибеп, мәҗлесне җылытып утыручы кеше дә шул Кышкардан килгәннәрнең берсе булды. Әдәбияттан хәбәрдар, шигырь-җыр ятатучы, ялгыз җырларлык матур тавышы белән җырлап, җырдан мәзәккә, мәзәктән тиз генә биюгә күчә ала торган кеше ул Фарук исемле кырык яшьләрендәге безнең кода, янында чибәр хатыны һәм унберенче сыйныфта укучы улы. Фарук сөйләгән мәзәкләр гыйбрәтле хәлләрне дә искә алу белән бергә бара. Шуларның берсе турында әйтеп китәсе килә. Унсигез яшендә, әле Совет Армиясенә киткәндә, авылдан районга юлсыз юллардан бара-бара килеп җитсә, соңга кала язган бу – отрядны җыйганнар, тезгәннәр, озатырга торалар. Егет тиз генә хәлне чамалап ала да (командирның моны башыннан сыйпамаячагын), озатырга килгән халыкка карап, саубуллашу җырын җырлап җибәрә, гүяки хордагы башлап җырлаучы яисә бөтенләй Батырҗанның үзе. «Хорда җырлаучыларның» – озатырга килгән халыкның гына түгел, командирларның да күзе яшьләнә, күңелләре йомшый, соңара язган егетне әрләми генә иптәшләре белән бергә озатып җибәрәләр. Менә ул җыр:

Утырамын да уйга батам,
Күк күгәрчен кулда уйнатам.
Чакрым саен чуар багана,
Авыр илдән киткән балага.
Уйлыймын да җырлап җибәрәмен,
Җырлар белән күңелем юатам.
Чакрым саен багана кем куйган,
Туган-үскән илдән кем туйган?
Утырдым көймәнең, әй, түренә,
Карадым суларның төбенә.
Чакрым саен багана кем куйган?
Туган-үскән илдән кем туйган?
Суларның төбендә һич кара юк,
Ил генәң ташлап китми чараң юк.
Чакрым саен чуар багана,
Авыр илдән киткән балага.

Онытмаган кода бу җырны, матур итеп тагын җырлады.

Иңгә иңне, кулларны бер-берсенең җилкәләренә куеп җырлашкан халкыбыз вәкилләренә – бу мәҗлес кунакларына карап тордым да: «Аллаһуга шөкер, боларда халкыбызның тарихи язмышын тою сизгерлеге дә, шул авыр язмышны яктыртып, яңартып җибәрерлек көч тә бар әле», – дип уйлап шатланып утырдым.

*2000*

**БЕЗ ИСӘН**

Вакыт – ком сәгате. Әнә, энә күзеннән генә агып ятса да, ике меңьеллыкның алтын тавын өеп тә куйган...

Әйе, үткән гомер – алтын тавы. Адәм баласы үткән көнгә багып, юкка гына «алтын чагым – ялкын чагым» димәгәндер. Бер караганда, гасыр узу, меңьеллыклар алышыну, берсе тулып икенчесе башлану бик тә табигый бер хәл кебек. Кешеләр һәрнәрсәне тәртипләргә, аерым «киштәләр»гә урнаштырырга яраткан кебек, йөзьеллыкларга, меңьеллыкларга бүлү дә аерым бер шартлы тәртипкә салу гынадыр инде ул. Өстәвенә төрле халыклар, төрле дин тарафдарлары бу бүленешләрне үзләренә генә хас тәртиптә алып бара.

Еллар узган саен, олылар сүзе искә төшә, кире әйләнеп кайтып, колакта яңгырый. Без кечкенә чакта әниебез: «Балалар, Аллаһы Тәгалә Җир йөзендә элек яшәгән, хәзер яшәүче барлык адәм балаларын да исәптә тота. Алар Аның каршында үлән сабаклары кебек калгып торыр», – дип сөйли иде. Бала күңеле моны аңлаганмы, юкмы – инде әйтә алмыйм, ә сүзләр бүгенгедәй хәтердә. Соңгы елларда кампитр дигән нәрсәләр тормышка кереп, бөтен илләрдәге халыклар-кешеләр турындагы мәгълүматлар шул санакларга аерым-аерым һәрберсенең үз күрсәткечләре белән кертелеп, язылып куелгач, әниебез сүзе хәтердә тагын яңарды, сорау туды: «Аллаһы Тәгалә яраткан мәхлук адәм баласы кампитр белән эш иткәндә, нишләп әле Бөек Көчнең Бөтенгаләм кампитры булмасын ди?! Тик адәми акыл күзалларлык шәкелдә түгелдер ул...»

Әйе, адәм баласы күпме фәнни ачышларга ирешсә дә, нинди генә аргамак-техниканы йөгәнләсә дә, күкләргә космик корабларда менсә дә, нинди генә катлаулы математик һәм башка исәпләүләр алып барса да, фаразлаудан артык уза алмый, аның ачышлары да йә хата ясау, йә алдагы ялгышларны төзәтү

генә. Адәм баласы дөньяны танып белүдә кайчан күбрәк уңышларга ирешкән – бу да бәхәсле. Әле хәзер дә серләре ачылмаган Мисыр һәм Америка индеецлары пирамидаларын төзүчеләр табигать серләрен белеп, аның белән күбрәк берләшә алганмы, әллә Галәм корабында очып йөрүчеләрме? Әйтик, әле XX йөз башында җайлап кына тарантаска утырып, үз янындагы әңгәмәдәше белән сохбәтләшеп баручы бәхетле булганмы, әллә бүгенге интернетта «сайт ачып», Җирнең теге ягындагы кеше белән мәгълүмат алышучы үзен бәхетлерәк хис итәме? Гасырны озатканда һәм яңасын каршы алганда вөҗүдебезнең сизү, тою, шәрехләү ноктaларын ныграк уятасы, тарих җилләренә йөзебезне тагын да ачыбрак куясы килә. Тарих җиле – вакыт җиле. Өстәвенә төркиләрдә тарих дигән сүз турыдан-туры вакыт дигән сүзне дә белдергән.

Һәм, әлбәттә, мондый уйлар халкыбыз язмышына барып тоташа. Татар халкы Аллаһы Тәгалә тарафыннан кыерсытылган халык түгел, аңа бөеклек бирелгән. Безнең бабаларыбыз гаҗәеп зирәк булганнар: алар Ислам динен кабул иткәннәр һәм шуның аркасында үзләренең телләрен, мәдәниятләрен, гореф-гадәтләрен дә саклап калганнар. Ислам дине теләсә кайсы милләт кешесенә ирек бирә: мөселманча яшәү рәвешеннән син үзеңнең телеңне, әдәбият-мәдәниятеңне алыштыр дигән таләп килеп чыкмый. Ә бит безнең байтак кына төрки туганнарыбыз (Дунайдагы болгарлар, казак булып китүчеләр һ.б.), носарилыкны кабул иткәнлектән генә, үзләренең милли йөзләрен югалтканнар.

Болгар-татарларга иң авыр чакларда, патша самодержавиесе чиновниклары «тегендә китегез, монда килегез» дип куган елларда, Ходай Тәгалә безнең өчен пәйгамбәрдәй булган Габдулла Тукаебызны – телне тел итүче, халыкны халык итүче бөек шәхесебезне җибәргән. Бөек шәхесләребезнең йөрәк көче белән тупланган рухи байлыкларыбыз безне менә тагын яңа гасырга, яңа меңьеллыкка әйди. Шул рухи байлыкның күп өлеше, билгеле, татар әдәбияты.

Әйе, Габдулла Тукай бүген дә безнең куллардан тотып алып баручы. Шул ук вакытта ул бүген дә сер: үзе, тормышы, иҗаты да. Аңарда «әсхәбе кәхәфлек» ярылып ята.

Әдәбиятта рухи бәйсезлек үрнәген без белгән чорда Сибгат абый Хәким мөмкин булган шартларда мөмкин кадәр күрсәтте кебек. Нихәтле тырышып карасалар да, тышкы бәйсезлеккә якын да килә алмыйча, күрәсең, эчке бәйсезлекне дә югалтып, Сибгат абыйның кайбер каләмдәшләре-фронтташлары, ачыла алмыйча (талантлы шагыйрьләр) иртәнге чык кебек китеп бардылар. Нигәдер нәкъ шул елларда «шагыйрь гомере озын булмый ул» дигән бер гыйбарә телгә кергән иде. Тик Фирдәүси (90 яшь), Низами (69 яшь), Хәйям (75 яшь) һ.б. турында эндәшми иделәр.

Озын гомерле булу да бик шәп. Ике гасыр арасын тутырып яшәп, үзләреннән соң яктылык көлтәседәй мирас калдырып киткән Нәкый Исәнбәт, Әмирхан Еники, Гомәр Бәширов, рәсем сәнгатебез Тукае Бакый Урманче кебек, мәсәлән.

Әйе, татар әдәбияты – безнең олы мирасыбыз. Бу соңгы йөзьеллыкта гына түгел, безгә билгеле тарихыбызның башларында да шулай булган ул. Кол Гали тарафыннан «Кыйссаи Йосыф» китабы кебек мөкәммәл, камил әсәр язылыр өчен, ул чакта ук артында меңьеллык (ә, бәлки, күбрәк тә!) әдәби һәм мәдәни тарихың булу кирәктер. «Бакыргани» китабындагы әсәрләр, «Идегәй» дастаны, Сәйф Сараи, Мөхәммәдъяр иҗаты да шуны исбатлый. Бигрәк тә Мөхәммәдъярның «зарлануы» кызыклы. Бездә өч кешенең икесе шигырь яза, ди ул. Мөхәммәдъяр заманында гына, кинәт кенә, уптым илаһи дигәндәй, бөтен халык иҗатка-әдәбиятка керешмәгәндер бит инде?

Соңгы елларда, бигрәк тә үткән ун-унбиш ел эчендә, бездә тарих белән кызыксыну җанланып китте, тарихчыларыбыз кыю фикерләр әйтә, яза башлады. Кубрат хан заманындагы Болгарстанны уйласаң, гасырлар буйлап күчсәң, шунысы да кызык икән әле. Монголлар чаптырып узып киткәч тә (билгеле, үзләренең идарәчеләрен, салым җыючыларын калдырып), империянең безгә караган өлешенең чикләре шул ук диярлек: Кубрат хан заманындагы чикләргә туры килгән Урал-Иделдән Төньяк Кавказ һәм Кырымга чаклы. Бу тагын бер кат бирeдә элек тә, Алтын Урда чорында да, нигездә, бер үк төрле этник халык яшәгәнен искәртә түгелме?..

Идел буе болгарлары көчле дәүләткә әйләнгәч, анда да илханнарның аерым биләмәләре – канаулар, коймалар белән әйләндереп алынган кальга-кирмәннәр аз булмаган ич. Мәсәлән, минем туган авылым Чуаш Кичүендә андый кирмән урыны авылның «Тау башы» дигән җирендә, кырыеннан Кече Чирмешән ага – канауларга ерып су кертелгән. Чирмешәннең «Кызыл яр» дигән жиреннән, энҗе кебек суларын челтерәтеп (ничә гасырлар буе икән инде?!), чишмә агып ята. Исеме «Изгеләр чишмәсе», суы гаҗәеп тәмле (әбиләргә, әниләргә ияреп, без бала-чага да шунда еш бара идек. Анда боткалар, ашлар пешә, терлек тә чалына иде). Ә яр өстендә – җиде изге кыз каберлеге! Бөтенесе дә Болгар дәүләте буенча сибелгән шундый кирмәннәр, чишмәләр, изге кызлар зиратлары кебек бердәй кабатлана, тәңгәл килә. Бу кирмән урынын тикшерергә археологларның кулы җиткәне юк әле. Ә моннан 30 еллар элек нәкъ менә кирмән өстендә дуңгызлар абзары тотканлыкларын әйтеп тә торасы килми. Тик шатлык та бар әле: чишмә өсте, демократия җилләре исә башлауга ук, түбә күтәреп тотып алынды, җиде изге кыз каберлегенә дә чардуган корылды. Ә менә шулай ук моннан 30–40 еллар элгәре бульдозер белән эттереп тигезләнгән курган-корганнарның эзләрен кем табып бирер икән? Безнең якларда берәү генә түгел иде алар. Берсенең, бик биегенең, урынын әле хәтерлим дә кебек.

Әйе, еллар су кебек ага тора, татарның үзенә генә караган проблемалары үзе белән бергә бара бирә. Үзебезне артык мактамыйча һәм түбән дә төшерергә тырышмыйча, шуларның бер-икесен генә әйтеп китик. Берсе – татарның сибелгәнлек-таралганлыгы һәм катнаш никахларга керүе. Артык мактамыйча дигәндә, татарның үз көченә ышанып, дөньяның әллә кайсы якларына барып чыгуы күз алдында тотыла. Ләкин булдыклылыгың белән туган илеңә ныграк бирелеп, аны гына яклашып яшәсәң, әйбәтрәк түгелме? Бездә морзаларның «акларының» да, «караларының» да читкә «кыяклавы» 1552 елга кадәр үк гадәткә кергән.

Татарның катнаш никахка керү гадәте Совет чорында чәчәк атты. Элек тә, чукындырудан беркадәр котылгач, бу бәладән безне динебез саклаган. Ә бүген? Тернәкләнеп килүче динебез генә саклармы безне? Әнә, «алга киткән милләтләр» бүген югары технологияләр белән шашына бит.

Японнар тормышыннан бер нәрсәне искә төшерәсе килә. XVIII гасырның урталарыннан булса кирәк, япон дәүләте үзен башка бөтен халыклар, илчелекләр өчен ябык дип игълан итә, барлык чит кешеләрне илдән чыгара һәм шул вазгыятьтә төгәл 150 ел яши, ягъни халык «үз казанында кайный». Менә шуннан бүген без белгән «алтын» куллы, «кампитр» башлы япон милләте «килеп чыга». Хәрби реваншизмнан бөтенләйгә ваз кичеп яшәп яталар, бөтен дөнья халыкларын япон башы уйлап чыгарган тауарларга күмеп. Инде ничә еллар бөтен дөнья «япон могҗизасы» турында сөйли. Бер үк вакытта үзләрен алга киткән дип хисаплаучы Аурупаның кайбер илләрендә, Кушма Штатларда, киң халык белмәгән әллә нинди «фәнни-тикшеренү» эшләрен алып баручы ябык институтлар барлыгы турында хәбәрләр йөри. Бу институтларны, янәсе, Җир йөзендәге кешеләрнең артык нык үрчүе борчый, Аллаһыдан узып, алар үзләренең «көйләүләрен» эшләп яталар, имеш.

Без, әгәр дә үзебезне яңа меңьеллыкта исән-сау яшәячәк милләт дип саныйбыз икән, димәк, рухыбызны ныгытырга тиешбез. Чор чирләреннән тәнебезне һәм рухыбызны сакларга. Менә шунда инде безгә татар әдәбиятының, сәнгатенең көче-куәтенә таяну кирәк.

Ә әдәби проблемаларның берсен, бәлки, үзе дә сизмәстән, «Шәһри Казан» гәҗитендә Наҗия ханым Садыйкова күтәреп чыкты. Әмма ул кире яктан күтәрә. Янәсе, нигә татар язучыларына китап бастырып чыгару өчен аерым матди ярдәм булырга тиеш? Наҗия ханым, базарча яшибез дип, әдәбиятны үстермәскәме? Кешелек цивилизациясеннән төшеп калыргамы? Мәскәүләргә барсаң, хәтта бүгенге авыр заман дип саналган көннәрдә дә китап кибетендә шаулап-гөрләп китап алалар. Мин, шәхсән, үзем Мәскәүдә китап кибетенең кассасына нәкъ 15 минут (!) чират тордым. Кайда, нинди тауарга чират бар хәзер? Наҗия ханым, сез безнең китап кибетләренә кагылгалыйсыздыр, бармы анда китап алучылар? Бармы кассага чират?

Сезгә тагын шунысы да мәгълүм бит инде: әгәр дә безнең милли югары уку йортларыбыз шаулап эшләп торса, хәл бүтәнчә булыр, татар әдәбиятын укучы икеләтә, өчләтә артыр иде. Бүгенге көндә, ярый әле, театрларыбыз эшләп тора, алар телне-рухны нык саклый. Театрга бөтенләй әдәбият укымаучылар да йөри ...

XX гасырның соңгы елларында куркыныч нәрсәләр инде җитәрлек булды дисәк, әле тагын шунысы да бар икән: «кешене клонлаштыра башлыйбыз, ягъни теләсә кемнең тән кисәгеннән (генетик коды ярдәмендә) кеше үстереп чыгарабыз» дип куркыта башладылар. Бер караганда, гаять зур фәнни ачыш, прогресс-алгарыш булып күренгән бу хәл, кешенең болай да келтерәп кенә эләгеп торган мораль-этик нормаларын туздырып, суга салып агызып җибәрмәсме? Һәм, гомумән, кешегә карата әле бераз сакланып калган гуманистик мөнәсәбәт җимерелмәсме?

Татар халкы яһүдиләр кебек дөньяның теләсә нинди төбәгендә «дәүләт эчендә дәүләт төзеп» үк яшәмәсә дә, һәр җирдә Аллаһыга шөкер, татар җәмгыятьләре төзеп яши. Яшерен түгел, ачык җәмгыятьләр. Кил, күр, катнаш, тормышың турында сөйләш, җыр-көйдә берләш, телеңне өйрән, саклаш.

«Рәхим итегез, милләттәшләребез!» диелә бу җәмгыятьләрдә, һәм аларның теләсә кайсы башка милләт вәкилләренә дә ишекләре ачык. Татар шундый инде ул, холкын яшерми, бизәп-матурлап күрсәтми, ачык йөз, кунакчыллык, башка милләтләргә карата киң күңеллелек күрсәтә, хезмәт сөючәнлек аның җанына салынган. Шул күркәм яклары белән ул күпмилләтле халыклар гаиләсендә, бик кирәкле бер гаилә әгъзасы булып, өченче меңьеллыкның ишеген ачып керде. Бәхетле тормыш сәфәрләре телик халкыбызга, барчабызга һәм бөтен кешелек җәмгыятенә!

*2001*

## ГОРУРЛЫК ХИСЕ

Әгәр дә мин күпердән чыкканда шулхәтле дә шатланам, канатланам, үземне бер күркәм бәйрәмдәгедәй хис итәм дисәм (әле күпернең араларны, йөрәкләрне-күңелләрне бер-берсе белән тоташтырып, күрештерүче икәнлеген хәтердә тотып әйтсәм дә), беренче карашка аңлашылып бетми кебек тоелырга мөмкиндер.

Әйе, мин аерым бер күпер турында, атап әйткәндә, җөмһүриятебезнең көньяк-көнчыгыш районнары халкының илле-алтмыш ел буена берөзлексез: «Эх, кайчан булыр икән Саескан тавы каршында Кама аша күпер-күперкәй?!»– дип өзгәләнеп, авыз суларын корытып сөйләгән күпер хакында әйтәм. Ходай рәхмәте, бар бит шул күпер хәзер – төзелде бит! Бу күпер безнең ун елга сузылган суверенитетыбызның бик олы бер җисми һәм мәгънәви җимеше – символы булып та тора. Кич белән якты утлар балкышында үткәндә бигрәк тә хозурлыкта каласың – йолдызлар Җиргә төшкәнмени! Күперебездән без үзебез генә – татарстанлылар гына үтмибез, ерак араларга баручылар да выжылдатып йөри башлаганнар. «Булдыралар бу татарлар», – диләрдер алар, мөгаен!

Күперне төзеп бетереп, йөри башлауга инде берничә ай үтсә дә, Әлки ягы халкы аның турында әле бүген генә булган хәлдәй сөйли. Каюм Насыйри бабабыз әйткән, эшләгән эш булганда бераз гына мактау да килешә, дигән. Күперне төзетүчегә, төзүчеләргә халыкның рәхмәте иксез-чиксез.

Авыл халкы өйләренә газ керүен дә бер могҗиза итеп сөйли. Булмады бит элек. Булмаганны булды дип әйтеп булмый. Элегрәк Татарстан җиреннән ел саен йөзәр миллион тонна нефть чыгарып кудырганда, аннан кергән акчаның беразын гына булса да нишләп шундый кирәкле гамәлләр өчен безнең үзебезгә дә калдырмадылар икән дигән беркатлы сорауны инде бирәсе дә килми, чөнки ни өчен икәнлеген белеп тордык...

Бу юлы мин туган авылым Чуаш Кичүенә Корбан бәйрәменә һәм туган мәктәбемә чакырулы булганга кайткан идем. Андагы самими тантаналардан күңелнең тулып ташуын әйтеп бетереп булмас.

Корбан ашында утырганда сиксән елга тулган дини өзеклек хакында бөтенләй онытасың. Матбугатта, телдән дә динчеләребез хакында тәнкыйть сүзләре дә ишетәбез, тәнкыйтькә җирлек тә бардыр, бәлки. Ләкин байтак нәрсәләр эшләнгән дә икән.

Туган мәктәбемдә укучылар, укытучылар белән очрашу шатлыгы да күпер төзелеп бетү шатлыгы белән бергә килеп кушылды. Шатланырсың, кайвакыт якташларыма: « Менә чират җитә, менә чыгабыз», – дия-дия дәрья буенда икешәр-өчәр тәүлек тә үткәрергә туры килә иде. Күпер турындагы безнең шатлык хисләре теге, алга киткән илләр дигән ил кешесенә, халкына бик тә беркатлылык булып тоелыр иде. Тик бит һәркем үз юрганына карап аягын суза, һәркемнең үз тәртибе яисә тәртипсезлеге, һәркемгә үзенеке якын. Кем ничек яши бит. Без менә шулай яшибез, әмма безнең халык аздан да шатлана белә. Хәер, Кама аша шундый зур, олы күперне салдыруны беркем дә кечкенә эш дип әйтә алмастыр.

Ә мәктәбемдә очрашу дәвам итә. Укытучылар, китапханәче апалары, укучылар үзләре язган шигырьләрне укыйлар – яраталар безнең авылда шигырьне. Бөтен нәрсә мәктәптән, хәтта беренче укытучыдан башлана. Минем үземнең дә беренче укытучым Галия апа Сабитова-Мингазова хәзер дә миңа хатларын шигырь белән яза. Әйдә, тормыш кайнап-кайнап үзенчә үзгәреп барсын, әмма туган мәктәбеңдә нәни генә балаларның чишмә кебек челтерәтеп шигырь сөйләүләре, изге җан беренче укытучының шигырь белән хат язарга дип ак кәгазьгә иелүе теләсә нинди яшәешнең дә иң матур бер бизәге дигәнне беркем дә кирегә исбатлый алмастыр.

Халкыбызның, бәхет бер килсә, килә бит ул, дигән сүзе бар. Туган авылыма кайтып килүгә атна-ун көн узуга, Ходай рәхмәте, туган ягыма – Әлкигә каләмдәшләрем – күренекле язучыбыз Мөсәгыйть Хәбибуллин һәм Татарстан Язучылар берлеге каршында оештырылган Матур әдәбиятны пропагандалау бюросы директоры, драматург Рәдиф Сәгъди белән тагын бер мәртәбә кайтырга насыйп булды. Алты авыл мәктәбендә укытучылар һәм укучылар белән очрашуны күңел бәйрәмнәре дип атамый һич мөмкин түгел. Районның мәгариф бүлегеннән Фәүзия Бари кызы Гыймадиева һәм «Әлки хәбәрләре» гәҗите баш редакторы Азат Рөстәм улы Низамиев безнең юлдашларыбыз булды. Якташларымның ягымлылыгы, игътибарлыгы күңелне эретеп җибәрүләрен әйтеп, аңлатып бетереп булмас. Олуг шагыйребез Сибгат ага Хәкимнең сүзләрен искә төшереп, туган ягым өчен «бер горурлык хисе» туды, дисәм, аңлашылыр дип уйлыйм. Ә мәктәптәге очрашуларны кыңгыраулар чыңлавы парады дип әйтми хәлем юк – һәрбер баланың күңеле һәм сөйләме кыңгырау ич! Менә ничегрәк тезелеп китеп чыңлады ул кыңгыраулар: иң беренче Алпар мәктәбе. (Шамил Маннапов, Мөдәррис Вәлиевләр мәктәбе!) Укучылар җыр-бию, шигырь бәйрәме ясадылар. Аннан – Иске Чаллы мәктәбе. Тагын да үзгә очрашу, тагын да шигырь әйтү, тагын да яңарак, матуррак мәктәп бинасы. Мөсәгыйть Хәбибуллинның борынгы болгар якташларына болгар тарихын тагын да канатланыбрак сөйләве, юмор – йомры сүзне җигә белүче Рәдиф Сәгъдинең тыңлаучылар йөзендә елмаю уйнатуы, көлү авазлары чәчрәтүе...

Кыңгырау чыңлавы тавышы эзеннән Карга авылы мәктәбенә барып керсәк, укытучыларның ярыш-конкурсы тәмамланып тора, язучылар белән очрашу икесе бергә ялганып китте. Бердән, бүгенге авыл укытучысының үсеш биеклеген күреп гаҗәпләнсәк, икенчедән, укучылар белән аралашудан зур рухи көч алдык. Биредә Айгөл исемле кызның шигырьләре аерым хәтердә калды. Безнең өчен тагын бер бик әһәмиятле әйбер: мәктәп бинасы өр-яңа, мәрмәрләп төзелгән.

Икенче көнне безгә Татар конгрессыннан җаваплы хезмәткәр Илдар Миңлегәрәев һәм, әле яшь кенә булса да, фәннәр кандидаты булып өлгергән Илһам Фәттахов килеп кушылды. Алар бик игелекле гамәлләр эшлиләр: конгрессның эше турында сөйлиләр, мәктәпләргә әдәби китаплар һәм методик

ярдәмлекләр дә бүләк итеп калдыралар. Иртән үк эшебезне Түбән Әлки мәктәбендә башладык. Бу минем өчен кадерле мәктәп. Биредә мин 8–10 сыйныфларда укыдым. Күңелем белән үземнең элекке укытучыларым: Шәүкәт Ногмановны, Нурания апаны, Фаик Мәхмүд улын, Мәһинур апаны, Оркыя Талиповнаны, Мөстәкыйм абыйны, Халидә апаны (исемнәре ничек хәтердә калган шулай язам) һәм башка бик күпләрне эзлим. Алар мәктәптә юк инде, әмма аларның эше яши, мәктәп хәрәкәттә, белем үрләренә менүне дәвам итә.

Очрашуларның маршрутлары уйлап, район үзәгенә якынрак мәктәпләрне дә, әкренләп ерагая барганнарын да, иң читтәгеләрен дә рәнҗетмәскә тырышып төзелгән иде. Иң читтә дигәне мөгаен Чиябаш мәктәбе булгандыр. Кичләтеп кенә барып җиттек, әмма барлык балалар мәктәптә иде. Һәрвакыттагыча, безнең халыкка хас самими сөйләшү-аңлашу, бер-береңнең йөрәк җылысын бүлешү. Шунысы да бар: тере язучыларны беренче мәртәбә күрәбез, диделәр. Булмады бит андый ерак, хәтта якынрак дигән авылларга да асфальт юл. Менә хәзер бар, рәхим итегез. Нишлисең, машина заманы, тизлек заманы – яхшы юллар кирәк.

Очрашуларның иң күркәме район үзәгендәге ике мәктәптә үтте дисәм, башка мәктәпләрнең ролен кечерәйтү булмас – район район булырга тиеш тә бит инде. Мәктәп бинасы да иң-иң әйбәте, укучылар да сорауларны сайлап, әһәмиятлеләрен бирергә тырышалар, үз һөнәрләрен дә тагын да каушамыйчарак күрсәттеләр. Мәктәп директоры Нәфисә Заһит кызы Хөснетдинованың бер елмаеп каравы да бала күңелендәге теләсә нинди кара болытны да эретерлек. Шундый елмаюны туган авылым Чуаш Кичүе мәктәбе директоры Гөлҗиһан Ибраһим кызы Мөбәрәкшина йөзендә дә күреп шатланган идем. Гомумән дә, әйтик, без булган мәктәп директорларының һәрберсенең аерым үзенчәлекләрен билгеләп, җыеп чыксак та, без татар халкының җыелма бер матур образын тудырган кебек булыр идек. Һәрберсе уңган-булган кешеләр алар. Бүгенге көн мәктәп хуҗалыгын тотуның ни-нәрсә икәнлеген ата-аналар да бик яхшы аңлый.

Әлки ягының бөтен тормышы ал да гөл икән дип исбатларга керешкән бу димәсен иде укучым. Бар инде ул проблема-мәсьәләләр. Татар китабы, татар китап кибете мәсьәләләреннән алып, хуҗалык, көнкүреш хәлләренә кадәр барып тоташа уйлар-теләкләр. Авыллар кырыеннан зур асфальт юл уза, тик хәзер халыкны шул такыр-каты юлның авыл урамына кермәве борчый. Бездә майлы кара туфрак, шуңа күрә юеш вакытта машинасы булган кешенең олы юлга чыгу сәфәре, еш кына, тирән пычрактан «ат»ын трактор белән тартып чыгару белән тәмамлана. Авыл халкының үзенең артып калган продукциясен тиз генә барып сатып кайтырга мөмкинчелеге юк. Базар, зур шәһәрләр ераграк. Бәрәңгене булса да килеп җыеп китсеннәр иде, диләр. Авыл халкының әле яңарак эшли башлаган җитәкчесе Фердинанд Мидхәт улы Дәүләтшингә ышанычы зур.

Районыбыз зур шәһәрләрдән ераграк, дисәм дә, аңа да берүк экономик законнар тәэсир итә. Бензин бәяләрен генә искә төшерик. Солярка һәм башка нәрсәләрне әйтеп тә тормыйм. Бу турыда көн-төн әйтелә, языла. Рәсәйдә хезмәт хакы бер тиен булса, бәяләре аның йөз тиен.

Әдәби-мәдәни тормышка әйләнеп кайтсак, безнең якның зур язучысы, шагыйре, легендар кешесе Нәби Дәүлигә ихтирамны нык арттырып, аның музеен берзаман эшләп бетерсәк, бу инде үзебезгә үзебез күрсәткән олы хөрмәт тә булып торыр иде.

Шулай инде, җитешсезлекләр булмаса, безнең бөтен эшебез беткән булыр иде. Кызык та булмас иде. Кайбер җитешсезлекләр генә туган ягымнан алган матур тәэссоратны һич тә томалый алмый. Самими-эчкерсез халкым Чирмешәннең Кызыл ярыннан агып чыккан мәңгелек Изгеләр чишмәсе кебек, күңелне сафландырып, акландырып, бетмәс көчләр биргәндәй рухландырып тора. Туган якның шифасын тойган бер мин генәмени? Аның шифалы көче барчабызга тигез ирешә.

*2003*

**УҢАЙ ҖАВАП**

Ул көннәр... Гаҗәеп көннәр... Өмет чаткысы йөрткән көннәр... Әле кайчан гына... әле кайчан гына... Ә чынында күпме гомер үтеп киткән. Ирек алабыз дип йөрүебезгә ун ел тулып үткән. Дөресрәге, ун ел гына түгел, ә унике. 1988 елдан татар халкының ирек яулавы янәдән бер яңа эчтәлек алды, конкретракка, максатчанракка әверелде. Сәбәпләре, җирлеге туды. Мәскәү каты кысып тоткан дилбегәне бушайтты, ул бушайтуны демократия дип атады. Татарга шул гына кирәк иде дә, чөнки ул үзе табигате белән демократ халык, аның янында бергә теләсә нинди кавемнәр яшәсен, тик татарга эшләргә генә комачау итмәсен, татарның телен алмасын, җырын алмасын, югыйсә ничәмә йөз еллар киресен эшләргә теләүчеләр уңыш казанып килә бит.

Менә бүген демократия чәчәкләрен шиңдереп, чүплеккә ата башлаганда, безнең Бәйсезлек декларациясен шул ук Мәскәү тарафыннан юкка чыгарып йөргән көннәрдә, без барыбер үзебезнең кадерле хатирәләребезне искә төшерергә, аларны һәрберебез беркадәр теркәп куярга тиешбез. Тарих өчен. Үзебезнең тарих бит.

1988 елда Татар иҗтимагый үзәге төзелде, аңардан татар яшьләре оешмасы бүленеп чыкты, аның исеме «Азатлык» булды. Татар иҗтимагый үзәгендә, нигездә, Марат Мөлеков рәислек итте, «Азатлык»та – Ирек Гарипов. Һәр икесенең дә оештыру сәләте ташып тора, ярдәмчеләре дә күп. Аларның эшчәнлеген аерым бер тикшеренү, аерым хезмәт итеп язып булыр иде, алар моңа лаек. Әйтик, Ирек Гарипов милли хиснең ни икәнлеген дә онытып бетергән яшьләребезгә дә милли рух өрә алды, аларны уятты (татарны уятуның ничәнче мәртәбәседер инде бу?), көрәшкә берләштерде, шул чактагы авырлыкларга эһ тә итмәде. Менә Ирек ут капкан кебек йөгереп кенә безнең бүлмәгә килеп керер дә: «Кердек бит. Егетләр-кызлар үтеп кердек телевидениегә. Әйттек үз сүзебезне, карагыз бүген кич, башкаларга да әйтегез», – дияр дә, ай-вайлап кыстаган бер чынаяк чәйне йотып, җил-җил чыгып та китәр. Аның эшенең иге-чиге юк. Бер җиргә пикет куясы (Мәскәүдән кемнәр генә килмәде ул елларда. Борис Ельцин үзе дә): күрсеннәр мәскәүлеләр татар яшьләренең нинди лозунглар-таләпләр куйганын. Икенче җирдә зур митингка әзерләнәсе. Аның өчен күпме әләм тегәсе, күпме шигарь-лозунглар язасы. «Азатлык»ның уставын тикшерәсе, кабул итәсе, өйгә әллә төнлә кайтып җитеп була, әллә кунып кына калырга туры килә. Ә өйдә әнисе Рабига ханым бердәнбер улын ут йотып көтеп тора. Усаллар ул-бу гына эшләмәсеннәр, исән-сау гына булсын тынгысыз улы, иминлек теләп дога укый... Ә хәвеф бар. Үзләрен демократ дип атаган Мәскәү яклылар аерым җыелалар һәм ыгы-зыгы, бәрелешләр китереп чыгарырга тырышалар. Шундый куркыныч мизгелләрдә Марат Мөлеков консерватория каршында Иҗтимагый үзәк җыенына килгән милләттәшләренә провокацияләргә бирелмәскә дип, микрофоннан яисә диктофоннан чакыру-өндәмәләр ташлый да Муса Җәлил исемендәге Опера һәм балет театры тирәсендәге икенче җыенга, Ирек мәйданы аша йөгереп чыгып, аларның микрофонына атылып килә дә намуска, тәртипкә, бергәлеккә чакыра башлый: «Татарлар азатлыкны үзләренә генә таләп итми бит, бахырлар, сезгә дә, безгә дә булсын, каршылыкка чакырмагыз, дус булыйк», – дип, тагын да үз җыенына йөгерә һәм, чынлап та, низаг булмый кала.

Ул елларда бераз нәшриятта эшләп алган Фәүзия Бәйрәмованың эш урыны безнең бүлмәдә иде. Фәүзия шулай ук милли хәрәкәтнең үзәгендә кайнады, ялкынлы мәкаләләр дә язды... Беркөнне (ул инде халык депутаты, инде Мөстәкыйльлек декларациясе кабул ителгән) Фәүзия гадәттәгедән дә ярсулы басып бүлмәгә килеп керде дә арлы-бирле йөренә башлады. Иркә Зөлкарнәеваның «ни булды» дигән соравына Россия президентын Татарстанда сайлатмас өчен (ничек инде Бәйсезлек декларациясе кабул иткән җөмһүрият күрше дәүләтнең башлыгын сайласын) нидер эшләргә кирәклеген ярып салды. Үзе ничек ялкынланып килеп кергән булса, шулай чыгып та китте. Чыгып барганда гына «Иртәгә сәгать унбергә Ирек мәйданына килегез!» дип чакыру салды.

Икенче көнне, әбәт вакытына туры китереп, Ирек мәйданына менеп киттек. Барсак, элекке обком бинасы янына халык җыелган, лозунг-шигарьләр, яшел әләмнәр һәм әз генә куак ышыгындарак (1991 елның май ае искиткеч эссе булды) урындыкта Фәүзия Бәйрәмова утыра, башында ак яулык, күкрәгенә «Сәяси ачлык» дип язылган плакат эленгән. Менә нинди эшкә керешкән икән Фәүзия! Шул ук вакытта без ул көннәрдә сәяси ачлык дигән сүзне ишеткәли идек инде. Уфада татар язучысы Айдар Хәлим Башкортстандагы татарларга, андагы башкортларга һәм урысларга булган кебек тигез хокук таләп итеп ачлык игълан иткән иде инде, мәйданда рәнҗетүләр булса да түзгән иде.

Фәүзиянең үз янына халыкны магнит кебек тартып китерә торган куәте-көче бар: мәйданда халык артканнан-арта барды. Фәүзия янына утырып, ачлык тотучы башкалар да пәйда була башлады: Рәшит Әхмәтҗанов (инде вафат), Балтыйк буе җөмһүриятләреннән азатлык өчен көрәшнең мәктәбен үтеп кайткан полковник Зәки Зәйнуллин, шагыйрь Газинур Морат, Чаллы фидакарьләре һ.б. – унҗиде-унсигез кешегә җиттеләр. Ачлык тоту мәйданы татарның сәясәт мәйданына әйләнде, һәркөнне ун мең кеше диярлек килеп-китеп йөри, ә зур митинг була дип хәбәр салынса, илле меңләп тә халык җыела. И-и, бу көннәрдә иң гүзәле ак яулыклы, ак шәлле әбиләребез булгандыр. Алар мәйданның үзенә бертөрле үзәгенә әйләнделәр. Тәсбихләре кулларында, намазлыклары букчаларында, китаплары белән бергә. Намаз вакыты җитте исә, тиз генә намазлыкларын алып, обком баскычларына җәеп салалар да догага керешәләр. Читтән килеп (элеккеге бөтен СССРдан) тәүлекләр буе пикетта торучы икенче бер милләттәшләребезне өйләреннән алып килеп чәй эчертүче, аш ашатучыларыбыз да шул ак яулыклы әбиләребез булды. Аларның изгелекләрен сөйләп бетерерлек түгел... Аннан әбиләр, бабайлар, яшьләр, урта яшьтәгеләр һәм бала-чага да рәткә тезелеп басабыз да «Азатлык» дип тамак карлыкканчы кычкырып урам әйләнәбез. Бауманга төшеп китәбез, Сөембикә манарасын урап кайтабыз. Суык тидерүчеләребез дә, эссе суктыручыларыбыз да булды. Ижаулардан кадәр йөгереп килеп җитә торган байракчыбыз Фәнүс Газизулла турында һәм тагын йөзләрчә, меңнәрчә фидакарьләр турында да бик күп итеп сөйләп булыр иде... Шул көннәрдә ул вакыттагы мәдәният министры урынбасары – бик милли җанлы кеше, архитектура һәм төзелеш белгече Габбас Мөхәммәтшин Сөембикә манарасына алтын ай куйдырып йөри, аңа бу эштә «Вакууммаш» инженеры, шулай ук милләт дип йөрүче Шамил Сәфәров (хәзер вафат) булышты. Аңа хәтле дип әйтергә кирәктер, Габбас Мөхәммәтшин бөтен баскычлары чүплек тавына әйләнгән манараны әрчетеп-чистартып, машина-машина чүп түктерде. Аннан манарага ай кую тантанасы. Айның эченә ай куюны сорап, тәкъдим итеп халык язган биш йөздән артык имзалы

хатны куеп калдыру... Ул вакытта беренче мәртәбә оешып, элеккеге атаклы Тукай исемендәге клубта эшен башлап җибәргән, Татар энциклопедиясе төркемендә хезмәт иткән Тәлгать Бариев та безнең бүлмәгә кергәләп йөри. Ул Казан дәүләт университетының физика факультетын (теоретик физика бүлеген) тәмамлаган, ә үзенең уенда татар милләте кайгысы, искиткеч фидакарь кеше. Татар гимназияләре ачтырып, шунда бәләкәй малаен укырга биргәнче көрәшәм, дип әйтә иде ул. Ирешге ул моңа, улы татар гимназиясендә укый хәзер, Аллаһыга шөкер. Тәлгать Бариев «Молодежь Татарстана» (элек «Комсомолец Татарии») гәҗитендә шулай ук ялкынлы, мантыйкый һәм фәнни яктан да бик нигезләп, туган телендә укый һәм сөйләшә дә алмаган урыс телле яшь татарларны да җәлеп итәрлек итеп бик тә үтемле мәкаләләр дә язды. Шуларның барысы өстенә ул әле Югары Советта тәрҗемәче булып эшли, урысчадан татарчага, татарчадан урысчага сессия барганда синхрон тәрҗемә итә, тик өлгереп булмый икән, ярдәмче кирәк. Тәрҗемә үзенчәлекле: сөйләп торган депутатның бер сүзен дә төшереп калдырмыйча, мәгънәне бозмыйча, депутат белән параллель рәвештә – бер үк вакытта микрофонга тәрҗемә итеп барырга, ә залда утыручы депутатлар тәрҗемәне наушник – колак микрофонынннан тыңлыйлар. Бу хәл күпмилләтле дәүләтнең демократия элементларын күрсәтеп торуы була инде. Ай-ваема карамастан, Тәлгать мине дә бу эшкә ризалаштырды, ә рөхсәтне Югары Советның тәрҗемә һәм башка кайбер эшләрне оештыручысы, шылтыратып, безнең ул вакыттагы нәшрият директоры Харис Әшрәфҗановтан алды.

Бик тә кызыклы һәм читен-җаваплы эш икән ул алай, пулеметтан аттыргандай дигәндәй, тәрҗемә итү. Көндәлек тормышта җайлап кына, әкертен генә сөйләшүче мин, бахыр, шулай итеп, әйткәнчә, сүзләрне аттыргандай тыкылдата башладым. Ул көннәрдә сессияләр бик озын, бик шау-гөр килеп, озак-озак үтә иде, иртәнге уннан кайчак кичке тугызлар җитә. Тәрҗемә иткәндә ял да сорала һәм шактый еш та, димәк, тагын ярдәмче кирәк. Мин бу эшкә Иркә Зөлкарнәеваны кодаладым. Директор бик үк риза булып бетмәсә дә, гомумхалык эше өчен булгач, килеште. Инде әйтеп үтелгәнчә, сессиядә синхрон тәрҗемә, парламентка цивилизация элементлары кертү белән бергә, татар теленә дәүләт статусы бирү юнәлешендә алга таба бер адым да булып тора иде.

Ә бу көннәрдә ачлык тоту мәйданында вакыйгалар куера, көн эсселеге кимеми. Иң беренче булып ачлык акциясен башлаган Фәүзия Бәйрәмованың кайбер көнне хәле бөтенләй начараеп та китә, ул күбрәк раскладушкада ятып тора: һәртөрле провокация куркынычлары туа... Ләкин халык бирешми, тынычлык саклый. Мәйданда сафлар сирәгәйми, халык агыла, ораторларын тыңлый.

Әгәр Татарстан 1990 елның 30 августында Бәйсезлек декларациясен кабул иткән икән, башка дәүләтнең президентын сайлауда аның катнашуы мантыйкка сыймый – халык шуны аңлый... Һәм, чынлап та, шулай булды да: Татарстанда Россия президентын сайлауда бик-бик аз гына тавыш җыелды, димәк, сайлаулар узмады...

Бәйсезлек – суверенлык декларациясен кабул итү сессиядә гаять четерекле шартларда барды. Декларацияне кабул иттермәс өчен ясалган басымнарны санап бетереп булмый, ә турыдан-туры көрәш, билгеле, Югары Советның үз эчендә, теге, үзләрен демократ дип атаучы депутатлар тарафыннан булды. Милли җанлы депутатлар мәсьәләне, кем әйтмешли, чәйнәп, авызларына салып «демократлар»га аңлаталар: демократия икән, борын заманнардан бирле үз туган илләрендә-җирләрендә яшәгән халыкның телен, сәнгатен һәм сәнәгатен саклап калу өчен, бәйсез дәүләт кирәклеген төшендерәләр, башка халыклар кебек дөньяга сибелгән татарның үзенчәлекләрен саклап калу өчен шул бер урын – Татарстан гына барлыгын тәкрарлыйлар. Шуларның барысына кушып, башка милләтләр җөмһүрияттә декларация кабул иткәнче нинди тынычлыкта һәм, үзебездән өстәп, рәхәттә дә дип әйтергә кирәктер, яшәгән булсалар, шулай ирекле яшәячәкләр дип белдерәләр, күмәк, бергәлектә яшәүнең халыкара нормаларын искә төшерәләр, әйтеп бирәләр. Әмма юк бит, әле Штанин торып баса, әле Грачев, аннан Михайлов, аннан үз маңкортларыбыз М.Хафизов, И.Солтанов, башкалары. Болары әле Казаннныкылар. Шундыйлар Түбән Камадан, Кама Аланыннан, хәтта ки Чаллыдан да бар иде. Болар һәммәсе үзләренең эчендә утырган бер фикерне – декларацияне кабул иттермәү уен тормышка ашыру өчен ни генә уйлап чыгармыйлар. Менә шул чакта, шул сессиядә килештерү комиссиясе төзелде. (Соңыннан, Татарстаннан күреп Мәскәүдә дә шундый комиссияләр төзи башладылар, аңа хәтле ишеткән нәрсәләре түгел иде. Гомумән, Мәскәү үткән ун ел эчендә Казаннан башка кайбер нәрсәләрне дә күчереп алды.)

Иң четерекле мизгелләрдә ул вакыттагы Югары Советның рәисе һәм килештерү комиссиясенең дә рәисе булган Минтимер Шәрипович Шәймиев гаять тә оста дипломатик йөрешләр ясады: үзенең чыгышларында бездәге халыкларның гомуминтересларын табып күрсәтеп, һәркемгә тиячәк уңай йогынтыны ачып сала белде, һәм эшләр шуңа барып җитте ки, төнге сәгать унбердә, бер тоткарланучыны исәпләмәгәндә (ул депутат Кама Аланыннан килгән иде), бертавыштан Бәйсезлек декларациясе кабул ителде! Тәрҗемә эшендә минем ун минутлык тәнәфес иде – залда аягүрә баскан депутатларның, кунакларның, күпсанлы журналистларның бик озакка сузылган кул чабулары дәвам итеп калды – мин мәйданга, халык янына очып дигәндәй йөгереп чыктым да ярты төн уртасында кайтып китәргә уйларына да килмәгән, ә «Нәрсә була?», «Ничек була?» дип суларга да куркып көткән

халыкка Бәйсезлек декларациясенең бертавыштан кабул ителүен әйттем. Мәйданда купкан шатлык диңгезе шаулары астында шулай ук тиз генә эш урыныма кереп киттем.

Төнге сәгать уникенче яртыда депутатлар таралыша башлады. Безнең депутатлар халык янына ашыга, ә демократлар исә: «Попридержите подол плащей, как бы на сувениры не оторвали», – дип үзләренчә шаяртып азапландылар. Без дә эшләрне бетереп, баскычлар буйлап төшә башладык. Шунда безгә тагын да иптәшләр килеп кушылды. Без бер-ике генә мизгелгә тукталып сүз алыштык, котлаштык, шуннан башны күтәреп карасак, депутатлар чыгып беткән диярлек, шул ук вакытта безгә таба Минтимер Шәймиев килә, үзе генә. Кызык бит, ул вакытта әле тән сакчыларының бүгенге кебек сырып алу гадәте булмаган икән. Без аны һәрберебез аерым-аерым котладык.

Төнге урамга чыктык, анда халык, анда бәйрәм, котлаулар, кыска нотыклар, гармун, җыр...

Декларация кабул иткәннән соң үткән елларда хәлләр төрлечә барды, анысы барыбызның да күз алдында. Гел ал да гөл генә булмады. Безнең өчен туган телебезнең язмышы күңелгә якын. Күңел исә җәрәхәтле. Уйланырлык нәрсәләр күп. Транспортта, вокзалларда татарча игълан итүләр булмагандай юкка чыкты. Эш урыннарына татар теле үтеп керә алмады, ә бит ул закон нигезендә дәүләт теле статусы алды. Баштагы елларда конкурс белән генә үтәргә мөмкин булган татар гимназияләренә, мәктәпләренә бару омтылышы кимеде. Югыйсә бит аңлаган кешегә безнең татар гимназияләренә, мәктәпләренә бер кереп чыгуың да җан рәхәте. Анда тәртип, анда матурлык. Ата-аналарга әйтәсе килә, әгәр дә балагыз рухи һәм җисми дә (!) сәламәт булсын дисәгез, аларны укырга татар мәктәпләренә, үзебезнең мәктәпләргә бирегез. Соңгы елларда тагын да баш күтәрә башлаган «Татар теле белән кая барасың?» дигән пошаманга бирелмәгез. Татар мәктәпләрендә урыс телен дә чытырдатып белеп чыгалар, иң мөһиме, балагыз тәрбияле булып чыгар. Яңа уку елы башланыр алдыннан бу турыда тагын бер кат кистереп әйтәсе килә.

...Әйе, эшләр гел ал да гөл булмады, үзгәртеп кору һәм демократия елларында, үзебезнең Бәйсезлек декларациясен кабул иткән хәлдә, бик күп форсаттан файдаланылмады. Туган телебезне тиешле югарылыкка кую – дәүләт теле итү мөмкинчелеге яралгы хәлендә калды. Күңелгә тигән башка нәрсәләр дә күп инде. Мәсәлән, Болгарга дип барып, Спас районында икәнлегеңне белү – кимсетелү генә дә ни тора. Безнең Болгар һәм Болгар арты яклары белән (басып алганнан соң) теләгәнчә уйнаганнар (яңа хакимияткә яраклы дип уйланылган халыкларны күчереп утыртканнар). Әйтик, тагын бер мисал: әле совет властеның беренче елларында да башта үзәге Түбән Әлки (гел татарлар гына яшәүче авыл) булган Әлки районы төзелгән, аннан тиз-тиз генә «аң»га килеп, ниндидер чуар, дүңгәләк халык килеп тулган Базарлы Матак дигән сәер исемле (борынгы исеме Кала Базар була) авылны Әлки районының үзәге итеп билгеләгәннәр...

Болары милли җанлы татарның күңеленә тигән нәрсәләре. Ә бит әле бездә төрле халык, төрле кеше дә күп. Кайбер очракта татарлар да: «Суверенитет безгә нәрсә бирде?» – дип сорау куеп, үзләре үк кире җавап бирергә тырышалар. Шулай инде, ваучер, милли фонд акцияләре (Татарстан үзе тараткан акцияләрне күпчелек халык шул фондка салган иде) хакында искә алган кеше дә юк дияргә була, искә алсалар да, сарказм, ачы көлү белән искә алалар. Чынлап та, әгәр дә җөмһүрият халкы, башта сөйләнгәнчә, барысы да ниндидер бер күләмдә акционерлар, акция тотучылар булып, алардан гаилә бюджетына бераз булса да керем килсә, менә хәзер Мәскәү Татарстан җирен-суын, табигый байлыгын, заводын-фабрикасын, гомумән, предприятиеләрен янәдән үзенә язып куя башлаганда, халык та йоклап калмас иде, халыкның акционерлар икәнлеген искә төшереп, бераз аяк терәбрәк сөйләшергә җай булыр иде. КВНнар, машина чаптырулар, хоккей командалары, бер карасаң ярыйдыр ул, ләкин алар гына бәйсезлек алып бирә алмыйлар шул. Бу мәсьәләдә «Суверенитет миңа нәрсә бирде?» дип, милеккә генә ябышып ятмаучы, рухи азыкны иң беренче урынга куйган, халкыбызның аңлы өлеше генә ярдәм итә ала, һәм бу уңайдан тагын да милли университет мәсьәләсенә килеп чыгабыз. Халык белән бер булып фикерләүче, эшләүче һәм яшәүче, һәм шул ук вакытта халыкны фикер ягыннан үстерүче белгечләрне бары тик милли университет кына, милли вузлар гына бирә ала. Бездә андый вузлар юк, шуңа күрә халыкның аңы да милли бергәлек төшенчәсе тирәсендә йөрми. Әзерлекле халкың булганда, әллә нинди конституционный суд-мәхкәмәләр «Суверенитет не действует» дигән карарлар чыгарса да, ул карар гына булып кала, чөнки һәрбер халыкның табигатьтән, бер Аллаһы биргән бәйсезлеккә хакы бар, өстәвенә бездәгечә халык референдумы белән дә ныгытылган булса. Аңлы халык аерым ситуацияләрдә генә үзен кузгатырга, митингларга, җыеннарга җыелырга тиеш түгел, ә үзен һәрвакыт мобилизациядә (билгеле, армия мобилизациясе күз алдында тотылмый) итеп хис итсә, Балтыйк буе илләрендәге халыклар кебек, һәр гаиләдә унар милли гәҗит-журнал алдыртып, аны укый, үзен-үзе хөрмәт итә икән (әлеге илләр Совет җөмһүриятләре булып торган заманнарында да шулай эшлиләр иде һәм милли университетларын да бирмәделәр, саклап калдылар), бу инде үзенә ышанган милләт, үзен яклый ала торган халык. Мондый халык бернинди алдауларга, провокацияләргә бирешми, бирелми, ә бу зур үсеш. Үзенә ышанган милләт исә, күп сөйләшми генә, милли университетын да ачып куя, башкасын да эшли. Басып алган як Шаляпинга һәйкәл куйдың дип тә исе китми, ә менә милли күрсәткечләр, әйтик, шул ук милли һәйкәлләр (беренче чиратта, Салих Сәйдәшевкә һәм иң күренеп торган урында!) күбрәк

булса, аның синең белән исәпләшми хәле юк. Башка халыклар: әрмәннәр, үзбәкләр, гөрҗиләр, әзәриләр, совет заманнарында да, шул миллилекләре аркасында, үзләре белән исәпләшергә мәҗбүр итәләр иде. Безгә дә, форсат бар чагында, өч-дүрт кенә урамның булса да исемен алыштырып, үзебезнең каһарманнарныкын куеп калсаң да ни отыш буласы иде...

Безнең буынга 1917 ел революциясе турында бик куп укырга һәм ишетергә туры килде. Ишетү һәм уку бер хәл икән. Чөнки мәгълүм бер халык Россиядә революция ясарга ярата инде дигән сүзгә дә кайвакыт ышанып куюлар булгандыр. Алай гына түгел ахрысы, бу илдә революцияләргә җирлек туып тора бугай. Менә хәзер дә күреп торабыз, алга таба да халыкның тормышы шулай барса, ай-һай,ниләр булмас...

Ә шулай да сүзебезне үзебез хакында, үзебезгә ышанып тәмамлыйсы килә. Иртәнге сәгатьтә радио үзебезнең гимнны уйнатып: «Татарстан Җөмһүрияте башкаласы Казан сөйли», – дип әйткәндә, шатлыктан йөрәге рәхәт кысылып куйган кеше «Миңа суверенитет нәрсә бирде?» дигән сорауны, бәлки, биреп тә тормас, андый сорауны бирсә дә, уңай җавапны үзе үк әйтер дә.

*2000*

**БАРЫБЕР ТҮГЕЛ**

Мин тирбәлә-тирбәлә дөя өстендә барам, ак комлы, ак кояшлы якты сахра... Колагыма шаулап кайнар җил килеп сарыла да ары китә, килеп сарыла да ары китә. Җирдә, күктә аваз йөри, аваз тарала, ниндидер ят та, шул ук вакытта бик тә якын, үз... Дөя дигәнем – йомшак кәнәфи селкенеп куя да мин айнып киткәндәй булам. Туган авылымда Корбан бәйрәме ашында кунакта утырам икән. Мин һәм башка кунаклар тыңлап утырган гали, якты, аһәңле көйле тавыш Газиз бабайның Коръән аятьләрен укуы.

...Мин моннан ике ел булып үткән матур күренешләрне кайта-кайта хәтергә төшереп утырам. Хәзер инде Газиз бабай да юк, дөнья куйды. Бездә генә түгел, бик күп башка авылларда да шәпләп өлгертелгән яңа мәчетләргә, мәдрәсәләргә гыйлемле, мәгърифәтле, дин эшенә чын күңеленнән бирелгән мулла-хәзрәтләр, мөгаллимнәр кайчан шаулап килеп керерләр дип көтәсе генә калды. Хәсис аракы эчәргә өйрәнүдән килеп чыккан күңелдәге иләс-миләслектән халкыбыз кайчан котылыр икән? Төп таянычыбыз булган татар авылы аракы эчүдән шактый түбәнгә тәгәрәде. Ә шәһәрне әйткән дә юк инде. Батты безнең шәһәр халкы төрле яктан: аракы сазлыгына, милләтсезлек, телсезлек пычрагына.

Казан урамнарыннан кайчакта безнең тележурналистлар репортаж оештыралар. Тапшыру татар телендә бара. Безнең татарлар урысча сөйли яисә бер сүз татарча, калганнары… Әкәмәт җөмләләр. Мондый хәлнең тагын кайда булуы мөмкин? Мондый репортажлар вакытында бәгырьне кисеп керә торган тагын бер авыр хәл күзгә ташлана. Титрда Фәйрүзә Федотова, Алсу Николаева дигән кебегрәк язулар пәйда була. Әйтик, 7 ноябрь тапшыруында бер өйдә яшәүче дүрт хатын-кыздан өчесенең фамилиясе урысныкы иде. Менә сиңа Казан, менә сиңа башкала! Ә без татар егете һәм кызларының кырык ике проценты урыска өйләнә, кияүгә чыга дип йөрибез. Чынлабрак тикшереп карасаң, җитмеш биш процент булса, нишләрсең? Мондый башкалада ничек татар гәҗит-журналлары таралсын ди инде? Шуннан соң без кабат-кабат авыл ягына борылып карыйбыз инде. Әмма авылга да, алда әйтеп кителгәнчә, талпан булып исереклек чире ябышкан. Ләкин мин барыбер безнең авылларга ышанам. Бу урында ышанычны шигъри юллар белән дә белдерәсе килә:

Ходаем биргән күчтәнәч
Газиз авылым минем.
Билгеле кыйблам булмаса,
Мин дә абыныр идем.

Нишләр иде бу татарың,
Кайларга терәр иңен,
Булмаса газиз авылы
Аркадаш, дусты, тиңе.

Авыллар татар халкына, ягъни үз-үзләренә ярдәмгә килер, исереклек чире белән үзләре үк көрәшә башлар дип ышанасы килә. Авылда да акча юк дип, татар матбугатын, татар китабын бөтенләй укымый башласак, кая барып чыгарбыз, җәмәгать? Бөтенләй юк дигәндә дә бер-ике исемдәге булса да матбугатка язылырга акча таба ала ул безнең халык. Әнә шул «яшел еланны» тотып буасың да язылаесың. Елан безне буып ятмасын.

Менә-менә Рамазан аена керергә күпме генә вакыт калды. Шул изге айда аракы бәдбәхетнең кулын кыскартасы, юлын кисәсе иде. Безнең могтәбәр авылларыбыз, районнарыбыз, аларның башлыклары үзләре тәкъдим белән чыксыннар иде. Сатылмасын бу изге айда безнең өчен кара дошман булган аракы дигән нәрсә. Авыллар шул эшне башласалар, бәлки, оятларына көч килеп, шәһәрләр дә күтәреп алыр

иде. Әгәр дә «Азатлык» яшьләр оешмасының шундый тәкъдим белән инде хөкүмәт оешмаларына чыкканын истә тотсак, бу нәкъ шулай булуы мөмкин.

Борынгы заманнардан бирле чын мөселман илләрендә эчкечелек проблемасы юк, дип кабатлап әйтми хәлем юк. Бу ишетеп кенә әйтү түгел, күргәнне әйтү. Пәйгамбәребез заманыннан бирле мөселман гарәбе – ком гарәбе чүлнең теләсә кайсы почмагына утырып, гасырлар буе армый-талмый Ходайдан яшеллек һәм су сораган. Чөнки кояш эссесе астында яшеллек һәм су булса, калганы барысы да була дигән сүз. Һәм Ходай Тәгалә аларга биргән. Гарәпләргә җир өстендә җәннәт кебек тормыш җир мае – нефть кыяфәтендә килгән. Алар хәзерге көндә шуның рәхәтен күрәләр, тормышларының кадерен беләләр. Мәңгелек Олуг көчне һич тә исләреннән чыгармыйлар. Шаулатып намаз укыйлар. Биш вакыт намаз сәгатьләрендә телевизор тапшырулары туктап тора, мәчетләр генә күрсәтелә. Шул ук вакытта алар архаик тормыш белән дә яшәмиләр, ультра заманча техниканың бөтен мөмкинлекләреннән файдаланып, бәхетле гомер сөрәләр.

Безгә дә бирелгән ул җир мае – нефть дигән әкияти байлык. Әмма аңа кирәк кадәр теләк тели белмәдек. Ходайга ялвармадык, күрәсең. Җиребездә булса да, нефтьнең нигъмәтләре безгә тимәде. Җир мае бармак араларыннан ком булып агып юкка чыкты, соңгы бөртекләренең акканын карап торабыз. Сәләтсез халыкмы соң без? Түгел бит. Шулай булгач, Рамазан аенда гына булса да аракы сатмау, эчмәү дигән мәсьәләне уңай хәл итик, кардәшләрем.

*1996*

## МИЛЛИ КИЕМ ҺӘМ...
## АВТОНОМИЯ КЫСАСЫ

«Казанда мода театры ачылган икән, кием күрсәтү тамашалары үткәрәләр икән, күрсәтүче кызлары чибәр икән», – дигән сүзләрне ишетергә, гәҗитләрдән укырга туры килде. Аннары күрергә дә бардым. Исеме – «Лик», «Азия» җыр фестиваленә барганнар, «Болгар» ансамбле белән чыгыш ясаганнар. Күрдек. Аларның үзләрен милли театр дип уйлауларын белдек. Шулаймы бу? Киемнәрен карагач, кием күрсәтүче кызларның тотышларын, йөзләрендәге әллә нинди бер төксе карашны күргәч, ай-һай, дисең, ышанмыйсың. Салкын караш, шактый сытык чырай белән кием күрсәтмәсләр татарлар. Татар булса, мөлаем булыр, сөйкемле, җылы карашлы булыр.

Шушы «Лик» театрын мактаучылар да бар. Бигрәк тә «Вечерняя Казань» гәҗите мактый аларны. Алар эше. Күрсәтүче кызларын, имеш, Парижга да алып китәчәкләр. Китсеннәр.

Тагын бер тамашаны Мәскәү Үзәк телевидениесендә күрсәттеләр. Төрле конкурслар оештыручы «Марина» исемле кооператив оешма бар икән. Шул «Марина» мода конкурсы үткәргән. Татарстаннан әлеге «Лик» театры катнашкан, финалга чыга алмаганнар. Аларны казах, үзбәк киемнәре традицияләре юнәлешендә эшләүчеләр диделәр. Татар атамасы әйтелмәде. Әкәмәт бит инде: Казаннан торып, Урта Азия модасын билгелиләр, кайгырталар булып чыга. Киемнәренә килгәндә исә, чынлап та, телевизордан күренгән кадәресе бер дә финалга үтәрлек түгел иде шул: карачкы кебек, капчык сыман күлмәк, чалбар-ыштан, чалма сыман нәрсәләр үтә дә караңгы төсләрдән сипләнгән. Шулайдыр шул, Казанда торып, Казахстан, Үзбәкстан өчен милли кием тегеп булмыйдыр. Теге яисә бу халыкның гореф-гадәтен, бүгенгесен шул халык арасында яшәп кенә белеп була икәнлеген әйтеп торуның кирәге юк ла! Казах, үзбәк, таҗик, кыргыз, төркмәннең аллы-гөлле кояш нурлары, тавис кошы каурыйлары, елның бөтен әйләнәсендә диярлек чалт зәңгәр күк йөзе төсен ятратканнарын белмиләр булыр «безнең» мода кайгыртучыларыбыз. Чынында, бу модачыларга урыс гореф-гадәтләренә бирелү, аның да әле Петербург-Ленинград соры тәэссоратына бирелү хас икән. Аларның тырышулары «а-ля восток» дәрәҗәсендә дә килеп чыкмаган иде. Берәр эш эшләр өчен объектка якынрак торуың хәерлерәктер. Бу очракта – Урта Азиягә.

Бу конкурста Казаннан әле тагын мехчылар – мех киемнәр тегүчеләр катнашканнар икән. Программаны алып баручылар, хәтта СССР күләмендә дә затлы итеп тегелгән мех әйберләрен, киемнәрен үзебезнең халыкка конкурсларда күрсәткәннәребез юк иде, диделәр. Бу беренче мәртәбә, диделәр. Ә бит затлы мех киемнәрнең бик күбесе Казанда тегелә! Шушы киемнәр бездән читкә китә. Кибетләрдә булганы исә күбесе ясалма мехтан. Чын мехтан тегелгәне дә карачкы сыман гына була иде. Хәзер, соңгы вакытларда, ниндидер кооперативлар чын мехтан теккәннәре матур түгел. Бәһаләре дә якын җибәрми, «тешли». (Җәяләр эчендә генә булса да, шуны әйтик: чит илләрдән, мәсәлән, Франциядән – Париждан очраклы рәвештә генә тун алып кайту бәхетенә ирешкән миллионнан бер кеше кайтып ярлыкларын әйбәтләбрәк караса, тунның Казанда тегелгәнен белеп, бот чаба икән – тун шулкадәр матур, ыспай икән дигән сүзләрне ишеткәләгәнебез бар иде.) Хәер, хәзер безнең кибетләрдә карачкы сыман туннар да юкка чыкты. Ә менә әлеге конкурстан Мәскәү телевизоры күрсәткән туннарга шаклар катарлык, искитәрлек – ул бизәлеш, ул чигешләр, ул мехны эшкәртү нечкәлекләре! Чит ил туннары бөтенләй бер якта торсын! Алар «Белка», «Мелита» фабрикаларында Казанда тегелгәннәр...

Халыктан яшереп, аны талауны ни дип атарга мөмкин икән соң? Казанның тирәсен генә дә әллә ничә җәнлек совхозы биләп алган. «Йомшак алтын» бездә күп, бик күп җитештерелә. Безнең халыкка гына хезмәт итми ул совхозлар. Валютага сатыла дисәләр дә, ул валютаның «в» хәрефе дә эләкми безгә. Исеме гәҗитләрдә күренгәләп ала торган «Кощак» совхозы директоры Н.Вәлиев тә бу юнәлештә шул алтын кебек кыйммәтле мехларыбызны саткан хакын безнең халык мәнфәгатенә җибәрә алмый. Валюта Үзәк һәм Россия дигән җирләрнең тирән базларында йотыла.

«Лик» театрына әйләнеп кайтсак, аларның хезмәткәрләренә, татар милли киеме үрнәкләрен, традициясен өйрәнсәгез, сез бер дә оттырмас идегез, ә һичшиксез, отар идегез, дияр идем мин. Музейларда ул үрнәкләр, Аллага шөкер, җитәрлек әле. Татар хатын-кызы кигән берсеннән-берсе матур, күпертмәле җилкә-җиңле, чачаклы-чуклы, әллә ничәмә-ничә бал итәкле (балитәк) ышлапырлы (әбием шулай дип әйтә иде), нечкә биллесе һәм иркен итеп тегелгән, төрле алтын-көмеш, гарыс һәм гади йон җеп, ефәк җеп белән чигелгән, тәңкәләр, энҗеләр тезгән, якасы иң гади утыртма якадан алып, челтәрле-челтәрле бөреп теккәннәре, итәге киңен һәм таррагын атарга мөмкин булыр иде. Күлмәкләренең йонын, асылын, ефәген, киндерен, озын-озынын, кыскарагын, нәкъ менә атаклы драматургыбыз Галиәсгар Камалның «Беренче театр» пьесасы персонажы Гафифәнең үз гардеробындагы күлмәкләрен санап китүен генә искә төшерик!

Бармы икән безнең милли кием модельерлары? «Мелита», «Белка» исемендә түгел, үзебезчә: «Гөлмәрьям», «Гөлниса», «Гандәлиф», «Гөлҗиһан», «Гүзәл», «Гөлйөзем» – болар барысы да бер «г» хәрефеннән башланган матур исемнәребезне файдалансак, килеп чыккан хыялдагы ширкәт исемнәре. Башка бик күп матур атамалар биреп, кайчан оешыр икән ул милли ширкәтләр? Чөнки һәртөрле башка сәнгать кебек үк, кием сәнгате дә бары тик милли генә була ала ич. Әле без әйтеп киткән «Марина» конкурсында да Белоруссия модельерлары җиңүче булды – бик милли, бик матур иде киемнәре. Ул якның төп чималы – җитен тукымадан бик матур милли чигешләр белән бизәлеп тегү, «мин белорус кызы күлмәге» дип кычкырып тора иде.

Безнең милли киемнең хәле дә, чынлабрак карасак, моңа чаклы безгә сөйрәлеп килгән нәрсәгә – дәүләтебез булмауга бәйле, билгеле. Бер мисал. Безнең бик матур чиккән читекләребез бар. Моңа чаклы аны «әбиләр читеге» диделәр, шалкан бәясенә саттылар. Ә чит илләрдән килгән туристларның Казаннан иң беренче алган әйберләре шушы читекләр булган икән. Читекләр һәм чүәкләр. Әле күптән түгел универмагта шул читекләрне бер урыс хатыны караштырып торганын күрдем. Ул болай дип сөйләп тә алды: «Мин үзем дә читек тегүдә байтак эшләдем. Хәзер менә пенсиядә. Арзан вакытта алып калмадым шул, уйламадым. И-и, шәп инде ул аякларга. Хәзер алып булмый инде – кыйммәт. Хәзер читкә дә китә бугай. Элек алай түгел иде. Милли товарлар читкә бик китәргә тиеш түгел, таралмасын, диләр иде». Менә шулай. Апай нәрсә беләдер, шуны әйтеп салды.

Ышанып әйтеп була: әгәр дә без союздаш җөмһүрият дип аталсак, әлеге «Лик» театры да әллә кайлардагы союздаш җөмһүриятләр киемнәрен тегәбез дип азапланып йөрмәс иде. Мәскәүгә баргач та, Казаннан килдек тә казах күлмәген тегәбез, дип, дөресен генә әйткәндә, кеше көлдермәсләр, без Казаннан, Татарстаннан килдек, татар милли киемнәре үрнәгендә эшлибез, татар киеме традицияләре гасырларга китә, дип, хурланмыйча сөйләрләр иде. Аңлашыла, автономия кысасы хәтта модага да китереп суга, аны да кысып куя.

*1991*

**БОЛГАР-ЙОРТ ЭРГӘСЕНДӘ**

Гадәттә, кеше туган ягына кайтып ял итеп килә, ә мин һәрдаим гамь җыеп киләм.

Хәер, гамь җыю Әлки ягына кайтырга дип билет алганда ук башлана: елның теләсә кайсы фасылында Базарлы Матакка кайтучы автобуска син теләгән вакытка урын булмый. Бездә шаяртып: «Базарлы Матакка кайтканчы, Рио-де-Жанейрога бару җиңелрәктер», – диләр.

Менә шулай. Автобус юк, автобусы булса, бензины юк. Бензин димәктән, инде ничә дистә еллар буе дәрья булып аккан Татарстан нефтеннән алынган бензин кем машиналарын йөртә икән соң?

Хуш, көч-хәл белән билет алып, автобуска утырып, туган якка – Әлкигә юл тотасың. Юлда таныш атамалар, авыллар исеме күзне иркәләр дип уйлыйсың, ләкин ни аяныч, алар берсе дә безнеңчә язылмаган: «Лаишевское», «Центральное», «Сокуры», «Каипский», «До Казани 41 км», «Слава труду», «Центральная усадьба»...

Безнең авылның исемен дә тукталышта «Чув-Брод» дип язып куйганнар. Авылдашлардан: «Моны кем шулай язган соң?» – дип сораган идем, «Кем белә инде аны, әрмәннәр төзегән иде, шулар язганнардыр», – диделәр.

Мөхәммәт Мәһдиевнең үзенең туган ягы – Арча төбәге турында ачынып язганын күп мәртәбәләр укыганым бар. Арча төбәге – Тукай ягы, дибез. Безнең яклар – изге Болгар яклары. Хәзер бу якка

халык күп агыла. Миңа калса, шундый юлда атамаларның татарча язылуы аерата мөһим. «Хәерле юл!», «Рәхим итегез!» кебек сүзләрне гарәп хәрефләре белән язып кую да әйбәт булыр иде.

Шулай сыкрана-сыкрана, ниһаять, авылга кайтып җиттем.

Элек безнең авыл зур иде, ике-өч меңләп кеше яши иде, хәзер кечерәеп калды, авылны нефть чыгару җирләре, КамАЗ, башкалар йотты. Тагын да Алабуга җиңел машиналар заводы, куркыныч әйбер – Татарстан атом станциясе төзелмәкче...

Авыл зарлана, ничә еллар буе совхоз директорыннан уңмаулары хакында сөйлиләр. Директорлар киләләр, байыйлар, китәләр... Илдә килеп туган хәлләр аркасында читтәге авылдашлар, авылда әйбәтрәк булса, кайтыр идек дип, хатлар язалар икән...

Туган авылым кешеләре өчен йөрәк әрнеде. Үзе иккән игеннән пешерелгән икмәк тә юк хәтта авыл кибетендә. Юк, юк инде дә, бернәрсә дә юк. Районнан унбиш чакрым ераклыкта гына газ торбасы үтә, билгеле, авылларга эләкми. Халык алай да безгә дә булмасмы әле дип ышаныч баглап тора... Әйе, җир мае – нефть, газ юан-юан торбалар буенча каядыр акты да акты. Соңгы бер-ике елда гына халык, йокыдан уянгандай, безгә дә булмасмы икән дип уйлана башлаган. Чынлап та, хәзер генә миллиардлаган тонналап сатылган нефть акчасының хет азрагы гына булса да республика мәнфәгатенә китсәче дип сыкрый алабыз. Элек сыкрау да рөхсәт ителми иде.

Авылда матди хәлләр шундый, ә бәлки рухи яклар әйбәтрәктер?

Китапханәгә кереп, як-якка күз салсаң, аптырап каласың. Татар авылы китапханәсендә бөтен эш урыс телендә генә алып барыла. Кайда туган тел? Кайда икетеллелек? Иманым камил, әгәр дә без республикабызда төп халык телен – татар телен дәүләт теле итә торган законны тиз көндә кабул итмәсәк, икетеллелек дигән нәрсә урыслар өчен генә түгел, без татарлар өчен дә буш сүз генә булып калачак, чөнки без икетеллелек дип сөйләнеп йөрүдән генә урыслар татар телендә сөйләшә башламады, киресенчә, татарлар да урысча гына сиптерәләр. Ә инде авыл җирендә дә бөтен эш кәгазьләренең урыс телендә генә алып барылуы бик зур хәвефне искәртеп тора.

Шулай эсселе-суыклы халәттә булып алгач, китапханәче Зөлфия Садыйкова белән китапларны карыйбыз. Татарстан китап нәшрияты чыгарган басмалар анда-санда гына күзгә чалына, ә инде соңгы бер-ике елда илле, йөз мең тираж белән чыга башлаган рәсемле балалар китаплары бөтенләй юк дисәң дә дөрес булыр. Шундый басмалардан китапханәдә бары бер генә китап бар, ул да булса, Мәхмүт Хәсәновның «Ут-малай» китабы. Зөлфия ханым, халык татар китапларын сорый, бигрәк тә яңа китапларны, ди. Ә алар юк. Авыл хуҗалыгына кагылышлы татар китаплары бөтенләй дә юк икән. «Сез китапны аз алдырасызмыни?» – дим. Зөлфия ханым исә: «Юк, безгә китап күп килә!» – дип, миңа яңа китаплар теркәлгән кенәгәне күрсәтә. 1989 елның беренче июненнән унбишенче июленә кадәр 107 китап килгән. Ләкин шуның бишесе генә татар телендә. Минемчә, Мәскәүгә яисә Ленинградка, йә Ленинград тирәсендәге авылга 102 татар китабы һәм 5 кенә урыс китабы озату турында беркемнең дә уена килмәстер.

Мин китапханәчегә сораулы караш ташлыйм. «Районнан бибколлектор шулай җибәрә, без үзебез заказ бирә алмыйбыз», – ди ул. Шулайдыр, хактыр аның сүзе. Казан шәһәрендәге мәктәп китапханәчеләре дә нәкъ шул рәвешле зарланышканнар иде. Әле күптән түгел генә. Менә нинди оешма икән ул бибколлектор.

Белдек, китапханәдәге хәлләр шулай икән. Бәлки, авылда китап сәүдәсе әйбәт куелгандыр? Авыл кибетендә китап сатылмый икән ләбаса! Элегрәк елларны хәлләр алай ук түгел иде ич. Сатыла иде китап. Хәзер менә авылда китап сатылмый дип кычкырып әйтү дә оят. Өйне әллә нинди җиһазлар белән җиһазласаң да, китап булмаган өй ятим кебек тоела миңа. Андый өйдә җылылык булмый, җан булмый. Ә безнең халык элек тә түрдән берничә киштәлек урынны, кагыйдә буларак, китапка биргән. Китаптан биздерелгән авыл халкы аны башка җирләрдән эзләп мәшәкатьләнмәс шул. Заманында безнең бабайлар китапны, авылдан авылга йөреп, кычкырып укып күрсәтеп, көйләп-җырлап, мактап-мактап, һәркемгә җитешеп сата торган булганнар. Район үзәгендәге китап кибетенә кергәч, тагын бер кат ис китте – китап сатучы булып анда безнең як халкының мәнфәгатьләрен аңламаганы әллә каян кычкырып күренеп торган кеше эшли икән. Сатып алучыларга ул шулкадәр дә илтифатсыз, кибеттән кире чыгып китүең хәерле тоела.

Ярый, тагын да бер якка – мәдәният дигән тарафка борылып карыйк әле. Авылда мәдәният-агарту эшләрен алып баручы клуб та була бит әле. Бинасын зуррак иттереп салсалар, культура сарае, культура йорты дип тә җибәрәләр. Бездә дә бар андый бина, тик ишегенә йозак эленгән. Хәер, кино-мазар булса, әллә нигә бер концерт бригадасы килсә, ачыла да әле ул, диләр. Шуның белән вәссәлам.

Бу күренеш әллә бөтен Әлки районына хас инде? Ник дигәндә, халык иҗатына багышланган фестиваль-конкурсларда райондашларның тавышлары бик тонык ишетелә йә бөтенләй дә ишетелми.

Авылда мәгариф учагы – мәктәп тә бар. Мәктәп хәлләрен дә белергә туры килде. Мәктәптә урыс телендә укыталар. Исең китсә дә, китмәсә дә – шулай.

Мәктәп директоры Ринат Фатыйхов белән сөйләшәбез. Мин аны янәдән татарча укытырга күчәргә өндим. Заманалар үзгәрде, алга таба тагын да зуррак үзгәрешләр булыр әле, дим. Директор татарча

укытуга күчәргә риза да кебек, әмма тел төбендә нindидер әйтеп бетермәгән шиге бар сыман, әллә «өстән» әмер көтә, әллә ата-аналар белән уртак тел таба алырына шикләнә.

Алгебра, геометрия, урыс теле һәм башка фәннәр ата-аналардан сорап тормыйча гына укытыла. Ни хикмәттер, татар телен өйрәнү яисә татар телендә укып белем алу дигәндә, ата-аналар дип сөйләнә башлыйлар.

Әйе, Совет хакимияте елларында ата-аналар ана телендә – татар телендә белем алу культуралылык билгесе икәнлеген аңламас дәрәҗәдә түбән төшерелгәннәр иде инде. Бу хатаны төзәтү өчен дәүләти гамәлләр таләп ителә, вәгазь генә аз.

Авылда халык аз. Шуңа балалар да азая. Карап карасаң, шәһәрдә дә безнең халык азчылык. Безнең милләттәшләр читтә. Моннан бер нәтиҗә килеп чыга: татарның теле бөтенләй бетмәсен, мәдәнияте саклансын дисәк, яңа төзелешләргә нәкъ менә читләрдә яшәүче милләттәшләребезне оешкан төстә кайтару сорала. Фирганә вакыйгаларыннан соң кайтырга теләүчеләр аз булмастыр.

Туган якларга – Болгар якларына кайткач, борынгы бабаларыбызның изге нигезен зиярәт кылмый мөмкин түгел. Туганнар белән җыелышып киттек. Шәһре Болгар биләмәләре туристларны, сәҗдә кылучыларны кабул итәрлек итеп бераз иплэнгән. Килсеннәр, карасыннар. Су юлы беләнме, автобус беләнме – рәхим ит. Казан – Базарлы Матак юлына, егерме елларга сузылса да, ниһаять, асфальт салынып беткән, соң булса да, уң булсын. Ә шәһре Болгарга Базарлы Матактан соң ерак калмый инде. Шушы юл белән хәзерге район үзәге Куйбышев шәһәренә барып керәсең. Болгарга дип баргач, нишләп соң әле бу Куйбышев дип аптырыйсың. Болгар шәһәре, Болгар районы дип кенә әйтәсе кала. Культура дәрәҗәсен дә күрсәтеп торыр иде борынгы шәһәр, тарихи дөреслек тә кайтарылыр иде.

Әй ул безнең әрәмгә вәйран киткән шөһрәтле, данлы исемнәребез!.. Менә безнең үзебезнең тел җимереп әйтеп йөргән Базарлы Матагыбыз – «мә, тыгын» булып яңгырый бит. Аның матур исеме Кала Базар булган. Петр I безнең якларга чуашларны көчләп күчереп утырткач, ул Базарлы Матакка әйләнгән, ягъни мәсәлән, Базарлы базар.

...Куйбышевта безнең татарча эндәшүебезгә өч кешенең берсе генә татарча җавап бирде. Әйе, биредә урыслар яши, аларны урыс патшалары күпләп-күпләп тә, көчләп-көчләп тә күчереп утырткан, билгеле, Болгарны юк иткәч, Казанны алгач...

Болгар хәрабәләре, Куйбышевка килеп керүгә, уң якта (автобус, машина белән килгәндә) 300–400 метр арада гына урнашкан. Ашыга-ашыга шул якка таба борылабыз, җәй көне бит, кинәт кенә кара-кучкылланып болыт чыкты, көчле җил исте, ялт-йолт яшен яшьнәде, яңгыр ява башлады. Кичергән тәэсирләрдән күздән үзеннән-үзе яшь тама башлаган иде инде, яңгыр явуы исә Табигатьнең, и адәм баласы, елама, синең өчен үзем елыйм, дип әйтүеме яисә икәү бергә еларга теләк белдерүеме? Ходай белә.

Яңгыр астында Иделнең биек яры кырыена килдек, ярдан төшеп, йоланы үтәп, мәңгелек елганың суын кулларыбызга алдык, биткә сиптек. Изге бабаларыбызның кабер ташларыннан салынган чиркәүнең тәресенә яшен чатыр-чотыр бәрә, ә нигездә яткан ташлардагы гарәп язулы чигешләрне эре яңгыр тамчылары елый-елый укыйлар...

«Идел буе Болгар дәүләтендә ислам дине кабул ителүенең 1100 еллыгын бәйрәм иткән көннәрдә нишләп шәһре Болгарда мәчет юк, нишләп салмыйлар?» дигән сүзләрне халык авызыннан еш ишетергә туры килде. Әйе, моңа ихтыяҗ зур. Болгарга килүчеләр отыры ишәя бара, тик әлегә аларны шәрә таш манара гына каршы ала. Безгә калса, киләчәктә шәһре Болгарны дөньядагы бөтен татарларның килеп-китеп йөри торган изге урыны – Мәккәсе итәргә мөмкин булыр иде. Кайбер милләтпәрвәрләребезнең «Көмеш дага» исемендә зиярәт кылучылар маршруты булдыру хыяллары да бар. Аннан «туризм» дигән сүз дә бар бит әле дөньяда...

Мондый эшләргә керешер өчен беренче чиратта көчләп ябылган Куйбышев (Болгар) татар педагогия училищесын торгызырга кирәк. Педучилище белән беррәттән архитектурада көнчыгыш традицияләрен дәвам иттерердәй төзелеш-архитектура техникумын ачу да, эх, шәп булыр иде.

Халыкта исә үткән белән кызыксыну уяна, арта бара. Авыл кешеләренең «Казан утлары»нда, телевидениедә дә «гарәпчә язарга өйрәтү дәресләре дәвам итәрме, гарәп әлифбасын өйрәтүче дәреслекләр чыгармы» дип сорашулары халыкның үткәнен беләсе килүне, борынгы ядкарьләребезне үз кулы белән алып, тотып укыйсы килүне күрсәтеп тора.

Авыл җирендә дә әхлакның бозылуына, исереклек, урлашу таралуга аптыраганнар. Кешене рәнҗетмәскә, алдашмаска, ялкау булмаска өндәгән, өлкәннәргә, ата-анага мәрхәмәт хисләрен тәрбия-ләгән, аракы эчү, тәмәке тарту һәм башка бик күп тискәре күренешләргә каршы көрәшкән ислам дине тәгълиматын искә төшерә башлаган халык. Авылда мәчет ачу мәсьәләсе көн тәртибенә килеп баскан. Моңа кадәр картлар кулларыннан килгән эшне үтәгәннәр. Моңа мисал итеп авыл зиратының хәзерге торышын күрсәтү дә җитә. Зират коймалары төзек, капкалары ябулы, йөзьяшәр агачлар, мәңгелегеңне онытма дигәндәй, серле шаулап утыралар. Ә яңа гына утыртылган сәрби куаклары исә, менә тагын бер бахыр мәңгелеккә китте, дип пышылдыйлар сыман...

Ә мин шушы җирдә яшәп, мәңгелеккә киткән туганнарым, газиз әнкәем, әткәем, кан кардәшләрем турында уйлыйм. Шушында яшәүче авылдашларым, милләттәшләрем турында уйлыйм. Читләрдәге бәхеткә ымсынып чыгып киткән якташларым турында уйлыйм...

*1990*

## МИЛЛИ ТҮБӘТӘЙ...
## ДУҢГЫЗ ФЕРМАСЫ... ҺӘМ...

«Казан утлары» журналы тышлыгыннан күренекле язучыбыз Нурихан Фәттах карап тора. Ул башына кара, түгәрәк татар түбәтәе кигән. Менә шушы матур, җыйнак, гади баш киеме безнең халыкның тышкы милли билгеләренең берсе, бәлки, шактый әһәмиятлесе булып торадыр да әле. Нурихан абый Аурупа костюмын кигән, ләкин шуңа карамастан нәкъ менә түбәтәй аның татар әдибе икәнлеген күрсәтеп тора.

Атаклы милләттәшләребез Заһир Бигиев, Дәрдеменд, Сәгыйть Рәмиев, Камил Мотыйгый, Габдулла Тукай, Галиәсгар Камал һәм халкыбызның башка бик күп күренекле, газиз кешеләре башларына түгәрәк татар түбәтәе кигәннәрен рәсемнәрдә, фотоларда күрәбез. Үзен татар дип хисаплаган кеше башына шундый түгәрәк түбәтәй кигән. Шушы баш киеме татарларны башка халыклар арасында аерымлап торган. Бу баш киеме белән татар кешесе хәтта үзенең иң якын туганы булган башка төрки халыклардан да аерылып торган. Ләкин бу аерылып тору аралашмауны аңлатмаган, билгеле.

...Сталинның кара заманнарында, торгынлык елларында түгәрәк түбәтәебезне халык күзе алдында тотучылар Татарстанның Габдулла Тукай исемендәге филармониясенең Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле булды. Иң авыр елларда да мәчет юлын онытмаган картларыбыз башларына татар түбәтәе киеп йөрделәр.

Менә хәзер башкачарак, үзгәрәк, кызыклырак заманнар – демократиянең зур капкалары ук булмаса да, җилкапкалары, төннекләре... ачыла башлады. Халкыбыз үзенең милли рухи дөньясына игътибарын ныграк юнәлтә, шуның белән бергә милли форма-шәкелгә дә әһәмият бирә башлады. Урамда түбәтәй киеп йөрүче ир-атларыбыз күзгә ешрак чалына; шунысы да күңелле, милли баш киемен яшьләребез дә кия башлады. Әмма... Чү! Урамда күбрәк дүрткырлы түбәтәй кигән кешеләр очрый түгелме? Шулай шул.

Ә халык зарлана, ризасызлык белдерә, татар түбәтәен теләгән җирдән, теләгән вакытта, теләгән бәһагә сатып алып булмавын әйтә. «Нишләп алай соң?» дигән сорауны ачыкларга тырышып, «Бүләкләр» кибетенең директорына керәбез. Директор безнең милләт кешесе түгел. «Хәзер юк шул әле татар түбәтәе, ә булгалый», – ди. «Кырык, илле, алтмыш сумгамы?» дигәч, «Арзанлысын тегәргә бәрхет юк, хәтфә юк», – дип җавап бирә. Әле шунысы да бар, татар түбәтәен аерым кешеләр өй шартларында гына тегәләр икән, фабрика-цехлар андый «вак-төяк» эшләр белән шөгыльләнмиләр икән. «Бүләкләр» кибетеннән чыкканда, тагын бер мәртәбә киштәләргә күз салабыз. Анда бер сум илле тиенлек һәм ике сум ун тиенлек үзбәк түбәтәйләре тезелеп тора, ә туган башкалабызда үзебезнең милли түбәтәй юк. Тып итеп аяк типсәң дә – юк, бу нинди эш дип гауга чыгарсаң да – юк. Дүрткырлы үзбәк түбәтәен Әндиҗан шәһәрендә фабрикада теккәннәр. Аңа каршы бер сүзебез юк, ул – безнең тугандаш халыкның милли баш киеме. Ә менә нишләп безнекеләр юк? Хәер, аларны бөтенләй юк дип әйтеп тә булмыйдыр, хәтта кайвакыт кибет киштәләрендә алынмыйчарак яткан чаклары була. Ни өчен соң алай дигәндә, аларның бәһаләре... тешли, алда әйтеп кителгәнчә, кырык, илле, алтмыш, җитмеш, хәтта сиксән (!) сумга хәтле торалар. Ә баш киеме, бигрәк тә түбәтәй, чәчкә сыландырып, басылып киелә. Аңлашыла ки, алай кигәндә чәч аны бик тиз майлата, керләндерә, димәк, түбәтәйне еш алыштырырга, яңасын алырга мәҗбүр итә, ә илле-алтмыш сумга бер-ике ай саен түбәтәй алыштырып булмый, ай-һай, кыйммәткә төшәр ул. Без инде үзбәк түбәтәйләре кебек бер сумлык, ике сумлык түбәтәй таләп тә итмибез, без үзебез бай булмасак та, түбәтәйнең биш сумлыгын, һич югында җиде сумлыгын алырга да разый булыр идек, ә инде илле-алтмыш сумлыгын рәешкә кияргә дип берне алып куярга була... Илле-алтмыш сум дигәч, тагын бер уйлап куясың: «Ә нигә кирәк соң чылтыр-чылтыр алюмин фольгасыннан кисеп ясалган түгәрәкчекләр белән түбәтәй бизәү?» Кызлар калфагы түгел ич ул. Калфакны да мишура белән түгел, ә энҗе белән бизәгәннәр. Түбәтәй елтыр-мылтырсыз да ир-ат башында булуы белән күркәм.

Республикада милли түбәтәебезне сату мәсьәләсенең тәмам төбенә төшәргә омтылып, «Росглавгалантерея» базасына юнәләбез. Аның директоры урынында түгел, ә менә урынбасары бүлмәсендә иде, өстәвенә үзебезнең татар кешесе – Шәрәфетдинова Ләлә Әсгать кызы. Әмма ул да түбәтәй мәсьәләсендә «Бүләкләр» кибете директоры сүзләренә өстәп әллә ни әйтә алмады. «Бәрхет юк, хәтфә юк». Гомумән, тауарның базада аз булуын, складларның бушлыгын, элекке белән чагыштырганда сату әйбер-сәйберсенең биш-алты мәртәбә азрак кергәнлеген әйтте. База Мәрҗәни

исемендәге мәчеттән ерак түгел, кайтышлый мәчет алдына тукталабыз. Анда түбәтәйләр кулдан сатыла, әмма кыйммәт – илле сум! Арзанлысы юк, беләбез бит инде, бәрхет юк! Ә менә Ташаяк ярминкәсе вакытында булган! Җаның ни тели, шул булган! Торгызасы иде шул Ташаяк ярминкәсен! Бәлки, шуның аша (кешеләрчә сәүдә мөнәсәбәтләре урнашса) муллыкка да барып чыгар идек. Шәһәребезнең яңа сайланган баш архитекторы ни уйлый икән?.. Ул уйламаса, халык уйласын иде...

Безнең көннәрдә юк дигән сүз әллә мода булып киттеме? Шикәр – юк, бензин – юк, тукыма – юк, төзү материаллары – юк, әгәр «юк» нәрсәләрне саный китсәң, ничә йөз метр кәгазь язып төшәр идек тә... «кәгазь юк» дип кисәтерләр...

Халык хәзер Кама Аланында төзелә торган атом электр станциясе турында шау килә. Нигә соң ул безгә? Татарстан нефть-газ өстендә утыра түгелме соң? Аның чыга торган җире дә нәкъ менә шул станциядән ерак булмаган Әлмәттә ләбаса! Менә бит әкәмәт! Янында, туган җиреңдә чыгарыла торган энергия чыганагы читкә китеп барсын да, ә безгә ягулык итеп халыкны куркуга сала торган атомны тәкъдим итәләр. Үз малыңа үзең хуҗа булмау дип атала бу хәл, ягъни «Үгез хуҗасына ит юк» шушы буладыр инде.

Мәскәүләргә татар халкының мәнфәгате әллә бар, әллә юк. Шулай булмаганда, Мәскәүгә буйсынган фабрикалар кием-салым теккәндә шунда беррәттән татар халкының милли баш киеме булган түбәтәйгә дә бер генә булса да конвейерда урын табарлар иде...

Милли традицияләрне күрмәмешкә, белмәмешкә салынулары ведомстволарның һәртөрле эшчәнлегендә ярылып ята. Бер генә мисал. Менә инде ничә дистә еллар татар авыллары тирәсендә революциягә кадәр гомер булмаган сасы ис – дуңгыз фермасы исе аңкый. Асрамаган безнең халык ул хайванны. Дин кушмаган, традиция шулай булган. Татар халкы, үзенә җитәрлек итеп (һәм әле сатарлык та), ат, сыер, сарык, каз, үрдәк, тавык асраган. Нигә кирәк ул бүгенге көндә безнең унсигез-егерме яшьлек кызларыбызны, яшь хатыннарыбызны мыркылдаган дуңгыз янында йөртү? Алардан дуңгыз исе килеп торсын дипме? Бәлки, уйдырма план өчен? Ә бит бармак илле калынлыктагы дуңгыз мае кисәген урыс кешесе үзе дә ашханәләрдә тәлинкәсенең читенә шудырып калдыра, ашамый. Ә гомумән алганда исә Татарстан авылларында ит йөкләмәләрен ничек кенә арттырып үтәсәләр дә, монда – безнең шәһәрләрдә ит юк. Бу бит авыл хезмәтчәннәрен, йомшак кына итеп әйткәндә, уңайсыз хәлгә кую булып чыга. Алар бу хәлгә карап-карап торырлар да: « Кая китә ул без җибәргән ит?» – дип аптыраулары да ихтимал... Яисә алыйк сөт-катыкны. Авыл кешесе каймак кебек сөт савып озата, ә шәһәр кибетләрендә шешәләрдә су кебек сөт, табага салсаң, сары су һәм эремчек хасил була торган сукыр бер «күзсез» каймак. Ә менә Мәскәү, Ленинградларда куе сөт, чын каймак булды... Бу уңайдан күзгә яшьләр китерә торган тагын бер нәрсә турында әйтеп китәсе килә. Сүз авыл халкы турында. Авыл кешесе гомер буе кырда, фермада эшләп пенсия яшенә җитте ди. Менә шушы вакытта аның алдына «нишләргә?» дигән коточкыч сорау килеп баса. Нишләргә? Картаеп, хәлдән тайгач, сыер асрап булмый. Терлеккә кышкы азык әзерләү безнең шартларда көчендә, куәтендә булган кеше өчен дә әле ул бер каза. Ә авыл кибетләрендә хәтта пенсионерларга дип тә сөт-катык, май, ит сатылмый, хәтта ипи сатуның да очы очка ялганмый. Шулай итеп, пенсия яшенә җиткән кешене тыныч картлык көтми, ничек итеп шәһәргә күчәсе иде дигән уй бораулый. (Билгеле, үлсәм үләм, нигеземне ташламыйм дип уйлаучы да шул ук татар пенсионеры.) Кырып-себереп дәүләткә озаткан байлыктан авыл пенсионерына өлеш юк, ә авыл тарала, нигезләр юкка чыга, рухи гына түгел, матди дә зыян килә...

Ә шулай да кызыклы заманда яшибез. Хәлләр ай саен гына түгел, көн саен дип әйтерлек үзгәрә. Күп халыклар, милләтләр үзләренең традицияләренең чишмә башына әйләнеп кайталар, безнең халыкның да андый омтылышы бар. Әмма дәрт бар да, дәрман юк дип әйтергә мәҗбүрбез. Рухи омтылышларыбызны тормышка ашыру өчен җирлегебез аз. Бер генә мисал. Демократия заманы дип, шәһәрләребездә элек күз күрмәгән, колак ишетмәгән афишалар барлыкка килә башлады. Аларның кайсылары эротик-фантазия концертына чакыра, икенчеләре эротик фотокүргәзмәгә, өченче бер төрлеләре көчләү-утерүгә өйрәткән фильмнар карарга өндиләр. Һәртөрле «фантазияләр» кайбер халыкларның әхлак-этик кагыйдәләренә сыядыр, бәлки. Ә кайберәүләрнең андый «культураны» якын да китерәсе килми. Чынлап та, нишләп андый нәрсәләр безнең милли республикада чәчәк атарга тиеш әле? Җөмһүриятебезнең эчендә бу мәсьәләләрне хәл итеп буладыр ич инде?! Бусына да без хуҗа түгелме әллә?.. Шуңа охшаш «фантазияләр» телевидениене дә баса башлады. Бусы инде тагын да куркынычрак. Концертларга һәркем бармаска мөмкин, ә телевизор өйдә ич! Төймәсен генә басасы!.. Үзәк телевидениедә бөтенләй дә безнең традицияләрне уйлап тормыйлар инде... Хәзер урысча сөйләшкән халыклардан «независимое радио, независимое телевидение» дигән сүзләрне ишетергә туры килә. Аларның бу теләкләре дә безгә туры килмәскә мөмкин, татарга үзенчә, милли, бәйсез телевидение, радио кирәк. Безгә Польшаның Ломжа воеводасы һәм Германиянең Брауншвейг шәһәре белән дуслыкка караганда (аларны да инкарь итмичә), бигрәк тә Урта Азия һәм Кавказ төрки-мөселман җөмһүриятләре белән аралашу кирәк, Төркия һәм башка мөселман илләре белән аралашу нәтиҗәлерәк булыр иде. Рухи яктан якынрак халыклар белән аралашуның кадерлерәк икәнлеген икейөзлеләнмичә генә таныйк. Ахыр килеп, быел Салих Сәйдәшевнең 90 еллык юбилее елында Татарстанда төрки

халыкларның музыка фестивален үткәрү Ходай үзе кушкан бер эш булыр иде. Казанда үткәрелгән урыс халкы җыры фестивален Салих Сәйдәшев юбилеена багышланды дип әйтеп булмый бит инде, аның үз урыны.

Сүзебезнең ахырында тагын бер теләк белдерәсе килә. Соңгы бер-ике елда безнең дин әһелләребез бик тә игелекле эшләр башкардылар. Болгар дәүләтендә ислам дине кабул ителүнең 1100 еллык бәйрәмен шаулатып үткәрү дисеңме, никадәр яңа мәчетләр ачу дисеңме, халыкны изге дин юлына күндерүдә башка бик күп хезмәтләр дисеңме, яисә телевидение буенча чыгыш-вәгазьләр дисеңме, яисә тагын әле быел гына республиканың йөзләгән диярлек мөселманнарының хаҗ кылу сәяхәтен уңышлы үтәп чыгу дисеңме – эшләр күп. Шулай да дин әһелләре гәҗит-журналларда да үз фикерләрен, тәкъдимнәрен әйтеп, тагын да ешрак чыгышлар ясасалар, халкыбызның дини белемнәре арта төшәр иде. Хәзрәтләребезгә яхшы таныш булса да, хәзерге вакытта авылларыбызда яңа ачылган мәчетләребездә указлы муллаларның җитешмәвен тагын да бер мәртәбә әйтеп китми мөмкин түгел. Кайдадыр Себердә, Красноярск якларында, һәм, гомумән, киң Себердә кардәшләребез дини йола тәртибен белүче кеше дә булмаганлыктан интегүләре хакында экспедициядә йөреп кайткан галимнәребез, студентларыбыз әле генә кайтып сөйләделәр. Хәер, бу проблемаларның барысының да татар милли түбәтәен башка киемнәр белән беррәттән фабрикада тегү мәсьәләсенә килеп бәйләнгәнлеген тоеп, белеп торабыз. Үз иләндә үз көнең дә булсын иде...

*1990*

## КҮҢЕЛ РӘНҖҮЛӘРЕ БЕТСЕН

Алдымда – «Татарстан яшьләре» газетасының 19 октябрь саны. Беренче биттә Сталинның коточкыч үлем машинасының тимер кулы белән җәһәннәмгә ташланган һәм шунда кеше ышанмаслык шартларда да дөреслекнең җиңәчәгенә чын күңелдән ышанган, танылган язучыбыз Ибраһим ага Сәлаховның «Йөзебезгә кара якмагыз» дигән ачык хаты. Ул «Казан феномены» дигән нәрсәкәй турында Бөтенсоюз телевидениесеннән күрсәтүләре, үзәк матбугатта язулары хакында сөйли. Шул тапшыруларның резонансы турында Кырымнан Фәнзилә Шәвәлиева мондый хат язган: «Безгә «Сез, татарлар, нинди явызлар икән!» – дип кенә җибәрәләр монда». Шулай йөзгә бәреп әйтәләр икән.

Ә бит бу коточкыч хәл! Сталин тарафыннан явыз рәвештә туган җиреннән – Кырымнан куылган кырым татарларын хәзер ата-бабалары җиренә кире кайтару турында сүз-эш бара. Кара эт бәласе ак этә тияргә мөмкин бит! Кырым татарларына: «Сез барыгыз да бертөсле, әнә казан татарлары бөтен ил буйлап кеше кыйнап, талап, сугышып йөриләр», – дип әйтмәсләренә кем гарантия бирә ала?

Ибраһим абыйның йөрәк әрнүе белән язылган сүзләрен укыйм да мине чарасызлык хисе баса: кем укыр икән Казанда бу мәкаләне? Группировкаларда йөрүче малайларның әти-әниләре (үзләрен әйтмим дә инде) укырмы икән? Ни өчен дигәндә, моңа бик зур шигем бар. Күпме генә алалар бездә татар матбугатын, татар басмасын? 400 меңнән артык татар халкы яшәгән башкалабызда һич югы 80-100 меңләп милли газета-журналларны (һәрбер гәҗитне, һәрбер журналны дибез, бөтенесен бергә кушып түгел) алдыручы да булмагач, без кем? Өй тутырып, рәхәтләндереп кайсыгыз «Социалистик Татарстан», «Татарстан яшьләре», «Яшь ленинчы» газеталарын, «Казан утлары», «Азат хатын», «Идел», «Ялкын» журналларын алдыра? Берән-сәрән, меңгә бер бит!..

Казан шәһәрендә «Татарстан яшьләре»н укучы кешеләргә мөрәҗәгать итәм: язучы Ибраһим абый Сәлахов язган йөрәк сүзләрен, газетаның 125 нче санын киштәгездән янәдән табып алып, безнең гәҗитне укымый торган кешеләргә, бигрәк тә борчулы уллары-кызлары булган ата-аналарга яисә яшьләрнең үзләренә укыгыз. Аңламасалар, тәрҗемә итегез! Ибраһим Сәлахов Сталин терроры котырганчы, Октябрь революциясенең беренче унъеллыгында, табигый, чын интеллигент булып формалашып, Колыма лагерьларында могҗизаи гына исән калган безнең намус авазыбыз ул! Аның тавышын ишетү безнең яшьләребезнең һәрберсенә фарыз.

Мин байтак еллар урыс мәктәбендә татар балаларына татар теле укыткан кеше. Ул чорда төркемнәр әле юк дәрәҗәсендә аз иде. Татар теле дәресләренә мөнәсәбәт төрлечә булды. Әмма бер нәрсә ап-ачык: татар теле дәресенә яратып, үз итеп, туган теле икәнлеген аңлап, теләп йөргән балалар тәрбияле, ата-анасы миһербанлы булган гаиләләрдән иде. Мин ул балаларның һәммәсен бүген дә беләм. Аларның берсе генә дә төркемнәргә кушылып китмәде. Торгынлык чорының иң шыксыз елларында да, җәй көне хезмәт һәм ял лагерена баргач, 8–9 сыйныф укучыларының кайберләренең (малайларның!) палатка эчендәге урын-җирләре янында, баш очында Габдулла Тукай сурәтен элеп куйганнарын үзем күрдем!

Ата-аналар, сезгә тагын да сүзем бар. Юлдан язарга җиткән малай-кызларыгызны үзегезгә якынайтырга теләсәгез, бөтен изге гамәлләрегезне дә алар белән бергә кылыгыз. Югыйсә нәрсә килеп чыга соң? Сез ял көннәрегездә, кәрзин-чиләкләрегезне, капчык-төенчекләрегезне күтәреп-асып, яшелчә-җимеш бакчаларыгызга хезмәткә китеп барасыз, ә сезнең озын буйлы егет-кызларыгыз урамда

трай тибәргә шәһәрдә калалар. Хәер, аларның буйга үсеп җитүен көтеп торсаң, соң булачагын үзегез дә аңлыйсыздыр. Тәрбияне бала тууга башлау мәйле...

Җәмәгатьчелек җыелган урыннарда, митингларда безнең япь-яшь егетләребез, кызларыбыз булмыйлар. Нишләп булсыннар? Чөнки анда сез юк... Бездә җыеннарга 400–500 кеше йөри, аларның да күпчелеге пенсионерлар. Пенсионерларга рәхмәт, алар оныклары язмышларына борчылалар. Ә бит картлар мәңге яшәмәс. Ашык-пошык төзелгән атом станциясе бүген шартлыймы, иртәгәме дип куркып яшәргә, сез, яшьләр, калачаксыз. Ташлагыз ул кулларыгызга тоткан тимер-томырны, арматураларны, тимер шарларны! Килегез, йөрегез тыныч җыеннарга! Бөтен нәрсәне сөйләшеп хәл итик! «Безгә киенергә кирәк, безгә тегесе, бусы кирәк» дигән заман шаукымына бирелүегез дә кими төшәр. Әгәр эчең-җаның буш булса, алтын-көмеш, ефәк-бәрхеткә төренсәң дә, карачкыга смокинг – Европаның әйбәт кичке костюмын кигезгән кебек кенә булыр. Башка җирләрдә, башка илләрдә әнә ничек киенәләр, әнә нәрсәләр ашыйлар дип нәфес арттыру да бик үк дөрес булмастыр. Рухыбызны-күңелебезне сәламәтләндерми торып, без рәтле тормышка ирешә алмаячакбыз.

Туганнар! Гасырдан гасырга, буыннан буынга хезмәт сөюче дигән матур даны чыккан татар халкының балалары яман сүзләр белән ил теленә керүдән туктасын! Шәхес культы елларындагы кыямәт-мәхшәрне үтеп чыккан мөхтәрәм язучыбыз Ибраһим ага Сәлахов һәм башка милләттәшләребезнең күңел рәнҗүләре туктасын! Аларның моңа тулы хакы бар!

*1989*

## НИ ӘЙТСӘҢ ДӘ...

Агачлар шаулап яфрак яра... Агачлар гөрләтеп яфрак коя... дип тә әйтәбез. Аларның бу гамәлләре төрле елларда төрлечәрәк вакытка туры килә. Кайсы елларны без адәм балалары, иртәрәк түгелме, дибез яисә, быел агачлар яфрак коярга соңгарак калдылар, дип тә җибәрәбез әле. Бу кешеләр күзлегеннән шулай. Ә табигатьтә барысы да үлчәнгән. Табигать икътисадының һәр көне бөтен бер табигый әйләнеш – елны эченә алып, үзенең эчке кампитрына без чамалый алырлык кечкенә берәмлек – микронга хәтле исәпләп-хисаплап салынган. Заводта энә очы хәтле генә бәләкәй деталь ясаучыларның остарып китә алучылары микронны бармак очлары белән тоярга өйрәнәләр икән. Чынында исә табигатьнең иң кечкенә һәм иң зур үлчәвен без күз алдына да китерә алмыйбыздыр...

Әйе, табигатьтә барысы да үлчәнгән. Агачларда – яңа яфраклар, җимешләр, үсемлекләрдә яңа уңышлар барлыкка килсен өчен, табигать «икътисади план» корып яшәгәнен – тулысы белән аңлы интуициягә ия булуын кеше хәзер таный да бугай инде. Ә хайваннар, җәнлекләр, кошлар дөньясының аңлы интуиция белән яшәгәнен (искиткеч югары дәрәҗәдә!) адәм баласы белә дә белә инде. Хайваннар дөньясының үзләре өчен бөтен бер төгәл программалы кампитрга ия булуын шулай ук танырга туры килә. Хәзерге заманда инде кеше дә үзенең яшәеш кануннарын күренеп торган – җисми кампитрга программалаштырып салырга тырыша башлады. Үсемлекләр белән хайваннар дөньясының программасы табигый рәвештә төзелсә, кеше төзегән программалар тигезсез, сикәлтәле икәнлекләре күренеп тора, пропорцияләр бозыла; табигать кануннарын исәпкә алмау гадәте дә бар кешедә. Шул ук вакытта адәм дигәнебез табигатьтән башка бер адым да атлый алмый.

Табигатьтән акыллы рәвештә файдаланган халыклар, илләр бүген дә байтак әле. Кеше барлыкка китергән дөньяви фәннәрнең бик күбесе турыдан-туры табигатьтән алынган. Мәзәк хәлләр дә күп. Әйтик, бионика дигән фән бар. Биология плюс электроника. Бу фән белән шөгыльләнүчеләргә чебен-черкинең дә файдасы тиеп куя икән. Галимнәр бу хәшәрәтләрнең күзгә күренгән берничә аякларыннан башка шулар янында күзгә күренмәс йөзләгән, меңләгән ябештергеч нокталар барлыгын тикшереп белгәннәр. Бүгенге көндә шул принцип кайбер тауарларны (аяк киемнәре һ.б.) җитештергәндә кулланыла. Судан коры чыгучы үрмәкүчләр бар икән дөньяда... Шулардан күреп, водолазларга су эчендә су сыланмый-тими торган киемнәр әзерләмәкчеләр, ди. Бу дөньякүләм икътисади үсешкә караган мәсьәләләр...

Ә бездә әле һаман да табигатькә төкереп карау гадәте өстенлек итә. Әйе, әйе, турыдан-туры лач иттереп урамга аяк астына төкерү. Аяк киемеңне пычратасың килмәсә, безнең шәһәрләрдә гел аска карап, сазлыкта түмгәктән-түмгәккә сикергән кебек, бер басар чиста урын сайлап барырга туры килә; болай барганда ялгыш кешегә дә килеп бәрелүең бар.

Безнең урамнарга төкеректән башлап трамвай билетлары, туңдырма кәгазьләре, газлы, газсыз су, аракы, сыра шешәләре, целлофан пакетлар, конфет-печенье каплары һәм зур-зур тартмалар оча, чүп тутырган алагаем зур капчыкларның да аунап-тәгәрәп ятулары чит күренеш түгел... Шәһәр читләрен, андагы юл буйларын әйткән дә юк. Бу гадәтләр инде авылларга да артыгы белән күчкән. Бүгенге көндә авыл урамнарында җәяү атлап йөрү галәмәтләре дә хәтта ки куркынычка әйләнеп бара дисәң дә арттыру булмас, анда трактор, машина казыган бер сулы чокырдан икенче баткаклыкка төшәсең...

Бездә яшәгән халык бу хәлләрнең, әллә нинди юллар белән әйләнеп килеп, үзенең кесәсенә каты гына итеп китереп сукканын уйлап та карамый булса кирәк, һичьюгында, культурасызлык галәмәте була дип, бер фикерләп алсачы. Әлеге тискәрелекнең зыяны шуның белән генә тәмамланса икән! Үзләрендә чисталык-пөхтәлек саклаучы читтән килүчеләр алдында оятка калу гына булса икән! Шушы афәтнең нәтиҗәсе дә коточкыч: мондый халык калган барлык эшләрне дә эштер-өштер генә эшли дигән сүз бу. Чүпне чүп савытына салырга иренүче (чүп савыты булмаган очракта да һәркемнең кесәсе, сумкасы, ниндидер бер пакет-мазары, ә машинада йөрүченең чүп салырга урыны бар да бар инде), чүп савыты чынлап та юк икән, чүбен подъезд төбендәге, ишегалдындагы чүп савытына салырга теләмәүче эзлекле игътибар, зур физик яисә акыл көче салып эшләнергә тиешле башка эшләрне тиешенчә эшлиме инде? Моңа ышанган кешедән тавыклар да көләр. Чүп-чар проблемасы ул, чынлап та, икътисад проблемасы. Бу хәл теге яисә бу илнең артка калуы яисә (культурасызлык проблемасы булмаса) алга китүе турында сөйли. Әнә ялган социализмнан уянып, чын социализмга аяк басарга исәп тотып, бүгенге көндә бөтен дөньяны үзләренең тауарлары белән күмә башлаган кытайлар шул чүп-чар мәсьәләсен, шул күренешне бетерүне беренче урынга куйганнар. Алар (Кытай иле) хәзер АКШ белән хәтта Япониягә зур конкурент булып үсеп яталар, ди. Бу кичә генә дигәндәй, Кытайдан кайтучылар сүзе. Ләкин моны бездәге хәйләкәр алыпсатарларның Кытайның идән астында эшләнгән юри генә тауарларын бер тиенгә алып кайтып, бездә йөз тиенгә сатулары белән һич тә бутарга ярамый. Америка белән Япониягә, Германия һәм Франциягә нинди тауар чыгаруларын күз алдында тотарга кирәк. Әле быел гына Аурупа берлеге илләрендәге кибетләрне Кытай аяк киемнәре басып алу сәбәпле, аяк киеме тегүдә эшләүчеләр генә дә кырык мең эш урынын югалтканнар, ягъни Кытай конкуренциясенә түзә алмаганнар...

Әле тагын чын социализм булган илләр дә бар ич. Алар күп булмаса да, бар. Шуларның берсе – Швеция, һәм Финляндия дә шуңа якын тора. Билгеле, алдан ук әйтеп куярга кирәк, безнең өчен, татарлар өчен кабул итмәстәй нәрсәләр дә бар анда. Хәер, көнбатыш цивилизациясенең чит-ят күренешләре безгә дә үтеп керде инде. Ул хәлләрнең безгә зарарлы икәнлеген кабат әйтеп киткән хәлдә, без ирешәсе, омтыласы нәрсәләрнең күплеге күзне кыздыра. Пенсионерларның берничә төрле пенсия алуы, дәүләттән, хезмәт иткән җиреннән, профсоюздан һ.б. җирләрдән килгән акчалар швед гражданнарын бер дәрәҗәгә бастыра да куя, чынлап та, һәрберсе хезмәтенә күрә бүләкләнә. Бу хәл яшь гражданнарның эшлисе килүенә китерә, хезмәткә зур стимул бирә, анда «балам әбәзәтелни вузда укысын» дигән тиле теләк тә юк. Бигрәк тә ир балаларның ни өчен вузга укырга керергә теләүләрен чамалыйбыз... Тик бу ике җөмләдәге фикерләр һич тә белемгә омтылучы, талантлы балалар укымасын дигән сүзне аңлатмый...

Чын социализмда хезмәт кешесенең теләсә кайсы өлкәдә эшләсә дә дәрәҗәсе зур. Бездә элек булган социализмдагы кебек «таяк»ка эшләтү галәмәтләре юк.

Швециядә чүп-чар мәсьәләсе дә, безнең элеккеге термин белән урысча әйтсәк, «как в стране окончательно победившего социализма» кебек хәл ителгән. Өйләрдә һәр катта, һәр ишек кырыена кечкенә генә бер тартма эленгән, идәндә матурдан матур бик артык зур булмаган ябык савытлар куелган. Бәләкәй тартмага лезвие ише металл-корыч җыела, матур савытларга пластмасса, целлофан кебек нәрсәләр салына. Пыяла ише әйберләр әрәм ителми дә ителми инде. Агентлар килеп җыеп йөри, хуҗаларга әҗере-суммасы билгеләнә, үзләренә хезмәт хакына да җитә. Әйе шул, металл рудасын җир астыннан эзләп табып алып, лезвие һәм башка бик күп кирәкле нәрсәләр ясаганчы биниһая озын юл үтәргә һәм зур чыгымнар тотарга кирәк. Җир астыннан җир маен куып китереп, өскә чыгаруның ни икәнен безнең татар халкы бик яхшы күзаллый. Аңа киткән чыгымнар да исәпләп бетергесез. Әзер металлны яңадан эшкәртү, әзер пластмассны яңа төргәккә, торбаларга һәм башка бик күп нәрсәләргә әйләндерү бөтенләй башка эш. Бу инде икътисадның иң беренче шартын үтәү – әрәм-шәрәм итмәү була. Аннан мәрхәмәтле Җиркәйнең канын – нефтен, җелеген – металл һәм башка рудаларны берьюлы суырып бетерергә димәгән ич. Бу хәл Җирне аңсыз рәвештә талау, мораль югалту, битсезлек дип атала.

Бүгенге заманда башка барлык илләр белән бергә Россия дә, шул исәптән Татарстан да инвестицияләр чорына килеп кердек. Бу инвестицияләрнең мәгънәсе турында Германиянең «Deutschland» журналы түбәндәгечә яза: «Немец бизнесмены – капиталисты чит илгә инвестиция кертеп, анда ширкәт, фабрикамы, башка хезмәт урынымы ачса, үз илендә шул ширкәтенә өстәмә хезмәт күрсәтә торган предприятие ачып, чит илдәге өч хезмәт урынына нисбәтән бирeдә бер хезмәт урыны булдыру – аның бурычы». Билгеле, немец та адәм баласы, ул да хәрәмләшергә күп сорамас иде, әмма аның һәр адымын хакимият карап, тикшереп тора. Хәрәмләшә башласаң, штрафлардан башың чыкмас, муеннан чумарсың, хәрәмләшмәс идем дип гомергә тәүбә итәрсең. (Безнекеләрдән берәүнең Германиягә китеп, ширкәт ачып, әле аз гына хәрәмләшкән өчен дә гомерлек сабак алуын мин дә беләм.) Ә инде инвестициясен нормаль илгә юнәлдергән булса, ул (бу очракта немец капиталисты) үзенең түккән байлыгын да кайтарып ала. Чын профессиональ икътисадчылар әйтүенә, язуына караганда андагы капиталист «янмаса», шуңа канәгать икән.

Нишләсәң дә, ни әйтсәң дә, бездә эшләр алай түгел, бездә эре баена да, вак сәүдәгәр – кырыктартмачысына да, вак-төяк җитештерүчесенә дә йөз, ике йөз һәм аннан да күп процент керем – доход кирәк. Бу саннарның ни дәрәҗәләргә җитеп үсүен чын икътисадчылар, бу эшнең эчен-тышын аңлап торучылар яхшы беләдер. Элеккеге СССРдагыдан түбәнрәк хезмәт хакына һәм пенсиягә Америка Кушма Штатларындагы, Франция, Германиядәге бәяләрдән узып баручы хакка тауар, азык-төлек алырга мәҗбүр булган бу ил халкын кызганып, кулыңа каләм аласың. Шундый хәлләр эшләргә теләмәү, урлашу кебек афәтләргә коточкыч әйбәт җирлек булып тора. Уенда урлашу гына булган җан иясенә эш күз буар өчен генә кирәк. Бу икътисадка иң каты сугучы таяк... Хөкүмәтнең пенсия һәм бюджет өлкәсендә эшләүчеләргә хезмәт хакын арттырырга акча юк диюләр дә әкият кенә. Акча күп, ул читләр кулында. Хезмәт кешесенә акча арттырмау патша Россиясе заманыннан килгән әшәке гадәт кенә. Янәсе, халык, хакимиятләргә нык бәйле булып, аның күзенә генә карап торсын; колны буйсындырудан ләззәт алу шушы буладыр инде...

Ризасыз халык әлегә авыз эчендә ботка пешерә, аннан, бервакыт боткасы ташый башларга мөмкин, кайната-кайната авыз да пешә бит әле ул. Кеше пешергән әйберне төкереп ташлый... Шулай да Россиядә революцияләрне бай катлам сөя, ярата булып чыга, ахрысы, алай булмаган очракта бераз гына оялып яисә бераз гына куркып-шүрләп, аңга килеп, аппетитларын тыя төшәрләр иде. Югыйсә бөтен халыкныкы дип саналган нәрсәләрне шәхси кулларга төшерү, котырып бәһаләр үсү дәвам итмәс иде. Ә менә Көнбатыш дигән илләрнең капиталистлары шул революция дигән афәттән куркып, үзләренең байлыклары белән бүлешергә, дөресрәге, эшләгән кешегә хезмәт хакының тиярен – тиешлесен түләргә мәҗбүрләр икән. Әйткәнебезчә, алар да барыбыз кебек үк Аллаһ каршында гөнаһлы адәм балалары, алар да азрак түләүгә бер дә каршы булмаслар иде. Бездәге өстен катлауны бөтенләй дә аңлап булмый. «Акыл белән Россияне аңлап булмый...» дигәннәре шулдыр инде...

Үзгәртеп коруның беренче елларында, бездә Суверенитет декларациясе кабул иткән елларда, җөмһүриятебездә хәлләр шактый гына үзгәрә, әйбәтләнә башлаган иде. Россиядәге өлкәләр белән чагыштырганда бездә иң арзан бәяләр иде, халыкны саклый, яклый торган өстәмә түләүләр, акчалар кергән иде... Соңгы елларда бездән Мәскәүләргә алтмыш, җитмеш, хәтта сиксән процентка кадәр түләүләр кертелгәч, ни әйтсәң дә, юк инде...

Германиянең югарыда искә алынган журналы язуына караганда, анда әле яңа гына ширкәт ачкан өчен салымнар киметелгән, ә керемнәргә исә арттырылган. Бездәге шомбайлар барыбер керемнәрен бүрек эченә яшереп булса да калырга чамаласалар да, очын очка көчкә генә ялгап барган ширкәтләргә зур файда булыр иде. Германиядә бу эш шуны истә тотып эшләнгән дә. Бездә әле һаман да урта бизнеска ярдәм итү кирәк дигән сөйләнү генә бар.

Германия безнең өчен федератив дәүләт буларак та кызыклы. Бу дәүләтнең үзәк парламенты Бундестаг чыгарган законнарның алтмыш процентына кадәр федератив җирләрнең парламентлары Бундесрат вето сала ала икән. Ә менә күптән түгел генә берничә ел рәттән Татарстан законнарын үзәкләштерү – «приводить в соответствие»ләрне искә төшерсәң, көлеп үләрлек... Көлсәң дә, барыбер уй баса. Бу хәл шулай ук икътисад дигән сүз. Мең чакрым ераклыктагы үзәк минем өемә ни кирәклеген ничек белсен инде?! Германия хөкүмәте федераль җирләрдән башка Үзәктән «ү» хәрефе дә калмаячагын, димәк, яхшы аңлый. Андый аңлашу шулай ук федератив дәүләт булган Швейцариядә дә бар, диләр. Ул дәүләттә өч дәүләт теле барлыгын барыбыз да беләбезме икән?

Нефть чыгаручы гарәп илләрендә икътисад мәсьәләсе тагын да ачыграк хәл ителә. Анда илдә гражданлык хокукы булган һәрбер кешегә җир маен сатудан килгән акча бүленеп кулларына бирелә. Шул тупланган акчага ширкәт ачасыңмы, башкача кулланасыңмы – һәркемнең үз эше. Бездәге нефтьне сатудан килгән акчадан Стабилизация фонды җыябыз дигән булып, гражданнарның башын катырып, алдау юк. Гарәпләр дә алдашыр иде, гөнаһтан куркалар! Көнбатыш дигән дөнья мөселман диненең шул гаделлеге белән көрәшә дә инде!

*2006*

## ИЛ ТОТМЫЙЧА,
## ТЕЛ ТОТЫП КАРА...

Ил тотмыйча, тел тоткан халыклар өчен, ягъни үзләренең мөстәкыйль дәүләте булмаганнар өчен тел мәсьәләсе һәрвакыт кискен – кабыргасы белән, ягъни көнүзәк мәсьәлә булып тора. Әйе, Атилла Расихның мәгълүм хикәясендәге «тел мәсьәләсе» инде ул – трагедиясе, комедия-сатирасы бергә укмашкан.

Тел «озын» булу да телне кыскарта. Ягъни бер-берсе белән ызгышып, берничә мәртәбә дәүләтен югалткач, татар алдында туган телне саклау проблемасы барлыкка килгән... Әй яратабыз инде без бер-беребез белән үзебез өчен зыянлы бәхәс корырга. Акылга утырганыбыз юк әле. Бүгенге көндә дә үзебез белән үзебез бәхәсләшкән булып, телебез өчен җайлы булган «яңалиф»не дә кайтара алмадык. Милләт

өчен берәр уңайлырак форсат чыга башласа, безнең татар кирегә сүз әйтергә ашыга. Нишләптер Мәскәүдәге татарларның кайбер даирәләре коткыга күбрәк бирелделәр кебек. Тик кайда гына яшәсәк тә, татарның «первый» сорты да, башкасы да, иң беренче без бер-беребезгә кирәк. Без барыбыз да бер очтан каелган... Ходайга шөкер, татарның гены – нәселдәнлеге көчле, «төштән соң» булса да, акылы да бар... Дәүләтен югалту чорыннан алып, юлда көчле каршылыкларны җиңә-җиңә, билгеле, зур югалтуларга да дучар булып, тырышып-тырмашып телен саклый. Тел саклау – үзеңне саклау инде ул. Халкыбызның әдәбияты, сәнгате билгеле бер күләмдә сакланып калу шул шатлыкларның иң мөһимедер, мөгаен. Телебезнең борынгы үрнәкләре дә аларда сакланган.

Мөстәкыйль дәүләтең булмаган хәлдә тел саклау читенлеген башкалар мисалында да күрсәтеп үтеп була. Татардан бик күп мәртәбәләр уздырып, бөтен дөньяга таралган, ләкин шул ук вакытта бер-берсе белән иң оешкан-береккән милләт булган яһүдиләр дә телләрен бөтенләй диярлек югалтып бетергән булганнар икән. Алай-болай итеп, җир сатып алган булып, Израиль дәүләтен төзегәч, язмадан тел торгызалар, дип сөйлиләр...

Ай-һай, читен ул ил тотмыйча, тел тоту. Синең телеңә урамда бәйләнәләр, эшеңдә бәйләнәләр, мәктәптә бәйләнәләр, балалар бакчасында бәйләнәләр. Брежнев чоры дигән елларда эштә авыз ачып, үз телеңдә сүз әйтерлек хәл калмаган иде: «Не говорите по-татарски, это не культурно!» Куркытуның шундый «культурный» юлын таба беләләр диген, ә! Ярый әле, Разия апа, Мөслимә, мин:« Өйрәнегез сез дә безнең телне, гомер буе безнең белән бергә яшисез бит», – дип әйтә ала идек. Ә берсендә, урамда татар кешесе дип ялгыш эндәшкәч, «ваш поганый язык» дип йөзгә бәреп әйттеләр...

Менә тагын безнең өчен читен заманаларның кара офыгын ачабыз, дип, жириновскийлар йөгерешеп йөриләр. Безнең барлы-юклы дәүләтчелегебезгә теш кайрый башладылар. Һәм иң яманы – татар шунда ук арткы хутка баса башлады. Матур гына татарлашып килгән мәктәп-гимназияләребез күзгә күренеп артка таба тәгәри. Анда укучы балалар бер-берләре белән урысча сөйләшә башладылар. Иң ояты, сораштыра башласаң, «Казан утлары» журналының, «Мәдәни җомга» гәҗитенең ни икәнен ... белмиләр, башкалары турында әйтеп торасы да юк. Мондый чорда бездән бигрәк тә оешканлык, бигрәк тә эчке оешканлык таләп ителә дә инде. Халкыбызның милләт өлеше әйткән, сөйләгән, язган һәрбер үгетләү сүзләренә барчабыз да колак салып, аңлап чин по чиннарга, түрә-каралыкка яисә гади бер татар кешесе булуга карамыйча вак-төяк «мин-минлеккә», һавалану-зурлануга, бөтенләй дә начары – битарафлыкка бирелмичә, өч көнлек дөньяның алдавычларына кызыгып сатылмыйча, туган телебез мәсьәләсендә барыбыз да бер булып аны яклашсак, саклашсак иде! Безнең гомер мизгел, ә татар теле барыбыздан да олы, галибанә, ул мең-мең елларны кичеп килә. Билгеле, туган телебез дә татарга рәхмәтле булачак – үзенең гүзәл гыйбарәләре белән колакларыбызны иркәләп, укыган чагында күзләребезгә дә шифа булачак.

Бездә эчке оешканлык патша Россиясе заманнарында ук булган. Тик бүгенге шартларда аеруча оешканлык таләп ителә. Алда әйтеп үтелгәнчә, ун-унбиш еллар элек, салкын карны тишеп, җирдән калыккан умырзая чәчәге төсле, бер-бер артлы ачылган татар мәктәп-гимназияләренә конкурс белән укырга керү азайды гына түгел, аннан кире агым башланды. Безнең ата-аналар шундый да бер «сизгерлек» күрсәтәләр, имеш, заманаларның кая таба барганлыгын бик тиз аңлап алалар... Намус дигән нәрсә дә булырга тиештер бит әле дөньяда? Үзеңнең татарлыгыңа – туган телеңә хыянәт итү намуслылык билгесе түгелдер инде ул. «Бөтен дөньясы буталды, намус-хәя калмады», – дип, үзеңнең дә зарланырга хакың калмый ич!..

Күренекле язучыбыз Тәүфик Әйдинең бөтен дөнья буенча сибелгән татарлар турында язуын күбебез белә булыр. Ул сурәтләгән йөзләрчә татар кешесенең һәрберсе татар мәктәпләрендә укып, алга таба элеккеге СССРның әллә ничаклы мәртәбәле юуйларында (вузларында) белем эстәп, дөньякүләм атаклы кешеләр булганнар. Белмәсәң бел дигәндәй, атом реакциясе үткәрелә торган казаннарның ныклыгы да Казан шәһәренең ике-өч кенә йортлы Завод урамында уйнап үскән, татарның 12 нче мәктәбендә белем алган, безнең татар кешесе Шәүкәт Ибраһимовның фәнни һәм гамәли эшчәнлегенә турыдан-туры бәйләнгән булган икән. Әтисе-әнисе янына кунакка кайткан чагында, гел казан, казан дип сөйләгәч, үзенең аты белән йөк ташучы булып эшләүче этисе «Шул гомер укып, бер рәтле казан да ясый алмадыңмы әле?» дип, шаяртып әйтә торган булган. «Татар мәктәбендә укып, кеше булып булмый» дигән кайберәүләргә җавап булып языла минем бу сүзләрем. Юкны сөйләп йөрмик, татар мәктәбендә тырышып укыган балага ныклы белем алырга да, чын кешечә тәрбияләнергә дә мөмкинлекләр җитәрлек. Рухи яктан кеше булу бүгенге көндә иң әһәмиятлесе әле ул. Урыс мәктәбендә укыган һәр татар баласы югары уку йортына кереп укый дип белерсең. Алай түгел ич, аннан соры масса күбрәк тә чыга. Бу хакта Казан дәүләт университеты студенты Эльмира Гыйсмәтуллина болай әйтә: «Урысча миллионлаган кеше укый... Ә шулай да илебездә күпме сукбайлар, эшсезләр, ярлылар, җинаятьчеләр...» Яисә бик тә билгеле, күркәм укытучы, Даур урамына урнашкан педагогик көллиятнең директоры Марат Лотфулла улы Гайнетдиновның әйткәннәренә колак салыйк. Тулай торакта яшәүче дүрт йөз студент бала арасында бер генә наркоман да, эчкечелек белән шөгыльләнүче дә, тәмәке тартучы да юк, ди ул. Ә менә татар мәктәбендә укып, берәрсенең баласы алга таба укый алмаса, бу сүз

тиражланып таратыла. Бу эштә баланың әти-әнисе «тырышлык» күрсәтә... Гаепне башка җирдән эзләсә дөрес булыр иде...

Заманалар үзгәреп, хосусый милек, хосусыйлаштырулар килде. Байлык шәхси кулларга күчә. Бәлки, татар байлары да күбәя төшәр әле дип ышанасы килә. Тик әлегә алар элеккеге Хөсәеновлар да һәм башкалар да түгел. Татар телен яшәтү өчен матди ярдәм кирәклеген аңлый торганнар сирәк күренә. Өстәвенә һәртөрле кызганыч хәлләр шаһиты да булырга туры килә. Бераз хәлле бүгенге көн татар кешесе бер шәһәрдә ике дә уйламыйча мәктәп белән мәчеткә хатын-кызлар өчен иркен янкорма төзетте. Шул чакта бер дин эшлеклебез булышчыбызның шәхси тормышында көтелмәгән ... этлек эшләде... Аяныч ки, яшь кешебез мәчеттән дә, татар тормышыннан да бизде. Ул хәзер башка халыклар арасында. Менә шундый югалту. Мәчет-мәдрәсәләрдә туган телнең бик аз өйрәнелүе аларның җитәкчеләренең милли аңы түбән дәрәҗәдә булуын да күрсәтә, күрәсең.

Без гелән-гелән генә тискәрелек-кирелектән тормыйбыз ич инде. Үзебезнең уңай сыйфатларыбызны эзләп табып, билгеләп карыйк әле. Иң беренче мин безнең тормышта бик кызыклы бер хәлне беләм. Әллә кайларда, Татарстаннан читтә яшәүче, туган телебездә рәтләп ипилек-тозлык та сөйләшә белмәүчебез дә «родной язык» дигән графага «татарский» дип яздыручыларыбыз турында әйтүем. Соңгы вакытта ул графаны юкка гына бетермәделәр ич инде, кемгәдер комачаулый...

Аннан, тагын да мәктәп белән бәйле хәл. Ата-аналар, мәктәпкә килеп: «Ипи, тоз дип әйттерә алмаган балаларыбызга туган телне өйрәтәсез, рәхмәтләр яусын сезгә», – дип, елый-елый рәхмәт әйтәләр иде. Монда әле елау гына түгел, бер күңелле кызык та бар. Идел-Урал төбәгендә шул Брежнев хакимияте елларында урысча укытуга күчеп беткән катнаш мәктәпләрдә туган телне өйрәтү бары татарларда гына иде. Соңыннанрак, бездән күреп, башка халыклар да укыта башлады. Күркәм сыйфатларыбызны барлап, бүгенге көннән дә мисал китереп була. Бары тик бездә генә мәктәпләр һәм югары уку йортлары өчен урыс балаларына һәм студентларына аталып программалар төзелгән, дәреслекләр чыгарыла. Сөбханаллаһ!

Татар халкы үзенең яшәешенең җайсыз-уңайсыз чорларында туган телен җыр җырлап та саклый. Бу уңайдан бик зур ярдәмчебез ул җыр. Сихри көйләргә үрелеп, колакка ятышлы сүзләребез күңелгә сеңә, үзләштерелә. Татарның иң күп барган-йөргән җирләре театр һәм җыр концертларыдыр. Тик соңгы елларда җырга кагылган уңайсызлыкларыбыз да чыгып тора. Глобальләштерү шаукымы (империализмның яңа шәкеле) милли көйләребезгә дә һөҗүм итә башлады, дөньякүләм бертөрле көйсезлек-моңсызлыкка тартып кертмәкче булалар. Татар көе хәтта үзебезнең төрки кардәшләребезнекеннән дә аерылып торуы белән яшәде, әле дә шуңа омтылырга, аерымланырга кирәктер. Моңа чаклы татар колагы иң нечкә моңлы борылышларны, мелизмнарны ишетеп яшәде, ә инде бер-ике генә нотадан торган, турыдан-туры кычкырта торган көйләр җырлый, тыңлый башласак, бөтенләй дә тупасланган колаклы татарлар кавеме барлыкка килергә мөмкин, Аллаһ сакласын! Үзләренең көйләрендә мелизмнар булмаган халыкларның колаклары безнең көйләрнең нечкәлекләрен ишетми ич, һәркемнең үзенчә.

Гафу, язмамның бу өлешендә үзебезнең уңай сыйфатларыбызны гына барлыйк, дигән идем, шуны дәвам итик әле. Дәүләтчелек структураларыбыз да туган телне саклауда тырышлык күрсәтергә омтыла. И кардәшләрем, әгәр дә сез март аеның соңгы ун көнлегендә Мәдәният министрлыгы һәм Хор җәмгыяте оештырган Сигезенче хор ассамблеясенең соңгы концертын гына карасагыз да, күңелегезгә күпме хушлыклар алып кайта идегез. Көе белән бергә сүзләре дә җырлап торган әсәрләр иң көчле алкышларга күмелде. Бөек телебезнең җиңүе, тантанасы иде бу!

Бөтендөнья татар конгрессының туган телебезне саклау буенча эшчәнлеген дә озак итеп сөйләп һәм язып булыр иде. Үзебезне бераз мактап алгач, тагын да борчулы хәлләребез чабудан тарта. Телебезне баетуда без ялгышрак юлда бугай. Бөтен халыкларда да тел, нигездә, алынма сүзләр хисабына байый. Барчасы да күршесеннән сүз ала да, үз теленең кагыйдәләренә туры китереп, аны әйтә башлый; яңа сүз шулкадәр дә үзләшеп китә, аны читтән кергән дип сөйләүче уйламый да, бары тик галимнәр генә ул сүз тарихын өйрәнеп-тикшереп, аның беренчел нигезен табарга мөмкин, чынлыкта ул сүз кабул иткән телнең үзенеке булып йөри – «ищи ветра в поле» кебек. Ә менә безнең тел мисалындагы хәлләр гаҗәпләндерә. Бездә алынма сүзне үзенең иске кагыйдәләре буенча хәрефен хәрефкә туры китереп язалар, авазын безнең артикуляциягә туры килмәгән очракта да бугаз ертып әйтәләр һәм... әйттерәләр. Гүя безне кемдер күзәтеп, болар сүз урламасын дип, карап-тикшереп тора. Нәтиҗәдә теге сүз дә «мин сезнеке түгел» дип «кычкырып» тора. Алай тел баетып булмый. Үзебезнең тел тегермәнендә - тарттырсак кына безнеке була ул алынма сүз. Тел баетуның тагын бер юлы – диалекталь сүзләрдән - файдалану. Татарның диалектлары бай, күптармаклы, шундый кирәкле, шундаен да матур сүзләр күп алар эчендә, сайлап-сайлап кына иң кирәклеләрен, иң матурларын аласы гына кала, ләкин ялт итеп каршы төшүчеләр табыла... Бу хәлне дә үз ботагыңны үзең кисү дип әйтмичә, башкача әйтеп булмыйдыр.

Тел саклау һәм аны баету мөмкинчелеге булып торган тагын бер урыныбыз бар. Безнең шартларда бу урын беренчеләрнең дә беренчесе әле. Бар ул андый урын – ул гаилә. Әби-бабае, әти-әнисе, угылы-

кызы булган гаиләдә мөлдер-мөлдер генә тутырып, гөлдер-гөлдер генә гөрләшеп-сөйләшеп чәй эчеп утыруны гына күз алдына китерсәк тә, туган телебез өчен борчылуларыбызның нәкъ яртысы юкка чыгар иде! Сирәгрәк күренештер шул бу. Ешаеп торсын иде шундый матур манзаралар, күңелдән агылган теләкләр. Шигырь дә шуны тели:

... Газизем дип, кадерлем дип,
Иркәләсәм баламны,
Бу чынында үз телемне –
Татар телен барлавым.

Шикәрем, балым дисәм дә,
Бал тәмен тоям телдә.
Чын татар гамәле булыр –
Сөйләшик туган телдә!

Газиз телем – чиксез күгем,
Син – диңгезем, хыялым.
Мәңгегә сине яшәтү –
Бердәнбер ихтыярым!
*2004*

## 3. Исәнме, Әлифба бәйрәме!

### ИСӘНМЕ, ӘЛИФБА БӘЙРӘМЕ!

Аллы-гөлле салават күпере чыгарып, бии-бии яуган күңелле, яңгыравыклы, уйнак, кояшлы яңгырны күргәнегез бардыр инде сезнең. Хәер, кыш уртасында кояшлы яңгыр турында бу нинди сөйләшү дип шикләнеп тә куярга мөмкиндер. Чынлап та, кыш уртасында кояшлы яңгыр түгел, ә кояш үзе дә әз-мәз генә күренеп китә безгә. Ә шулай да кояшлы яңгыр кебек күңелле күренешләр әле безнең тормышыбызда табыла икән. Дөресрәге, алар туып килә. 1991 елның 25 декабрендә (нинди өметле ел!) Казан шәһәренең Киров районындагы 81нче мәктәбенә Әлифба бәйрәменә җыелучылар күрде шундый күренешне. Кечкенә кояш кебек балкып торучы 1нче сыйныф балалары ай сыман түгәрәкләнеп тезелешеп басканнар да гаҗәеп матур тамашаны – Әлифба белән саубуллашу тантанасын әтиләргә, әниләргә, әбиләргә, бабайларга, апаларга һәм башка бик күптөрле кунакларга күрсәтәләр.

Үзебезнең туган телебездә – татар телендә бу кадәр дә матур итеп сөйләшүне балалар авызыннан тыңлаганга күрә күңел тула, куана, канатлана, тыңлаучы-тамашачылар күзендә шатлык яше ялтырап китә, рәхәтләнеп бүләк иткән алкышлар яңгырый. Шатланырлык та, алкышларлык та шул. Инде беттек, татар халкы үлеп бара дигән фикер миләргә кереп җәфалаган бер заманда шундый яңарыш, халыкның яңадан туарга талпынуын күрү зур өметләр уята, канатландыра. Әлифба бәйрәмен сары каз бәбкәсе хәтле генә бер кызчык алып бара, шулкадәр табигый, сөйкемле, һәрбер сүзе йөрәккә сары май, күңелгә бәлзәм. Кызчык оялмый, тартынмый, әйтерсең сәхнәдә олы бер тормыш юлы узган; гомумән дә, беренче сыйныфтагы укучылар бик кыюлар. Менә тагын ике кызчык, иңбашларын сикертә-сикертә, күлмәк итәкләрен җилфердәтә-җилфердәтә, шаян, күңелле җыр җырлый... олылар җырын башкаралар. Бу уңайдан бер нәрсәне искәртәсе килә. Күптән күзәтеп киләм, әгәр балаларны ирексезләп, тема кысасына кертеп, Октябрь бәйрәменә туры килгән җырларны, пионер, октябрят, комсомол һәм башка шундый кызыл даталарга багышланган балалар җырларын җырлагыз, дип кушып тормаган очракта, алар элек тә зурлар җыры дип аталган матур җырларны, бигрәк тә халык җырларын яратып җырлыйлар иде. Мин моны үземнең мәктәптә эшләгән вакыттагы күзәтүләремнән дә чыгып беләм. Күрәсең, балалар өчен табигый яңгыраган матур җырларыбыз аздыр. Шундый сәбәп тә бардыр. Бу Әлифба бәйрәмендә дә балалар халкыбызның уенлы-җырлы матур көйләрен башкардылар. Аларны балалар авызыннан ишеткәндә бигрәк тә күңелгә хуш килә икән, бу күренештә уш китәрлек мәзәклек тә бар. Кичәдә матур-матур бик күп шигырьләр дә яңгырады, кечкенә-кечкенә генә сәхнә әсәрләрен дә уйнап күрсәтте балалар. Әлифбаны укып чыккан беренчеләрне икенче сыйныфта укучылар, өченчеләр котлады. 81нче мәктәптә быелгы уку елында беренче мәртәбә өр-яңадан өч татар сыйныфы ачылган. Беренчеләр турыдан-туры татарчага килгәннәр, ә икенчеләр һәм өченчеләр үткән уку елында урысча укыган булганнар (нинди гүзәл күчеш булган, ата-аналар ашкынып күчергәннәр, әле конкурс белән!). Аларның сөйләмендә инде үзгәрешләр бар – «минга», «синга» дигән әйтелешләр ишетелеп китә. Укытучы Мәрзия ханым Вафина, соңыннан: «Бер-ике ел эчендә тел ничек бозылган бит, әй, ун ел эчендә нишләп бетәр иде ул?» – дип әйтеп үтте. Әйе шул, икенчеләр беренчеләр белән чагыштырганда ничектер ачылып бетә алмадылар шикелле, аларда кыенсыну сизелә иде, беренчеләрдә булган кыюлык, табигыйлек җитеп бетмәде. Бу хәлне ата-аналар да күрделәр. Алар туган тел елгасы агымына бик тиз

төшәрләр, рәхәтләнеп йөзеп китәрләр, әмма бу хәл сабыйның беренче сыйныфтан ук үз туган телеңдә белем алуның нинди зур әһәмияткә ия булуын тагын бер кат раслый.

Бернәрсәнең дә үзеннән-үзе барлыкка килмәвен беләбез, шуңа күрә бу асыл бәйрәмне башлап йөреп оештыручылар, үткәрүчеләр турында әйтергә кирәктер. Халык арасында бик күп булучы, татар дөньясын йөреп чыккан, әлеге бәйрәмгә дә матур җырлар бүләк иткән яраткан җырчыбыз Шамил Әхмәтҗанов: « Бик күп мәктәпләрдә булганым бар, татар гимназияләрендә дә, бу кадәр матур бәйрәмне күргәнем юк иде», – диде. Әйе, кемнәр соң алар – бу бәйрәмне үткәрүчеләр? Илгизәр Тимергали улы Гайсин – мәктәп директоры. Ул бу мәктәптә икенче ел гына эшли, әмма мәктәпне баштанаяк үзгәртеп тә куйган. Мәктәпнең бинасы утызынчы елларда ук төзелеп, хәзер хәрабә хәлендә калырга мөмкин булган. Директор бүгенге кытлык заманда могҗизадай эш эшләгән: мәктәп бинасын эчтән әкияти бер өй сыман бизәп, төзекләндерү эшләре үткәрелгән, мәктәпкә татар милли рухы кергән, ашханәнең стеналарын безнең тәмледән-тәмле милли ризыкларыбызның рәсемнәре бизи (моңа чаклы булган хәлме?), өстәлләрдә ак ашъяулык, ә һәрбер уку бүлмәсенең ишек башына шул бүлмәдә укытыла торган фәннең исеме башта татар телендә, аннан соң урыс телендә язып куелган. Казан шәһәрендә башка шундый мисалларны табуы да шикле кебек (соңыннан гына яза башладылар), хәтта Бәйсезлек турында декларация кабул иткәннән соң да кайбер мемориаль такталарда да андый уңай үзгәреш юк, башта урысча, аннан соң гына татарча языла. Һәрнәрсәнең рәте-чираты бар дигәндәй, безнең җөмһүриятебезнең исеме Татарстан, бар нәрсәдә дә шуннан чыгып эш ителергә тиешледер. Мәктәп утызынчы елларда төзелгән дигән идек. Башта ул татар мәктәбе булган, аннан шул бер язмышка – урыс мәктәбенә авыштыру язмышына дучар булган. Ә менә Әлифба бәйрәме, гомумән дә, беренче мәртәбә үткәрелә икән. Безнең халыкка тыйнаклыкны сатып аласы түгел, ул ишелеп бирелгән, бушлай. Хәтта кирәкмәгән дәрәҗәдә тыйнак ул безнең татар халкы. Куркытудан туган тыйнаклык. Әйтик, шушы ук уку елында Мәскәү районының 135 нче мәктәбендә дә татар класслары ачмакчы булганнар, ләкин алты гына бала җыя алганнар. Бу очракта ата-аналарга барлык курку-өркү, тыйнаклыкларын куеп, бирелгән хокуклардан файдалану турында кичекмәстән уйлыйсы түгелме икән? Югыйсә бит татарлар балаларын туган телләрендә укытасылары килми диеп, безнең оешмаганлыктан файдаланучы бәгъзе мәгълүм матбугат органнары язарга, сөйләргә мөмкиннәр. Әллә без, татарлар, һаман да, алдана күрмик дип, вакланып, вак-төяктә откандай булып, зурдан оттыруны дәвам итәрбезме? Яңа ачылган татар сыйныфларында да, татар гимназияләрендәге кебек үк, киң профильле укытуны тормышка ашырырга, төрле телләрне: татар, төрек, урыс, инглиз һәм башка телләрне, төрле фәннәрне тирәнтен өйрәнү юлына басарга торалар. Шуңа күрә балабыз тиешле белемне алмый калыр дип курыкмагыз, кадерле ата-аналар! Әгәр дә сез 81 нче мәктәптәге беренче сыйныф укучыларын барып күрсәгез, һич шикләнми, йөгерә-йөгерә бәбкәчләрегезне татар сыйныфына илтеп бирер идегез! 135 нче мәктәптәге урыннар да буш тормас иде, ә аннан соң татар мәктәпләре аерым-аерым да ишәерләр иде.

81 нче мәктәптә укытучылардан да бик уңганнар шул. Анда Вафина Мәрзия ханым үзе генә дә ни тора! Ул – математика укытучысы, ашкынып, курслар узып, математиканы татарча укытырга күчкән, татар теле укытучыларын да кимсетергә теләүчеләрне тыя алган. Аның кулында Ходай биргән хәзинәсе дә бар: тальянда өздереп уйный, гармунчы да, җырчы да дигәндәй, баяны да кулында. Билгеле, шундый кеше булганда, ничек бәйрәм үткәрим икән дип кайгырып торасы юк. Бу мәктәптә Казан дәүләт педагогия институтының өлкән курс студентлары мәш килеп эшләп йөриләр икән. Татар телен укытуга бөтен гомерен биргән, татар мәктәпләре, татар теле өчен иң авыр елларда да мәктәптән китмичә, урыс мәктәбендә булса да, татар телен дистә еллар буе укыткан, бик тә тәҗрибәле укытучы Наилә ханым Кадыйрова әлеге булышчылар турында мактау сүзләрен әйтте, бу бәйрәмне оештыруда да бик актив катнаштылар, диде. Димәк, татар телендә төрле предметларны укытырга укытучылар җитешми дип көтеп торасы түгел икән, югары курс студентларына ирек бирергә, укытучылар җитешмәгән очракта алар менә дигән иттереп эшли ала икән.

Соңгы бер-ике ел эчендә генә дә никадәр үзгәрешләр күрәбез. Әйтик, 81нче мәктәптә татар телен укыту мөдире штаты каралган. Әле биш-алты ел гына элек бу турыда уйлап та булмый иде. Әле кайчан гына ана телебез Казан шәһәрендә, башка шәһәрләребездә, район үзәкләрендә, хәтта байтак авылларда да ниндидер бер мәсхәрәле секта хәлендә калган иде. Күрде безнең башлар диярсең. Әле сиксәненче-туксанынчы елларда гына татар балалары белән җыелышып, ата-аналарны да чакырып, сөекле Габдулла Тукаебыз туган көн бәйрәмен мең бәла белән тырыша-тырмаша үткәрә башласаң, завучларның, хәтта директорның үзенең дә чыш-пыш, колактан-колакка: «Там татары собираются!» – дигән шомлы сөйләшүләрен ишетергә туры килә иде, гүяки без үзебезнең туган җиребездә түгел дә, гүяки без куркыныч бәндәләр. Менә хәзер күңелләргә өмет әйләнеп кайта кебек.

* * *

...Алга таба, бәлки, дәреслекләр чыгару да җайга салыныр. Бәлки, бәлки... Ә хәзергә әле «Әлифба»ны укып чыккач, мәктәп алдында алга таба укыр өчен беренчеләргә «Туган тел» дәреслеген

табу бурычы тора икән... Без тагын да бөтенесен яңабаштан башлыйбыз булып чыга. 1905 елдагы кебек, 1917 елдагы кебек.

1917 елда әдипләребез чын күңелдән ышанып, «башлана башлады» дип язганнар иде, тик тора-бара барысы да кирегә таба сүтелде, үтереш-бетереш, юкка чыгаруга кайтып калды. Ходай тарафыннан аерым-аерым яратылган милләтләрне бергә буташтырып, совет халкы дигән зат ясамакчы иделәр дә, коточкыч хакыйкать алдында калдык – адәм балаларының байтагы үзләренең кеше икәнлекләрен дә оныта башладылар. Хәтта патша Россиясе коллыгында да татарның үз балалары үз кулында булып, үз мәгариф системасын үзе җитәкләп барган. Шул халыкның балалары совет заманында кулыннан тартып алынды, алар урысча укыту системасына куып кертелде, хәтта татар мәктәбе дип аталып йөргәннәре дә чынында татар милли мәктәбе түгел иде.

Шулай итеп, без урыс мәктәбе аша миллионлаган балаларыбызны югалттык, чит кавем төсенә кереп, алар юкка чыктылар. Бу бит йөз генә, мең генә бала түгел. Миллионлаган бала өчен кычкырып еларга кирәк! Моннан соң ничек итеп авыз тутырып милләт генофонды, милли йөз турында сөйләп булсын инде? Безнең проблема: беренче сыйныфта укучы унтугыз гына балага ничек итеп унтугыз «Туган тел» китабы табарга? дигән сорауга килеп терәлә. Яисә хәзерге вакытта килеп туган христианлаштыру куркынычыннан урыс мәктәбендә укучы татар балаларын ничек саклап калырга? Поплар мәктәпләргә килеп йөри башлаган. Радио, телевидение һәр көнне диярлек христиан динен мактау белән шөгыльләнә. Ә безнең балалар кайчан үзебезнең милли мәктәпләргә күчеп бетәрләр икән?..

*1992*

### ҮЗЕБЕЗНЕКЕ ҮЗӘКТӘ БУЛСЫН ИДЕ

Бүгенгедәй хәтерлим әле, үзгәртеп кору чорында – 1989–1991 елларда ун меңгә, ә кайсыбер көннәрдә хәтта илле меңнәргә хәтле татар халкы җыелган митингларда, күзләреннән мөлдерәгән яшьләрен кулъяулык чите белән сөртә-сөртә: «Беттек бит, Казаныбызда бер генә татар мәктәбе дә калмады, балаларыбыз «әти-әни, ипи, тоз»ны да үзебезчә әйтмиләр. Кирәк татар мәктәбе, кирәк!» – дип ачынып, үз фикерләрен әйтми калмыйлар иде. Микрофоннан сөйләгән ялкынлы чыгышларны санап бетереп булмас иде...

Бик зур, катлаулы киртәләрне үтеп чыгып ачылды татар мәктәпләре, татар гимназияләре. Хәлләр Казанда гына, башка шәһәрләрдә генә түгел, район үзәкләрендә, авылларда да мөшкелләнгән иде шул. Бик күп авылларда уку урысчага күчерелгән, район үзәкләрен әйтеп торасы да юк иде инде.

Шундый бер әйбәт заман булып алды – Казаныбызда, җөмһүриятебезнең башка шәһәрләрендә, район үзәкләрендә (күпчелегендә), авылларда татар мәктәпләре торгызылды, яңадан ачылды. Тик безнең шатлык озын гомерлегә охшамас кебек тоела башлады бит әле. Күз алдыбызга бу хәлнең куркыныч дәлилләре чыгып баса башлады. Татар мәктәпләрендә фәннәрне урысча укыту шаукымы башланган. Ә җөмһүриятебезнең уналты район үзәгендә татар мәктәпләре бөтенләй ачылмаган да икән әле. Бөтендөнья татар конгрессы җитәкчелеге тарафыннан шундый район үзәкләрендә хәлләрне белешү-танышу, аңлашу, хәл кадәренчә ярдәм итешү өчен төзелгән бер эшче төркем белән бергәләп шул төбәк үзәкләрен йөреп, әйләнеп чыктык.

Район мәгариф җитәкчеләре, нигездә, үзәктә татар мәктәбе ачар өчен даими тырышлык куюларын исбатларга тырыштылар: татар балалар бакчалары ачу, мөмкин булмаганда татар төркемнәре оештыру (мөмкинчелек юклыкның сәбәбе итеп татар белгечләре җитешмәвен күрсәттеләр), һәрбер татар баласын алдан ук исәпкә алу, ул бала һәм аның әти-әнисе белән аңлату эшләре алып баруны да күрсәтеп үттеләр. Берничә район үзәгендә (Югары Ослан, Алексеевский) татар балалары контингентының аз булуы хакында да әйтелде. Бигрәк тә Болгар шәһәрендә безнең халыкның аз булуы күңелләрне тетрәтте.

Татар мәктәбе ачылмауның бер сәбәбе итеп мәктәп бинасы булмау да күрсәтелде. Уйлап карасаң, күктән өр-яңа балалар төшми, шул ук, бер үк балалар укыйсы бит булган биналарда. Шул балаларның бер өлеше – татарча, икенче өлеше урыс телендә укыячаклар. Зуррак, шәһәр сыманрак район үзәкләрендә балаларга ерак урамнардан татар мәктәбенә йөрү читен – автобус белән йөрергә туры киләчәк, диделәр.

Менә шундый сәбәпләр. Бу сәбәпләрне милли үзаңы бар кебек күренгән татар җитәкчеләре дә, шулай ук татар кешесе булып та, татарча матур гына сөйләшә алып та, «я на русский перейду» дигәне дә, элеккеге заманнардан аермалы буларак, бу мәсьәлә хакында әлегә йомшак кына итеп сөйләшергә тырышкан башка милләттән булган җитәкчеләр дә зурдан кубып тәкрарладылар. Ләкин сәбәпләрнең иң аянычлысы бар иде әле: кайбер район үзәкләрендә әлегәчә татар мәктәпләре ачылмавының сәбәпчеләре, ә инде ачылганнарында предметларны укытуда урысчага күчерешү әйдәмәннәре, әле генә без югарыда күрсәтеп үткән, моннан ун, унбиш ел элек кулъяулык чите белән күзләрен сөртә-сөртә

елап торган ата-аналар, имеш. Ничек шулай тиз үзгәреп була икән? Үзеңне-үзең татар итеп саклап калыр өчен безнең шартларда, башка кавем эчендә бик нык тырышырга кирәклеген, моңа бары тик балаңны татар мәктәбендә укытып кына ирешергә мөмкинлеген белмәүчеләрме әллә алар?

Казан ханлыгы ауганчы татар белән урысның җан исәбе бертөрлерәк сан белән (икесе дә җидешәр миллион тирәсе) билгеле булган. Без менә хәзерге саннарны һәм нисбәтне дә яхшы беләбез. Безнең халыкның тырышу юнәлеше – башкага кан-нәсел бирүе хурлык кына да түгел (моңа сүз табып бетереп булмый), бу манкортлык кына да түгел, бу мәгънәсезлек кенә дә түгел, моны мисезлек дип кенә атап буладыр инде.

Мәгариф җитәкчеләренең берсе (ир-ат кеше!) «без татар балаларын татар мәктәбендә укытсак, чуаш балалары нишләр» диде. Татар белән чуаш баласы урыс телле мәктәптә укырга тиешләр икән. Балаларның татар мәктәбендә һәм чуаш мәктәбендә укуы нишләп ярамый, анысын аңлап булмады. Хәер, ул җитәкче икесе (татар баласы белән чуаш баласы) бергә укыганда гына дуслык була дип аңлатырга тырышты. Ә менә икесе дә үзләренең милли мәктәбендә укып та, чын дус, кардәш булып калуның кадерлерәк, кыйммәтрәк, кешечәрәк булуын аңламауны һич кенә дә аңлап булмады. Ирексездән Күлтәгин язмаларындагы сүзләр (VII гасыр) искә төшә: « Мин күпме халыкларны җайлы урнаштырдым... үз ыруларым алдану һәм сатылу аркасында исәпсез санда һәлак булдылар...» Төрки-татар кавеменең таркаулыгы гомер буе, мәңгегә дәвам итәргә тиеш түгелдер бит инде?! Безнең башка халкыбыз юк. Яхшымы ул, яманмы ул, аңардан бердәмлек сорала. Бердәм булмаганны тормыш, тарих себереп ташлый...

Бүгенге көндә безнең татар кешесе авыл җирендә дә баласын янәдән урыс телле мәктәпкә илтеп тыга башлаган. (Мондый хәл хәтта патша Россиясе заманында да булмаган, бу элеккеге СССР чорындагы коммунистларның мәкерле сәясәт эше иде.) Янәсе, югары уку йортына керергә җиңел булсын, гүяки урыс телле мәктәпне бетергән бала рәттән вузга керә бара, гүяки татар мәктәбен тәмамлаучылар керә алмый. Татар мәктәбен, гимназиясен тәмамлаучыларның югары уку йортына керү дәрәҗәсен – бик зур процентын әйтеп бирсәң, әле яңа сүз уйлап тапканнар икән: кергәч, укырга авыр, имеш.

Балаң милли мохитле мәктәптә рухи ныгысын, бүгенге шаукымлы заманның усал җилләренә бирелмәсен, куркыныч агымнарга иярмәсен дисәң, алга таба югары уку йортына укырга керсә яисә эшкә урнашса да, ярты ел гына кайбер читенлекләргә түзәр инде! Шушы ярты ел вакыт аралыгында үзенә кирәкле булган яңа күнекмәләрне үзләштереп бетерә ул.

СССР вакытында ук әле, урыс телле катнаш мәктәптә укып, Мәскәү, Ленинградның иң престижлы дигән вузларына укырга кергән безнең иң башлы балаларыбызны мәкерле юллар белән кришнаидлар, башка төрле әллә нинди сектантлар ясап, укуларын ташлаучылар, беркайда да эшләмәүчеләр, хәтта ки хәер сораучылар иткәнне безнең ата-аналар әллә онытты да микән? Үзебезнең милли аң бирә торган татар мәктәбендә укыган булсалар, ул балалар безгә ят булган нәрсәләрне күрми, аңламый калырлар идеме соң? Ә бүгенге көндә исә үзебезнең мохиттән киткән баланы (хәтта зурракларны да) нинди афәтләр сагалап торганын әйтеп бирүе дә куркыныч.

Безнең яшьләрнең бүгенге тормышта гомерлек утка эләгүеннән бердәнбер саклану чарасы – милли татар мәктәбе. Аннан, әгәр дә син үзеңне намуслы кеше дип саныйсың икән (кайсыбызның бу сыйфаттан ваз кичәсе килер икән?), бөек Тукаебыз телен, татар телен, ана (!) телебезне саклау – андый кешенең бурычы! Намус эше.

Әйе, беләбез, аңлыйбыз – дәүләт тотмый тел тоту читен инде ул. Ләкин дә бит дәүләт югалтуда да без үзебез күбрәк гаепле... Татарның һәрберсенең эчтән генәме, ачыктан-ачыкмы үз милләттәше алдында үзен генә әллә кем дип хисаплый торган сыйфаты бар кебек: кардәшенә, милләттәшенә баш бирми, ягъни берләшми, алай гына түгел, ул нишләптер башка кавемгә авып төшә, хәтта, куштанланып, башкалар алдында үз кардәшенә каршы чыга. Бигрәк тә үз кардәше-милләттәше белән талашудан тәм таба. Бер мизгеллек куанычка тормаган мондый «җиңүләр» гомерлек тарихи хаталарга сәбәпче була. Мондый хәлләр көнкүрешкә карыймы яисә зуррак мәсьәләләргәме, барыбер зыяны тигез тия. Кызганыч, мондый мисаллар тарихта – үткәндә дә, бүгенге көндә дә буа буарлык. Югыйсә дөньяда моның киресе булган мисаллар да аз түгел. СССР вакытында юри урысча кычкырып торган акцент белән сөйләшкән милләтләр бүгенге көндә үз дәүләтле булдылар.

Дәүләтең булмаган килеш туган телне саклау өчен икеләтә тырышлыклар таләп ителә, чөнки әле дөньяда мөстәкыйль дәүләтләрнең уңышлы – бәхетле дигәне дә, дөньяны кулымда тотам дигәннәре дә үз милләтен саклауда берсеннән-берсе күптөрле тырышлыклар куеп яши. Әйтик, Франция акчасы артык булганнанмы, әллә һәр елны кимендә бер мәртәбә бөтен дөньядан халык-фольклор коллективларын үзенә җыя да французларга, әйдәгез, карагыз, белегез дөньяда күпме төрле халыклар яши, аларның нинди кызыклы, үзенчәлекле телләре, сәнгатьләре бар, дип, ай буена шул ансамбльләрнең концертларын мәйданнарда, бакча-паркларда, урамнарда күрсәтә. Бездән, Татарстаннан да, кимендә бер-ике ансамбль барып кайта ул бәйрәмгә.

Үзен бөтен дөньяга баш дип хисаплаган Американың шаукымы безгә әле яңа тия башлады, ә алар (Франция халкы, хөкүмәте) инде ничә еллар шуннан җәфа чигәләр. Француз киноларын, әдәбиятын, сәнгатен, фәнен дә (инглиз телендә сөйләшүчеләр «француз телендә фән турында сөйләп, язып буламы соң?» дип көлә башласалар да, безгә, мәсәлән, бу гаҗәп тоелмас иде, чөнки без үзебезгә карата мондый оятсыз сүзләрне ишетеп яшибез) кысып чыгармакчы була океан артының кыйммәткә төшкән арзанлы примитивлары.

Россиядә дә хәлләр шуңа килеп терәлде ки, татар, мари, чуаш, башкорт, якут, бурәт, удмурт, мордва, Дагстандагы халыкларның телләрен һ.б., һ.б. ны саклаган очракта гына урыс теле дә сакланырга мөмкин. Урыслар шуны тизрәк аңласа, без дөрес юлда булыр идек, чөнки инглиз теле үзен генә бердәнбер телгә санап, дөньяга хуҗа дип хис итә башлады. Борынгы заманнарда латин теле шундыйрак форсатта булган, имеш: ә табигать бертөрлелекне һәрвакыт сөйми икән, латин теле җан тәслим кылган да, аның урынын бик күптөрле матур телләр алган... Менә ничек була икән бит әле ул... Бер карасаң, әллә ни искитәрлек нәрсә дә юктыр бу хәлгә. Империяләр җимерелә ич. Тел империализмы да, үз вакыты җиткәч, авып төшәдер.

Туган телебезгә мөнәсәбәтен КДУда укучы студент кызыбыз бик үзенчәлекле итеп белдерә: «Урыс телле мәктәптә укып чыкканнар ни өчен урам тулы наркоманнар булып йөриләр соң?» Бусы безнең көндәлек матбугатта басылганнан.

Татар мәктәбендә белем алу – балаларыбыз чит кавемгә әйләнде, әти, әни, ипи, тоз, ватан дигән иң изге сүзләрне дә әйтә белмиләр, дип, кабат-кабат тагын еламау өчен кирәк ул. Бу кирәклек модага иярү генә түгел, исәпкә-санга булсын өчен генә дә түгел. Безнең милләтнең каймагын, ягъни татар әдәбиятын, сәнгатен, тарихын белүчене, үз халкының психологиясен-холкын аңлый белүчене, башка халыкларга шул хакта күркәм итеп аңлатып бирүчене татар мәктәпләре һәм, билгеле, вузлары да әзерләп чыгарырга бурычлыдыр.

Татар мәктәпләренең мөһимлеге хакында сөйли башласаң, үзеннән-үзе югары уку йортларының юклыгына килеп терәләсең. Шунда бик кызык нәрсә ачыла. Ата-ана соравы буенча дип, татар мәктәпләрен бик тиз генә ябып куярга кодрәтләреннән килгән чиновниклар, шул ук ата-аналарның ничә еллар буе гозерләп үтенгән югары уку йортларын һич кенә дә ачып җибәрә алмыйлар... Кызык бит, әй!.. Кызганыч... һәм каһкаһәле көлке...

Чикләнгән дәүләтчелек кысаларында яшәвебез сәбәпле, мондый хәлдә татар җәмәгать оешмаларына тирләп-пешеп тырышырга кала. Чит илләрдә шушы җәмәгать оешмалары дигән төркемнәр дәүләтнең ярты эшен алып барышырга булышалар. Без бераз күбрәк белә башлаган Төркиядә дә шулай бу хәл. Анда иң матур, тарихи биналар җәмәгать оешмалары урнашкан урыннар. Сөйләүләренә һәм язуларына караганда да Американың (АКШ) бераз гына буш вакыты булган һәркеме җәмәгать эшендә катнашуын бер табигый күренеш дип саный икән. Әллә ничә баскычлы булып үтә торган сайлауларын да, нигездә, пенсионерлар җилкәсеннән үткәреп җибәрәләр икән.

Бездә җәмәгать оешмалары, милли хәрәкәт берәр революцион ситуация килеп чыга башласа гына активлаша. Бу мәсьәләнең безнең шартларда уңай чишелешен, безгә калса, ничек булырга тиешлеген һәм реаль, һәм уңышлы, һәм актуаль вариантын күптән түгел «Яңа гасыр» радиосында чыгыш ясаганда безнең күренекле җәмәгать эшлеклебез, үз юлыннан армый-талмый, уңга, сулга тайпылмый, темпны да киметмичә баручы танылган журналистыбыз Римзил Вәлиев: «Балаңны, оныгыңны татар мәктәбендә укытсаң, үзеңнең мал-мөлкәтеңнән хәлеңчә мохтаҗ кардәшеңә, ятим балаларга, картларга, мәктәп, мәдрәсәгә өлеш чыгара белсәң, милли хәрәкәт шушы була инде», – диде. Дөрес сүзгә җавап юк, диләр бездә, ягъни хаклык белән килешергә генә кала.

*2005*

**ХӘСРӘТЛЕ, КАДЕРЛЕ ЯЗМЫШ**

Безнең милләт, сәяси усал җилләр исә башлауга, килеш-кыяфәтне бик тә туры китереп, йокымсырау халәтенә күчә. Суверенитет сүзен әйтми башладылар икән, нишлисең, өстә беләләрдер. Татар теленең кулланышы ике аягына да аксый башлый икән – шулай ук җавап әзер: «Мин аксатмадым». Әйтерсең шанлы ел булмаган, әйтерсең, Бәйсезлек декларациясен кабул иткәч, шатлыктан елый-елый сөенмәгәнбез.

Күңелне шундый авыр уйлар баса башласа, мин Таулар бистәсендәге 10 нчы татар мәктәбенә кереп китәм. Анда җаныма – сихәт, тәнемә куәт алам. Көч тә кереп киткәндәй була. Анда рәхәт, анда тыныч тормыш, анда татулык, анда гүя бердәм бер тулы гаилә. Кечкенә генә бер малай (беренчеме, икенчеме сыйныф укучысы инде ул) шундый ук бәләкәй иптәшенә: «Әй, малай, әти белән балыкка барган идек, кәрәкәләрне каптырдык кына!» – ди. Тыңлаучысы да белгеч: «Һе, сезнең бакчагыз күл янында ич».

Кәрәкә дигән сүзне бәләкәйләр түгел, зурларыбыз да онытып бетергән иде инде. Малайларның матур сөйләшүен ишетеп, йөрәк шатлыктан рәхәт кысылып куя. Бу мәктәпне мин, тфү-тфү, күз

тимәсен, тынычлык иле дияр идем. Югыйсә бит яхшы беләбез, башка (катнаш) мәктәпләргә барып чыксаң, бәреп екмасыннар дип, коридорларыннан бик сакланып кына үтәргә кирәк.

10 нчы мәктәптә укытучылар да, теге мәктәптәге коллегалары кебек, йөзләренә борчылу билгеләре йә артык та эшлекле кыяфәт чыгарып, үзләре дә тыз-быз йөрмиләр. Яисә укытучылар бүлмәсенә җыелып, ләчтит сату гадәте дә юк. Алар күренмиләр дә диярлек. Алар һәрберсе үзләренең кабинетларында – сыйныф бүлмәләрендә тын гына, тыныч кына эшлиләр, тәнәфес вакытында да алдагы дәрескә әзерлек эшләре алып баралар. Катнаш мәктәпләрдәге шикелле, коридорлар буйлап нык чабышып (күбрәк очракта сугышып) йөргән малайларның (түбәнрәк класстагы укучылар булсалар, билгеле) берсенең якасыннан алып, икенчесенең кулыннан тотып аерганнан соң, кызарып-бүртенеп, соңга кала-кала, дәрескә килеп кермиләр. Ә зуррак малайларның янына якынрак килә дә алмыйлар ул катнаш мәктәп дигән җирдә. Куркыныч. Андый мәктәп ишегалдында, бигрәк тә мәктәпнең тәрәзәсез дивары артында ниләр була, анда беркем чыкмый да, карамый да. Анда исә иң «гади» эш тәмәке тартудан алып теге шикле үләннәр, дарулар, порошоклар – наркотиклар белән чуалу, кечкенәләрдән акча җыю, югары сыйныф укучысының берсенә өерелеп, ташланып кыйнау... Йөрәккә тия торган гамәлләр. Яннарыннан олылар, ата-аналар, әби-бабайлар, агайлар, яшьләр дә үтеп китә югыйсә. Бу хәлләрдән күңел елый, барысы да үзебезнекеләр бит.

Күңел тынычлыгы эзләсәң, үзеңнән-үзең 10 нчы мәктәпкә йөгереп барырсың. Тагын да, тфү-тфү, күз тимәсен, бу мәктәпкә Аллаһының рәхмәте иңгән, аның директоры Дания Гарәф кызы Шәмсетдинова – ягымлылык, сөйкемлелек, педагогик такт һәм сәләт иясе. Кычкырып, тон бозып сөйләшүнең ни икәнен белмәгән җитәкче булганда, нишләп укыту мөдире шундый булмасын, нишләп укытучылар башкача булсын? «Су баштан болгана, балык башыннан чери» гыйбарәләрен искә төшерүнең кирәге булмаганда нинди күңелле!

Сез бу мәктәпнең китапханәсенә керсәгез әле! Ул китапханә зур да түгел, китаплар да җитешми, билгеле. Ләкин анда һәр тәнәфес саен укучы балаларның баллы чәчәккә җыелган бал кортлары кебек мәш килүен, бер китапны тапшырып, шунда ук икенчесен алуын, китапханәче апаларының – Сания Кадыйр кызы Билалованың балалар белән гел елмаеп, яратып кына сөйләшүен күрер идегез.

Мин мәктәптә бераз эшләгән кеше. Район һәм шәһәр мәгариф бүлегенең алдынгылык буенча барча диярлек байракларын да үзенә җыеп бетергән мәктәпләрне дә белә идем. Ләкин эчтән караганда иң начар тәртип аларда иде. Теге елларда нәкъ шул мәктәпләр иң күп зәхмәтле «группировкалар»ны бирделәр. Ә хәзерге 10 нчы мәктәп гади генә бер уку йорты ул. Шул ук вакытта гади генә дә түгел. Ул безнең милли оазисыбыз.

Мондагы чараларның берсе – бөек шагыйребез Габдулла Тукайның 115 еллыгы уңаеннан татар теле һәм әдәбияты атналыгы кысаларында үткәрелгән «Хәзерге педагогик технологияләр: тәҗрибә һәм файдалану перспективасы» дип аталган фәнни-гамәли конференция иде. Бу конференциягә менә инде җиде-сигез ел буена 10 нчы мәктәпнең милли мәгариф буенча директор урынбасары Рәүфә Габдрахман кызы Хәйретдинова җитәкләгән «Яшь укытучы мәктәбе» тыңлаучылары чакырылган иде. Ә конференциянең фәнни җитәкчесе – педагогия фәннәре кандидаты, ТУБКИның татар теле һәм әдәбияты методисты Закирә Нури кызы Хәбибуллина. Ул бу эшне инде менә берничә дистә еллар буе алып бара. Татар мәктәпләре өчен нинди генә авыр елларда да, татар телен укыту бөтенләй ачы язмыш кулында калган чакларда да, ул татар теле укытучыларын ташламады, аларның бердәнбер диярлек яклаучысы, ярдәмчесе булды.

Әйе, татар мәктәпләре – безнең тамырларыбызның иң көчле үрентеләренең берсе. Моннан ун еллар элек исеп алган демократия җилләреннән яңадан терелә, тернәкләнә башлаганнар икән, мин шул милли оазисларыбызга бик теләп, яратып, сөеп барам. Менә әле 16 нчы гимназиягә «Карга боткасы» бәйрәменә чакыргач та чыгып йөгердем.

Мин 16 нчы гимназия тормышы белән бер дә диярлек таныш түгел идем. Ә элегрәк ул 3 нче гимназия булып эшләгән иде. Анысы минем күршедә генә булды. Ул елларда шул 3 нче гимназияне ачышуда хәлдән килгәнчә ярдәм итешеп, гәҗитләргә мәкаләләр язышып та (бер ишегалдында ике мәктәп икән, шуларның берсе татар мәктәбе булсын дип, Ходай Тәгалә үзе тәгаенләгән бит инде, дигән идеяне үткәрергә тырышып), ата-аналардан гаризалар җыешып та йөргән идем. Ул вакытта оештырылган ясалма киртәләрне татар мәктәбе дип янып-көеп йөрүчеләр бик яхшы хәтерлиләр. Соңыннан бу 3 нче гимназия өчен яңа бина төзелеп, Дубравная – Имәнлек дигән урамга 16 нчы гимназия булып күченде. 16 нчы гимназиягә – бәйрәмгә мине музыка укытучысы Рабига Сәлимҗан кызы Салихҗанова чакырды. Рабига ханым исә үзе 8 нче музыка мәктәбенең татар бүлегендә эшли, ә 16 нчы гимназия укучылары аңа музыка, җыр дәресләренә йөри.

Бәйрәмгә укучылар, ата-аналар җыйналган иде. Тамашаны татар музыка мәктәбенә дә йөрүче, әйткәнебезчә, 16 нчы гимназия укучылары әзерләгән иде. Бәйрәм кичәсе йоласына туры килгән җырлар белән бәйләп алып барылды. Бу бәйгедәге ягымлылыкны, матурлыкны әйтеп бетереп кара! Аны күрергә кирәк. Билгеле, ул бәйрәм бик гади кебек инде үзе. Яз җиткәнен белдереп, каргалар килә. Аларны балалар, әби-бабайлар, әти-әниләр ботка пешереп каршы алалар. Ләкин андагы тәрбияви

мизгелләр, теләкләр, әйтемнәр, җырлар, биюләр аша бала күңеленә шундый да яхшылык, кешелеклелек иңә ки, баланы янына утыртып, айлар, еллар буе яхшылык турында сөйләсәң дә, болай уңышка ирешеп булмас төсле. Шулай инде, табигатьне яратырга өйрәнгән бала (һәм зурлар да) башкаларны да ярата. Иң мөһиме – үзен дә ихтирам итәргә өйрәнә. Бүгенге көннең фаҗигасе – наркотиклар белән организмын агуламый, шәхесен юкка чыгармый. Аракы белән тәмәкене дә фәкать шулай – башкаларны һәм үзеңне хөрмәт итү хисеннән чыгып кына җиңеп булганы аңлашылса кирәк. Рабига ханым шул эшкә үзеннән өлеш кертергә тырыша. Шартлы рәвештә ясалып куелган матур өйчекләр янында торып, ул уен белән сиздермичә генә идарә итеп тора. Аның йөзендәге мимика-кичереш уйнауларын күреп, укытучының бу эш артыннан чын күңеленнән йөрүенә сөенәсең. Башкача булуы да мөмкин түгелдер, чөнки Рабига Сәлимҗан кызы татар мәктәбендә укучы балаларга музыка укыту турында еллар буе хыялланып, Киров шәһәреннән үк күченеп килгән ич!

Шулай итеп, бер яктан, безгә, Аллаһыга шөкер, дияргә нигезебез бар кебек. Болай әйтергә татар мәктәпләренең, инде бөтенләй бетте дигәндә, соңгы елларда янәдән тернәкләнеп эшли башлаулары мөмкинлек бирә сыман. Тик икенче як та килеп чыгып ята бит әле. Бу икенче як дигәнебез янәдән милләтләрне кысуга юнәлтелгән Рәсәйдәге яңа вазгыять. Безнең татар мондый вазгыятьтә йокыга киткәнгә сабыша һәм татар мәктәбеннән – үз мәктәбеннән йөз чөерә башлый. Бик тә кызганыч ки, моның гамәлләре инде сизелә генә түгел, күренә дә башлады. Безнең халык имеш-мимешне бик тиз ишетеп ала. Имеш, татар мәктәбендә укып, югары уку йортларына укырга кереп булмый. Тагын әллә нинди имеш-мимешләр. Кемнәрдер чыгарып тора имеш-мимешне, безнең халык ышанып тора. Татар мәктәпләрен, гимназияләрен тәмамлаучыларның йөз проценты диярлек югары уку йортларына кергәнлеген күрсәткән саннарга ышанмый безнең халык. Гәҗит-журналларыбызның бертуктаусыз шул турыда язып торуларына да ышанмый безнең халык. Татар мәктәпләрендә урыс телен дә су урынына эчеп, белеп чыгуларына ышанмый безнең халык. Кыш көне, тәнәфес вакытында урамга чыгып, кар ашап, сугышып йөрешләр булмаганлыктан, ягъни күркәм тәртип хакында, татар мәктәпләре һәм гимназияләренең берсендә дә грипп эпидемиясе чорында укулар тукталып тормавына ышанмый безнең халык. Һаман да, әлеге дә баягы, юк-бар имеш-мимешләргә ышана. Һәм, гомумән дә, милли дигән сүзгә битарафлык күрсәтеп, битарафлык битлеге киеп (хәтта ун ел элек кенә «Азатлык» дип кычкырып йөрүчеләре дә) үзләрен бик тә хәйләкәргә санап йөри башлыйлар. «Безнең халык үлгәнме, әллә йоклаган гынамы?» – дип тәфтишле сорау куйганда, хәтта бөек Тукаебыз да ялгышкан кебек тоела миңа кайчакта. Ул вакытта да бездә хәйлә-мәйлә булмадымы икән дигән шик туа. Безнең халык шуңа өйрәнгән, күрәсең. Бетә язу дәрәҗәсенә җитә дә, аннан (җае чыкса) тагын бер кузгалып, яшәү төсмере күрсәтеп ала. Яшәү принцибы түгелдер лә инде бу?

Шундый коллык психологиясе тормышыбызның төрле өлкәләрендә әллә нинди чагылышлар таба, йә тегеннән, йә моннан килеп чыга. Бер-икесен генә искә алыйк. Төрек әдәбияты әсәрләрен тәрҗемә итә башласаң, таныш булмаган һәр сүз дә гарәпнеке йә фарсыныкы булып чыга. Аны тыштан гына караганда һич кенә танып булмый, чөнки ул шулкадәр төркиләштерелгән-төрекләштерелгән (1917 елга кадәр, татар белән төрек даими рәвештә әдәбият алмашканда, билгеле, таныганнардыр, совет елларындагы өзеклек үз эшен эшләгән инде). Ярый әле патша заманнарында сүзлек төзүчеләр «тырышкан» – гарәп, фарсы дип билгеләп барганнар. Төрекләр гарәп һәм фарсының сүзләрен әрдәнәсе белән алып файдаланса да, аны үз орфографиясенә һәм орфоэпиясенә дә (әйтелешенә) яраклаштырып алган, теге халыкларның кагыйдәләренә төкермәгән дә. Без генә ул, колларча, үзебезнең телне вата-җимерә, гарәп сүзләрен дә, фарсы сүзләрен дә, урыс сүзләрен инде бигрәк тә шул телләрнең кагыйдәләре буенча кулланып ятабыз. Телне ярлыландыруның иң тайгак юлы бу хәл. Бездән кала дөньяда башка шундый халык булмас. Читтән кергән һәрбер яңа сүзне нормаль халыклар үз кагыйдәләреннән чыгып кулланалар – телләрен баеталар. Телләрендәге һәртөрле диалекталь күренешләрне дә диссертацияләр язып аерым бүлеп ятмыйлар – һәрберсен сөйләм теленә кертәләр дә шуның белән вәссәлам. Барчасына бер әдәби тел. Гарәп һәм фарсы сүзләрен, урысчадан кергәннәрен дә, шул телдәгечә иттереп, тырыша-тырыша әйттерү өчен, көчләп-көчләп чит авазлар кабул итми, «Әлифба»сына керттерми рәтле кеше. Төректә бер «г», бер «к», бер «х». Безнең хәтта татарча матур итеп сөйләгән дикторларыбыз да азаплана шул авазлар аркасында.

Бердәм халык үзен ни типтәргә, ни мишәргә яисә Әстерхан, Себер дигәннәргә дә бүлдерми дә, үзе дә бүлми. Чөнки мондый эшнең бик хәтәр нәрсә икәнлеген чамалый. Мондый хәлнең мәктәпләр эшендә зарары күплеген исбатлап торасы да юк. Шулай ук мәктәпләргә турыдан-туры кагылышы булган тагын бер нәрсә шәйләнә башлаган. Ул нәрсә дигәндә, соңгы вакытларда кайбер татар язучыларының да, кайбер чит халыктан күреп, әсәрләренә, Тукаебыз әйтмешли, «шактый ук оятсыз сүзләр» кыстырып язгалый башлавы. Бу күренеш яшь буын алдында җаваплылыкны нык тойган язучыларыбызны борчый. Шул уңайдан шагыйрә һәм педагог Эльмира Шәрифуллинаның атналык гәҗит «Татар иле»ндә басылган «Әдәпле әдәбият» исемле мәкаләсе бик гыйбрәтле. Язучы бүгенге яшь буынны чолгап алган мохитне әрнеп, нәфрәтләнеп сурәтли дә, бу очракта әдәпле әдәбиятның ролен өскә калкытып, басым ясап болай ди: «Әдәбият – эстетик фәннәр рәтенә керә торган сәнгать әсәре. Ә

сәнгатьтә матурлык – мәҗбүри. Димәк, безнең дә бер генә әсәребезне дә, әсәрдәге бер генә җөмләбезне дә ямьсез итеп язарга хакыбыз юк». Аллаһым сакласын, татар язучысы да мәгълүм халыкның «глобализация» дигән әле яңа гына үрә башлаган җәтмәсенә эләгеп, чәбәләнеп ятмасын иде берүк. Пәри башка, җен башка дигәндәй, безнең бурыч – хәлебездән килгән хәтле халкыбызны саклау. Татарның хәсрәтле язмышы башкаларга түгел, үзебезгә аңлаешлы һәм әле бик тә, бик тә кадерле дә. Чөнки хәсрәтле булса да, зур язмыш ул татар язмышы.

*2001*

## Ә БЕЗ ҺАМАН ЛӘМ-МИМ

«Әсәр язучылар үз әсәрләрен, гадәттә, киләчәк буыннарга бүләк итү вә аларга истәлек калдыру, аларның хәер-догасын алу максаты белән язалар. Без инде бу нигъмәтләрдән мәхрүмнәрбез...» Үзе әйткәнчә, «сынык күңел» белән шушы юлларны язучы изге галимебез һәм соңгы мөфти-хәзрәтебез Ризаэтдин Фәхретдин, ничек кенә аяныч булмасын, алдагыны дөрес күргән: үзенең вафатыннан соң алтмыш ел үткәч, нәшер ителгән алтын бөртегедәй кадерле китапны Казан урамнарында сатып алучыларга сузам – галимебез турында берни белмиләр, китапны кирәксенмиләр, мөфти дигән сүзнең ни-нәрсә икәнлеген аңламыйлар. Югыйсә Казанда ничәмә йөз мең татар яши бит. Бөек галимебез караңгы-канлы 37 нче еллар пәрдәсе аша безнең бүгенгебезне бөтен ачыклыгы белән күргән.

Бүгенге көндә бик тә әкәмәт хәл килеп чыкты бит: коммунизмны бетердек, бетерәбез дип, бүген үзләрен демократ санаучы кичәге коммунистлар тыз-быз чабышып йөргән булалар, демократия килде дип безне ышандырмак булалар, чынында исә, күзеңне ачыбрак карасаң, кемгә демократия, кемгә бетү килгән икән.

Менә мин фәкыйрегез дә бу юлларны һәр көнне радиодан иртәнге сәгать тугыздан балаларга атап башлана торган будда диненең бер сектасының «хари-хари, хари кришна» дип такмак әйтешкәннәрне ишетеп язып утырам. Аннан соң евангелистлар үзләренең вәгазь сүзләрен башлар, аннан – православныйлар, аннары еракта японнар шулай ук христиан дине турында тапшыру башлап җибәрерләр. Радио шул – бер. Мәскәүнеке. Татарның радиосы шуларның өйдәше генә. Шуңа күрә татар сүзе эфирга кереп чыккалар гына, ләкин күпчелек татарлар ул вакытта, Казан сөйли торган озын дулкынны өзеп, радиоларын кыска дулкынга көйләр...

Хәер, ул татарлар юкка куркалар, безнең дулкында дини тәрбия хакында бер сүз дә әйтмәсләр, гомуми мәгълүмат кына булса да бирмәсләр, татар телендә андый нәрсә булмас.

Бөек Тукайча әйтсәк, ниндидер кара көчләр, Рәсәй империясендә революция ясадык дип (эшчеләр һәм игенчеләр революция ясады дигән сүзгә инде хәзер беркем дә ышанмыйдыр, шәт), хәзер барыгыз да атеист буласыз дип, динне себереп юкка чыгарды, ә ислам диненең исә хәтта тамырын корыту өчен бөтен нәрсә эшләнде. Ә менә хәзер, халык дәһригә әйләнгәч, рәсми төстә коммунистлар Рәсәйдә һәм башка илләрдә юкка чыгарылгач, димәк, дин тотуга киртә рәсми төстә шулай ук юкка чыккач, ислам диненә каршы, элекке замандагы тәре походлары кебек, ачыктан-ачык дөньякүләм көрәш башланды: Гыйракны утка тоту, Сомалида террор үткәрү, Фәләстыйн, Ливанның җелегенә төшкән яраларын казып-казып чиләндереп тору, электәге Югославия дәүләтендәге мөселманнарны кырып бетерергә тырышу, Һиндстандагы мөселманнарны бертуктамый кысрыклап һәм һәлак итеп тору, Таҗикстанда, Азәрбайҗанда, Грузиядә (мөселман абхазларга каршы) ясалма сугышлар китереп чыгару...

Көрәшнең астыртыны да алып барыла: төрле секталарның дини-информацион терроры. Алда әйтелгәнчә, бу хәлләр белән ниндидер көчләр идарә итә, күрәсең, ә Ульянов-Ленин, Джугашвили-Сталин, Горбачев кебекләр гади үтәүчеләр генә. Шушындый уеннарга кайвакыт безнең татардан да кайберәүләр катышып ала. Шуларның нәтиҗәсе булып безгә дә Татарстан дигән җөмһүрият калды. Ләкин үзенең тарихында татарның шушы Татарстанлы чакта кысылган кадәр беркайчан да кысылганы булмаган әле. Ит югында үпкә дә тансык, дип тынычланудан ни файда! Хәзер инде максат та башка: ничек кенә булса да шушы җөмһүриятебез эчендә исән калырга тырышу... Габдулла Тукай, Дәрдемәнд, Садри Максуди, Гаяз Исхакый, Йосыф Акчуралар кебек фикерләүләрдән без мәхрүм инде...

Татарстанны дини секталарның (аларның берсе дә ислам диненә карамый!) оясы дип әйтеп була хәзер. Һәрбер кыйшайган коймa, һәрбер җимерек өйнең дивары ниндидер «изгеләр», «пәйгамбәрләр» белән очрашуга чакырган игъланнар белән тулды. Бу очрашулар чынында чукынуга өндәү, шунда ук чукындыру һәм хәтта шул «изгеләр» хакына үз-үзеңне һәлак итүгә чакырулар да була икән. Мәсәлән, «Белое братство» («Юсмолос») дигән оешма шундый гамәлгә өнди икән... Икенче бер евангелистлар оешмасы, Казанның Ласточкина исемендәге клубка урнашып, шулай ук мөселманнарга каршы эшләп ята икән...

Татарның яшь егетләрен кармакка эләктереп, христианга әйләндереп, шул ук вакытта мөселман битлеге астында җимерү эшләре алып бару өчен гарәп илләренә укырга да җибәрергә чамалыйлар икән... Җибәрерләр шул, Ласточкина исемен йөрткән клуб кисәгендә дә әфәнделәр долларга эшләгәч...

Әле менә җәһәннәм артындагы Яңа Зеландия һәм Австралиядә дә безнең өчен урыс телендә сөйләүче миссионерлар әзерләп ятканнар икән. Күр инде, гел безне кайгыртып яшәп яталар лабаса болар!

Беркөнне, шәһәр читендәге бакчадан кайтканда, кырык яшьләр чамасындагы татар хатыны белән сөйләшеп киттек. Киров исемендәге мәдәният сараена шул Яңа Зеландиядән килгән евангелистны тыңларга ашыга-ашыга кайтуы... Бик матур слайдлар күрсәтәләр икән, яшь бала белән килгән аналарның балаларын аерым бүлмәгә җыеп, карап торучылары да бар икән. Менә нинди уңайлыклар бит! Сез үзегезне мөселман итеп тоймыйсызмыни, дигән сорауга ханым менә болай җавап бирде: «Мин үземне мөселман дип хисаплыйм, тик менә ислам дине буенча шундый кызыклы вәгазьләр, лекцияләр укучы юк бит!»

Әллә ниткән дини секталарга кереп, өеннән качып йөргән балаларның аналарына: «Мәчеткә барыгыз, хәзрәтләр белән киңәшегез, ярдәм сорагыз», – дигәч, шул аналар мәчет, хәзрәт дигән сүзләрнең хәтта мәгънәсен дә юньләп төшенмиләр булып чыкты.

Без, гаеткә унбишәр мең кеше җыела дип, шатланып яши башлаган идек, карасаң, Казандагы калган меңнәрчә татарларыбыз ислам диненнән бихәбәр яшәп ята икән. Әллә безнең муллалар, хәзрәтләр, имам-хатиплар да, беркөнне йокыларыннан уянып, бөтен ишек-коймаларны тегеләр кебек игъланнар белән күмеп, мәчетләргә, мәдәният сарайларына меңнәрчә безнең халыкны җыярмы? Ай-һай, моның булуы икеле, була калса да, шәһәр башлыклары бу хәлне бик тиз белеп алып, кара тавыш чыгарырлар иде...

Ә менә җиде диңгез артыннан килгән миссионерлар бөтенләй таныш булмаган җирләргә килеп, шулай киң җәелеп китсен өчен монда аларны кемдер кочак җәеп каршы алырга тиештер инде... Бу секталарның җимергеч эшләрен хакимият күрми дә, ишетми дә. (Милли хәрәкәтнең әнә һәр адымын күреп, белеп, тикшереп торалар.) Югыйсә ул секталар безнең күпме гаиләләребезгә фаҗига китерделәр: иң әйбәт балалар ата-анадан читләшеп, тормыштан бизеп, хәйләле капкынга эләктеләр. Ни хикмәт, чара күрүче табылмый. Гомумән, читтән килгәннәрне без нигә үз эшебезгә тыгылдырабыз әле? Нигә безнекеләрне Франциянең яисә Англиянең эшләрен рәтләшергә дип бер дә чакырмыйлар соң? Йә бездә яшь шәһәрләр проблемасы буенча аурупалылар килеп киңәшмә үткәрә, яисә бу татарлар чынлап та мөгезле түгелме икән дип киләләр дә, аннан матур сүзләр әйткән булып, сынап китеп баралар.

«Рәсәйне ничек рәткә салырга?» дип әле бер Солженицын гына читтә бимазаланып, баш ватып ята иде, хәзер инде барча Америка, Аурупаның шул турыда уйлап башы авырта булып чыкты. Теге, элек КГБны, ягъни мәсәлән, Хәйдәр Алиевларны сүккән көнбатыш радиостанцияләре хәзер бөтенләй бүтәнчә сайрый башладылар. Алиев та бик шәп кеше, фундаменталист та түгел, гомумән дә, Азәрбайҗанны ал да гөл итәсе икән.

Шул көнбатыш радиостанцияләре үзләренең матбугатында басылып чыккан язмаларны тапшыралар, күзәтү ясыйлар. Ни борчый соң мәгърип халкын? Шул элеккеге СССР илләре, янәсе, аерым-чөерем (ирекле дип аңлыйбыз) яшәмәсеннәр, ә тагын да зуррак дәүләт – ниндидер бер Евразия составына керсеннәр. Үзбаш булып йөрмәсеннәр әле, көнбатыш демократлары күзәтүендә көн күрүләре мәгъкуль.

Әйтәм соң, федерализм мәсьәләләре буенча конференциягә килгән Аурупа вәкилләре, юристлар: «Сезгә тагы ни җитми инде, сез бит (татарлар) болай да инде Аурупада», – дигән кебек сүзләр әйттеләр. Безнең халык мондый очракта: « Төтене туры чыга агайның», – ди. Сез, әфәнделәр, ирекле булып рәхәттә яшәп ятасыз, безнең дә берничә йөз еллардан соң булса да шул ирекне татып карыйсы килә бит. Рәхәтләнеп туйгансыз, ахрысы, метрополия булып яши башласагыз, сез дә бик тиз барып төртелерсез. Бигрәк тә элеккеге СССР дигән җирләр белән бәйләнсәгез. Ерып чыга алмаслык урманчытырман ул...

Язам, язам, ә сүз башым бит татар мәктәбе иде. Ни хәл итеп тә булмый, татар мәктәбенең язмышы менә алда язылганнарга бәйләнгән инде. Урыс телендә чыккан дәреслекләрдә христиан диненнән мәгълүмат бирелә, ә ислам дине турында ләм-мим, безнең үзебезнең китапларда да ләм-мим.

Татар шулай инде ул, алданмыйм дигән булып, вак-төяктә откан сыман тоелып, олысында оттырып яши. Быел да татар ата-аналарының уптым-илаһи күпчелеге, татар теле дип тел чарлаулар вакытлыча булыр дип, балаларын тагын урыс мәктәбенә бирделәр. Кайберәүләр мәктәп юклыгын сылтау итә. Халкың бер сүздә булып, балаларыбызны татар классларына укырга бирәбез дисәләр, хакимият нишләсен – мәктәп биналары табыла ул. Татар хатыннары төзелештә эшләп, Казанда гына да ничәмәничә мәктәп төзеп бирделәр, үзләре төзегән үз балаларына да тиештер бит инде!

Һичьюгында урыс мәктәбендә дә татар балаларын беренче класстан өченче класска кадәр татарча укытып, аннан соң бер-береннән ерак тормаган (әле бер ишегалдында ике мәктәп очраклары да аз түгел) ике мәктәпнең берсен татар мәктәбе итәргә була.

Бөтен нәрсә үзеңнән тора, әгәр дә эчтә ныклык, оешканлык була икән, тышкы көчләр алай тиз генә җиңә алмый ул. Безнең халыкка бары тик бердәмлек кенә җитми, югыйсә ул табигате белән уңганбулган, аклыкны-паклыкны ярата, хәрам һәм ярамаган эшләрнең ни-нәрсә икәнлеген белә.

Милли хәрәкәттәге таркаулык, дошманлашып йөрүләрнең зыяны әйтеп бетергесез зур. Шуңа күрә сүз дә үтми. Бу бик күп нәрсәләрдә чагыла. Мәсәлән, Казан урамнарында күпме зат ыштансыз-күлмәксез дигәндәй хәшәрәтлек арттырып йөри – моны күрмәмешкә салышумы бу, әллә тәртипкә дә чакыра белмибезме? Хәтта шундый әшәке модалар чыгып торган көнбатышта да, ярым-ярты киенгән хатын-кызны фирма-предприятие хуҗалары «фирманың дәрәҗәсен төшереп йөрмәгез әле» дип, эш урынына кертмиләр икән.

Дин әһелләре бу турыда хакимияткә мөрәҗәгать итәргә тиешләрдер, чөнки шулай киенеп йөрүчеләрнең татар мөселман яшьләренә аздыргыч тәэсире әйтмичә дә аңлашыла булыр. Шул ук вакытта мөселман хатын-кызларына гадәттән тыш катылык күрсәтелсә, күренеп торган чәч бөртеге өчен дә тавыш купса, без дингә тартылучыларны арттыру урынына киметәчәкбез генә. Күпме еллар динсез булып яшәгәннән соң, тәртәне текә бору да ялгышлык булырга мөмкин.

Ни хәл итәсең, хәзер татарның язмышы татар милли мәктәпләренә терәлеп кала. Ләкин хәзергә исә бездә чын милли мәктәпләр юк дию дөресрәк булыр.

*1994*

# 4. Бакый сагыш

### ТАГЫН ДА ТАТАР ОПЕРАСЫ ХАКЫНДА

Әле ярый балалар бар. Менә бүген дә алар мине үзләре белән Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театрыбызга «Алтынчәч» операсын карарга алып килделәр.

Бу әсәрнең искиткеч гүзәл музыкага бай булуы белән бергә, анда карар нәрсә дә күп: опера халык иҗатына – риваять-дастаннарга нигезләнеп иҗат ителгән. Аның күренешләрендә күпме матур картиналар, җете манзаралар, халкыбызның күпме гореф-гадәте бергә тупланып бирелә. Либреттоны язганда әле яшь-яшь булган Муса Җәлил аксакалдай нинди олысымаклыкка ия булган.

Менә икенче алыпның – Нәҗип Җиһановның сихри музыкасы яңгырый башлый... Пәрдә ачыла... Тугзак ана ыруы яудан кайткан батырларны каршылый. Шатлык өстенә шатлык: Тугзак ананың кече улы Янбулатның хатыны Каракаш углан-малай тапкан. Тантана, бәйрәм. Матур музыка сихерли, ерак гасырларга алып китә...

Спектакльнең тамашачылары балалар дигән идем һәм балалар гына да түгел, ә аларның әти-әниләре, әби-бабалары да алар белән бергә. Ак яулыклы, ак шәлле әбиләрнең операга килүе гүзәл күренеш икән. Ничекләр генә итеп коткармадылар инде безне ак яулыклы әбиләребез, алар һәрчак алгы сафта...

Балалар арияләрнең сүзләрен-мәгънәләрен барысын ишетеп, барысын аңлап бардылар дип әйтергә дә теләмим, әмма бер генә мәртәбә дә кирәкмәгән җирдә кул чабу булмады, шулай ук кирәгендә алкышламадылар дип әйтергә бер сәбәп юк. Алкышладылар. Җырчы тавышының һәрбер матур борылышын, нотаның югарыга менеп зеңгелдәвен бер генә дә игътибарсыз калдырмадылар.

Берсеннән-берсе талантлырак җырчыларыбыз үзләренең матур аһәңнәре белән колакны гына иркәләп калмыйлар, ә күз өчен дә азык бирергә өлгерәләр – менә дигән иттереп, драма артистларыдай оста уйныйлар да. Карагыз әле бу Урмайга (хан киңәшчесе, Татарстанның халык артисты Айдар Фәйзрахманов) хан янында ничек кенә бөтерелеп йөри, дүрткә-бишкә иелә-бөгелә, ә үзеннән түбәннәр белән камчы телендә генә сөйләшә.

Менә бөтен залны күкрәк тавышы белән тутырып, татар булмаса да, саф татарча җырлаучы яраткан артисткабыз Галина Ластовка (Тугзак ана). Әнә йөзеп кенә йөрүче гүзәл Каракаш (Клара Хәйретдинова), Зилә Сөнгатуллина, Венера Ганиевалар кебек сайрап кына җырлаучы Разия Үзбәкова (Алтынчәч). Бәлки, аңа хәтле Җик партиясен башкаручыларның һәммәсеннән дә отышлырак, җылырак, матуррак һәм көчлерәк тавышлы Хәйдәр Бигичев. Һәрберсе драматургия кануннарын да төгәл үтиләр.

Менә тагын хан партиясен җырлый-җырлый инде үзе дә мәһабәт ханнар кыяфәтенә һәм яшенә кереп баручы Рафаэль Сәхәбиев. Чү, ханның моңсу матур ариозасын Рафаэль үзенең бик тә матур тавышы белән тагын да моңсурак җырлый түгелме соң? Әллә бу хан партиясен мин картайгач кем җырлар инде дигән гамьле сорау Рафаэль Сәхәбиевнең йөзенә үк чыкканмы?.. Чыннан да, менә егерме елдыр инде, мин «Алтынчәч»не, нигездә, шул бер төркемдә тыңлыйм. Билгеле, Бураш бабай партиясен башкаручы бердәнбер дип әйтерлек бас – калын тавышлы опера җырчыбыз Сәет Рәенбәков та шул чама җырлый торгандыр. Бу артистларыбыз шәп, сүз тидерерлек җир юк, ә яшь башкаручыларыбыз нигә күренми? Нигә яңа исемнәр юк? Кайда алар? Консерватория кемнәрне, нинди җырчыларны укытып чыгара соң соңгы елларда? Театр үзе кая карый?.. Җырчыларны китереп биргәнне көтәме? Әллә... килгәнен дә кире борып җибәрәме?.. Һәм безнең халыкны операдан биздерү, аны – татар операсын бүкәй итеп күрсәтү дәвам итәрме?.. Ә бит булган заман, сугышка хәтле үк йөргән безнең халык операга, Әстерханнан кадәр пароходка төялеп килә торган булганнар опера тыңларга. Ә Муса Җәлилнең көрәштәше Гарәф Фәхретдинов кебек, артист булмаса да, киң тавышлы солдат-егетләребез

Аурупа буенча концертлар куеп, татар операсыннан арияләр («Эшче» операсыннан һ.б.) җырлап йөргәннәр. Ә хәзер исә татар мәктәпләре, Аллаһы боерса, ныклабрак аякка басып эшләп китсәләр, бик күпкә артачак ул операны тыңлаучылар, аңлаучылар, яратучылар.

Опера спектакле башланганда, ничекләр генә җырларбыз икән бу ыбыр-чыбырга дигәндәй, шикләнебрәк караган сыман тоелган җырчыларыбыз залны аларның аңлавыннан һаман саен канатланганнан канатлана бардылар, артистларның кәефе үсүе залның иң аргы почмагыннан да күренеп, сизелеп торды. Ә тамашачы – нәниме ул, олымы – рәхмәтле: опера спектакле тәмамлангач, әкрен-әкрен генә пәрдә ябылмаса, алкышлар туктыйсы түгел иде. Рәхәт, җылы яңгыр астында тору бала-чагага ничек күңелле булса, алар спектакльне дә, мөгаен, шулай кабул иттеләр.

Менә уйлап утырам. Нигә, дим, иң яхшы Алтынчәч партиясен һәм Җик партиясен башкаручыларга аерым бүләк уйлап чыгармаска? Чит илләрдә, Мәскәүләрдә дә әллә ниләр кыланалар бит. Зилә Сөнгатуллиналар, Хәйдәр Бигичевләр, вакыт җәнапларын туктаткандай, бер югарылыктан төшмичә, биеклектә торалар ич, моны хәтта сукыр да күрә, алар тавышын саңгырау да ишетә, башкаларны әйтеп торуның кирәге дә юк.

Һәм тагын бер уй. Театрда композиторларны күрмәдем, әллә миңа гына очрамадылар. Ә бит «Алтынчәч» куелды! Безнең операбызның йөзек кашы! Шулай булса да, ул һәркөнне куелып тормый ич. Әгәр мин композитор булсам, акчасыз булмый дип, дөньялар авыр дип, зарланып тормастан, бөтен ыгы-зыгыдан качып, опера язарга утырыр идем. Алга ипи белән су гына куеп. Нихәтле темалар елап, безне кайчан күтәреп алырсыз, дип көтеп яталар. Без операсыз бернишли алмыйбыз: тарихи урыныбызны – Аурупа белән Азия арасындагы татар илен ташлап китә алмыйбыз бит инде! Аурупа дигәне опералы халыкны гына таный, ә Азиядән аерылырга җыенмыйбыз да, аның белән һәрвакыт аңлаша алырбыз, Аллаһы боерса. «Алтынчәч» операсын, «Шүрәле» балетын, мәсәлән, дөньяның теләсә нинди сәхнәсендә күрсәтсәң дә, аларны искиткеч якын итәрләр иде (үз вакытында «Шүрәле»не шулай кабул иттеләр дә). Костюмнарны тагын да җетеләтсәң, милли гореф-гадәтләрне бозмыйча, дөрес итеп, матур итеп күрсәтә белсәң... Билгеле, бу эшләргә тотыну өчен һәм, гомумән дә, татар операсын үстерү өчен турыдан-туры хөкүмәтнең, дәүләтнең иң беренче кешеләре катнашырга тиештер. Татарстанда спортны җанландыру нинди көч һәм дәрт, матди булышлык белән эшләнсә, бу өлкәгә дә (татар операсы, балеты өлкәсендә дә) шундый ук, хәтта аннан күпкә ныграк тырышлык белән кичекмичә, хәзер үк керешергә кирәктер. Ә нигә эшне элек куелган опера, балетларны яңартып куюдан башламаска? Ә алар бит аз түгел.

Һәм, әлбәттә, кайта-кайта, Нәҗип абый Җиһанов турында уйлыйм. Әйе, бик бай мирас калдырды ул безгә. Көчле, кодрәтле, талантлы һәм хакимиятле дә иде ул. Бар иде аның кулында хакимият. Шул хакимиятен татар операсы өчен эшләтте дә ул. Тик шунысын да истән чыгармаска кирәктер, уңышка ирешүнең юллары гомер-гомергә төрле-төрле булган. Хакимиятләр тирәсендә хәтта бөтенләй буталып йөрмәгән талант иясе дә уңышка ирешә. Андый мисаллар азмыни дөньяда? Дөрес, бу ил турында сүз барганда болай әйтү бәхәсле дә булырга мөмкин...

*1998*

**БАКЫЙ САГЫШ**

Һай ул безнең татардагы байлык. Рухи байлык! Мең еллыгын җыеп килүче «Кыйссаи Йосыф» диикме (әле шунысы да бар: шундый камил әсәр туган икән, димәк, болгар-татарның аңа хәтле дә мең еллаган әдәби-мәдәни тарихы булуы турында сөйли бу хәл) яисә колакка шанлы-яулы хәбәрләр җиткерүче, «янәдән тууы» – совет тыюыннан соң матбугатта басылып чыгуы белән үк безнең күңелләргә кереп утырган һәм халкыбыз тарихы турында сөйләүче «Идегәй» дастанымы, Бакырганилар, Сәиф Сараи, Мәүлә Колыйлар, Утыз Имәниләр, иҗтимагый-дини өлкәдә казганучы Курсавилар, Хөсәен Фәезхановлар, инде колакка чалына башлаган, элек «юк, булмаган алар» дип исәпләнгән төгәл фәннәрне өйрәнүчеләр-өйрәтүчеләр диикме, татарның тарих баганасын ныклап утырткан Шиһабетдин Мәрҗани хәзрәтләрен алыйкмы, бер генә дә истән чыкмаган Тукай белән Дәрдемәндне атыйкмы – болар әле безнең беренче иң якты йолдызлыкны хасил итүчеләр, безгә иң якын булып күренеп торган Җидегән йолдызлык кебек, ә татарның Киек Каз Юлы йолдызлыгы катлы-катлы галәм.

Яисә безгә вакыт ягыннан якынрак булган Ризаэтдин Фәхретдин мөфти хәзрәтенең әсәрләре һәм «Асар»ы буйлап күз йөгертә башласак?! Ул мәрҗән әсәрләрне укып эреп кенә китәргә була, хәтта ки үзеңне идиллик бер галәмдә яшим дип хис итәргә мөмкин. Күпме кешелеклелек, такт, нечкәлек, сафлык, изгелек галим мөфтиебезнең һәр сүзендә, һәр җөмләсендә. Гүяки бу әсәрләр патша Россиясенең халыклар төрмәсендә яисә совет иленең Сталин терроры вә ачлыгы елларында язылмаган... Беләбез, чынында галим түземлекнең үзе булган.

Дөньяви тормыш парадокслардан торгангадыр инде, татарның матди байлыгы җилгә очып кына торса да, аның рухи байлыгы туктаусыз өстәлеп тора, Ходайга мең шөкерләр. Мин бакый һәм гигант шәхесебез Бакый Урманченең графикасы, нәгыше вә уйма сыннарыннан тыш останың һәм остазыбызның хәзерге көндәге милләттәшләребезгә һәм дә киләчәк буыннарга да атап язган уй-нәсыйхәтләрен эченә алган хезмәтләрен, шуның белән бергә аның турындагы мәкаләләрне бергә туплаган китапларның дөнья күрә башлавын күз алдында тотып әйтәм. Менә ул китапларның кайберләре: «Бакый Урманченең рухи дөньясы». Өч телдә: татарча, урысча, инглизчә чыккан бу китапка оста турындагы мәкаләләр вә күпсанлы фоторәсемнәр, фоторепродукцияләр тупланган. Бу җыентыкны альбом-китап дип атарга да мөмкин булыр иде. Татарстан китап нәшрияты басмасы, 2005 елда чыккан. Икенче китап «Баки Урманче и татарская культура» исемендә. (Татарстан Фәннәр академиясе, «Фән», 2005.) Бу җыентыкның беренче бүлегенә шулай ук остаз турында истәлек мәкаләләре тупланган. Мәкаләләр тәрҗемә ителмичә оригиналда урысча һәм татарча бирелгән. Икенче бүлеге мәшһүребезнең үз әсәр-мәкаләләрен эченә алган. Язмалар гел туган телебездә. Бу китаплар белән рәттән «Татар эпосы. Дастаннар» («Раннур», 2005. 639 б.), «Татарский эпос. Баиты. Татар эпосы. Бәетләр.» («Фән» нәшрияты. 2005 ел. 545 бит). «Татар эпосы. Бәетләр.» («Раннур», 512 б.) җыентыклары дөнья күрде. Югарыдагы китап-байлыкларны барысын бергә атавымның сәбәбе – аларны бер үк кеше – Бакый Урманченең җәмәгате, фольклорчы галимәбез Флора ханым Әхмәтова-Урманче җыйган, туплаган (ә фольклор әсәрләре ифрат зур дәрәҗәдә фәнни эшкәртү дә таләп итә!), матбугатка әзерләгән, финанс ягын хәл иткән, акча эзләп тапкан... Бу фолиант дип әйтерлек китапларны, энә күзеннән үткәргәндәй әзерләп, барысын берьюлы, бер елда чыгару өчен физик, матди, гыйльми көч белән рәттән биниһая олы рух, җитлегү вә инанганлык-ихласлык кирәк. Ә фольклор әсәрләре моңа кадәр безгә танышларының өр-яңа вариантларын бирү белән гаҗәп дәрәҗәдә игътибарга лаек булуы белән бергә, яңалары өстәлүе дә тагын бер байлык...

Бакый Урманче бәхетле шәхес. Сталин чорының җәһәннәм-тәмугларын үтеп, аннан соң да репрессияләнгән кешенең кара шәүлә булып тагылып йөргән язмыш бәлаләрен кичеп, намусын, вөҗданын, оятын, акылын, талантын саклап кала алган шәхес. Рәссам кешенең иң тирән илһам чыганагы халык иҗаты икәнлеген сизенгән язмыш аңа, Казанга күченеп кайтканының соңында, үзе үк фольклорны гәүдәләндерүчедәй шул фәннең тирәнлегенә үтеп кергән галимә Флораны гомер юлдашы итеп биргән. Үзе бәхетле булу өстенә, ничәмә-ничә миллион туган халкын (һәм башка бик күпләрне дә) иҗаты белән бәхетле иткән кеше ул Бакый Урманче. 1956 елдан соң, аның Урта Азия якларыннан туган җиребезгә, Казанга кайта алуы да безнең өчен тагын бер зур бәхет. Кайта алмаска да мөмкин иде бит! Латыйф Хәмидиләр, Чыңгыз Әхмәровларның китү сәбәпләре тышкы яктан башкачарак кебек күренсә дә, чынында шул ук сөрген иде, ә менә алар кайта алмады. Әйдәгез, Бакый Урманчены чакырып кайтаручыга рәхмәт әйтик. Бу кеше ул елларда Татарстан хакимияте башында торган Салих Батыев. Нишлисең, бу кешегә рәнҗүләр дә күп булды кебек. Аның сәбәпләрен язучылар яхшы хәтерли. Әмма бер рәхмәт мең бәладән коткара, ди. Урманче өчен әйткән рәхмәт бу дөньядан кичкән кешенең рух-җанын шат итәр, бәлки. Барысы да Аллаһ кулында.

Бакый Урманче, чын бакыйларча йөзьяшәр булып яшәп, вафатыннан соң да бәхетле. Флора ханым кулы вә тырышлыгы белән аның иҗат мирасы бөртекләнә-энҗеләнә, халыкка ирешә. Аның рәсем-картиналарын, уймаларын карап бер хушланса, оста турында замандашлары язган истәлекләрне укып, үткәнне үзенә гел якынайтып торырга мөмкинлек тапкан укучы, оста-остазның үз язмаларын укып, искиткеч рух күтәренкелеге туплау белән бергә, Шиһабетдин Мәрҗанидән, Каюм Насыйридан, Габдулла Тукайдан, Риза Фәхретдиннән иңгән кебек акыл яктылыгы һәм хәтта тарихи аң да иңдерәчәк. Бу урында тарихи-этнографик аң-истәлеккә мисал итеп Бакый Урманченең «Сабантуй» исемле мәкаләсеннән бер мисрагны китереп үтү урынлы булыр кебек: «...Икенчесе: игенчелек культурасына караган һәм үзенә бер дөнья булган атамалар – киндераш үстерү, басасын, орлыгын аеру. Аннан җеп эрләү, баса ясап агарту, туку, сугу. Урын, стан, аның татарларга хас ясалышы. Күрек, кылыч, соса, тәбәлдерек, калдырча, әвернә, шүре, киләп кебек сүзләр. Кайчаннан бирле ул атамалар ясала башлаган?! Бу үзенә бер гыйлем бабы».

Халык тормышы, аның авыз иҗаты әсәрләре язма әдәбият өчен рух бирүче бетмәс-төкәнмәс саф чишмә ролен үтәгән кебек, моны тулысы белән рәсем сәнгатенә дә авыштырып куеп була. Бакый Урманченең бу хактагы ихлас ифрат кызыклы уйлары-фикерләрен укып, укучылар тагын бер кат хушланыр әле. Шул ук вакытта күпне кичергән, күпне күчергән (эшләгән), халкына күпне биргән шәхесләр барыбер әле тагын күпмесен үзләре белән дә алып китәләрдер, барысын әйтеп тә, әйтеп бетерерлек тә булмыйдыр... Әйдәгез, останың шул әйтелми калганнарын аның сәнгать әсәрләреннән үзебезчә эзләп карыйк...

Бакый Урманче үзенең нәгышь әсәрләрендә кайвакыт татар күңеленә бик тә ятышлы алсу, сыек яшел, яшькелт, саргылт, зәңгәрсу, ак төсләрне куллана. Бу бигрәк тә табигать күренешләрен рәсемгә төшергәндә, сабантуй күренешләрен сурәтләгәндә, «Печән базары» картинасында һ.б. да шулай. Бер сүз белән әйткәндә, идиллия. Гаҗәпләндергәне – «Туктамыш хан» әсәре. Бу әсәр дә алда аталган матур,

нәфис төсләр белән бирелгән. Уйлабрак карасаң, ул шулай булырга тиеш тә икән. Ханнарның уйламый кылган гамәлләре аркасында халык тарихи авыр язмышларга дучар ителсә дә, бу әле ханлы вакыт – татар халкының бәхетле чоры...

«Сөембикә» һәм «Сагыш» уйма сыннары.

Үткән гасырда, әле коммунистларның хакимияттә нык итеп утырган чорында ук, бераз уйлана торган татар кешесе шушы ике сәнгать әсәренең тәэсирен, ярдәмен тоеп та яшәде.

Сагыш «Сагыш»ка гына мулдан салынмаган, «Сөембикә» дә тоташ сагыштан тора. Сагыш, кайгы-хәсрәт, ләкин мескенлек түгел. Гаҗәптер, бу сәнгать әсәрләренә күпме иксез-чиксез дәрәҗәдә тирән уйлы сагыш диңгезе коелган, ләкин анда чагылдырылган геройлар үтә дә горур! Бик тә горур. «Сагыш»ка Хозыр Ильяс мәрхәмәтлеге, хакимлеге, акылы, кешелеклеге салынган булса, «Сөембикә»дә патшабикәләр чалымы һәм чагылышы, гәрчә аның бөтен вөҗүденнән йөрәк өзгеч зур югалту хәсрәте бөркелеп торса да. Ләкин ул әле яшь, горур, менә-менә башын күтәрер дә, күзләрен ачып, хакимнәрчә караш ташлар да үзенең хан боерыкларын бирә башлар кебек, әлегә ул үзенең иң серле бер бүлмәсендә, ялгыз калып, иң төпкелдә яткан, үзеннән-үзе яшергән гәүһәрдәй кыйммәтле уйларын уйлый кебек, безгә аңлашылган кадәресе: «Ничек болай булды, нигә бу хәл булды?» – дип ачыргалана төсле. Әйе, уйлары аянычлы, гаять тә аянычлы, күз астында түгәрәкләнеп-түгәрәкләнеп киерелгән нәни-нәфис мускуллар елавын тыеп торсалар да, калфагындагы энҗеләр менә-менә ачы күз яшьләре булып тамарлар кебек... Нинди олы хәсрәтләр бит, нинди олы! Дәүләт тажы хәсрәте!.. Үтәмеш Гәрәй хакындагы ачы хәсрәткә ничек түзмәк кирәк?!.

Безнең Сөембикә турында шыпыртын гына бер-ике сүз алышудан узмаган күпләребез хәтта исләренә кертеп чыгаруны инде 37 нче елларда ук оныттырылган халыкның Бакый Урманченың бу әсәрен музейга барып күрә, карый башлагач: «Ә-ә, Сөембикә!.. безнең патшабикәбез...» – дип әкертен генә теле ачыла башлады. Аның турында, язмышы хакында уйлана башладык. Соңгы патшабикәбезнең Казан чорын бераз өйрәнә, белә башладык. Ә менә әсир-тотык итеп алынгач, Явыз Иван белән бер-ике сөйләшүеннән вә көчләп Шаһгалигә кияүгә бирелүеннән гайре башка соңгы көннәре хакында берни белмибез. Хәер, кол булса да, аның баш имәве турында ачулы-ябулы гына бераз хәбәр бар кебек, башка берни юк. Күпмедер яшәгән бит әле ул! Аннан соң ни булган? Казанны алганнан соң, кирәге калмагач, Касыйм ханлыгын ашъяулыкны чүпләрен-валчыкларын каккалап-суккалап җыеп алган кебек, җыештырып куеп, хәтта тарих сандыгыннан да урын бирмәскә карар кылынганнан соң, халык калтырап төшеп уйлау сәләтен югалтканмы, әллә шулкадәр дә битараф булганнармы безнең кардәшләр? Сөембикә ханбикәнең соңгы көннәр хатирәләрен алар сакларга тиеш иде бит инде югыйсә. Яисә Казанга карата бөтенләй дә дошманлык хисе тоеп яшәгәннәрме? Анысы да булырга мөмкин, Мәскәү гаскәренә ияреп, үзебезнең ханны куябыз дип, юкка гына Казанны алышырга килмәгәннәр бит инде алар. Алданудан соң айну килдеме икән? Алдану ачысын булса да тойдылармы икән алар? Аңлап бетереп булмый, чөнки бүген дә «Шаһгали әтрәтләренә» басучыларны, «кирәкләре» чыккан саен «я!» дип алга атлап чыгучыларны күргәләп торабыз. Аллаһ сакласын!

1990 елларда Казаныбызда Шаһгали янында кем җирләнгәнен ачыклыйм, табам Сөембикәнең җәсәден, күчерәм Казанга, дип йөрүчеләр булды булуын. Кая ул, ике йөз процентка җиткән һәртөрле каршылыклар өстенә ул вәкилләребез дипломатия осталыгыннан да ерак торалар иде шул.

Менә шундый үзәк өзгеч язмышны күрәбез «Сөембикә» әсәрендә. Бөек оста – Урманче сәнгате уйлар диңгезенә сала.

Яисә «Сагыш»ка әйләнеп кайтыйк. Карагыз инде сез аңа иркенләп, бирелеп, курыкмыйча! Чөнки әсәр үзе: «Курыкмагыз, кешеләр, сагышланудан. Адәм баласының рухы шундый көчле, аңа ачкычны үзегез үк таба аласыз. Менә мин сагышлы, ләкин бирешеп, кәкрәеп төшкән мәллә? Юу-ук! Мин көчле, бик көчле, миңа әле тагын да тау-тау сагыш салынса да, күтәрәм. Сагыштан сафлана, чистара, яктыра барам», – дип, безнең белән бик тә үз итеп, яратып сөйләшә кебек. Чү! Үз гомерендә шулхәтле дә четерекле хәлләрне кичереп тә, йөзендәге мөлаем яктылыкны җуймыйча, йөз яшьлегенә килеп җиткән Бакый ага үзе карап тора ич «Сагыш»тан! Шулай да кичергән авырлыкларын «Сагыш»тан күреп була – ил агасының күз төпләрендә кара сагыш, тагын да дикъкатьлерәк баксаң, бу үзеннән дә яшергән кара күз яшьләре. Әмма «Сагыш» авторның үзе кебек үк мәрхәмәтле, аңардан ышаныч бөркелеп тора, бу ышанычлы караш үзебезнең туган халыкка төбәлгән, чөнки татар кешесенең байтагы бүген дә сагышның күзенә туры карап әңгәмәләшерлек хәлдә әле. Безнең тормыш сагыш бит ул. Туу белән үлем арасы.

Ләкин Бакый Урманче безне гел генә сагышлы халәттә калдырмый. Аның бик якты, чибәр, күңелле полотнолары да безгә мирас булып калды. Элеккеге «Печән базары»н чагылдырган рәсемгә генә күз салыйк. Анда тормыш нинди күңелле, матур, чуар. «И адәм баласы, синә хәтле дә тормыш кичкәннәр, кара, хозурлан, тарих киштәңә дә салып куй», – дип әйтә сыман әлеге рәсем. Рәссамның Идел буе ярларын тасвирлаган рәсемнәре дә безгә шулхәтле якын, үз...

Кайберәүләр инде менә ничә гасырлар «Аурупага тәрәз уябыз» дип ясканалар, ә безнең бөегебез, җаны ерак галәмнәргә күчкәч тә, үзенең бөтен тормышы, иҗат куәте белән татар халкына үз күңеленә тәрәз уярга риясыз рухландырып тора.

Бу уйланулар да бөек останың безгә калдырып киткән гүзәл хәзинәсенә әле бер тыелгысыз шатлану гына...

*2006*

**МӘСКӘҮДӘ ТАТАР АҺӘҢЕ**

Соңгы елларда Мәскәүдә татар сулышы, татар сәнгате-мәдәнияте үзен ныграк сиздерә башлады. Суверенитетыбыз шаулаган, яшәгән елларда Мәскәү яклары белән аралар ерагаеп-салкынаеп киткән заманнардагы безгә карата сәяси килешмәүчәнлек аркасында килеп туган сәяси «тынлык»тан соң барлыкка килгән аралашулар, бер яктан, элеккеге совет чорын искә төшерсә, икенче яктан, хәзер үзгәлек тә бар. Элек Мәскәүгә чакырулы гастролерлар – союздаш җөмһүриятләр вәкилләре беренче унлыкка кереп, автономияләргә сан җитми дә кала иде. Урысчалап әйтсәк, аларга – подмосткалар. Ләкин бу әле татарларга начар заллар, биналар бирелә иде дигәнне аңлатмый, биредә фикер, аң, караш, мөнәсәбәт лабиринтлары күз алдында тотыла… Мәскәүдә беркайчан да татарлар кечкенә-бәләкәй, билгесез залларга гына сыймады, алар кичә дә, бүген дә Кремль сарайларын да шыгрым итеп тутыра…

Хәзер Мәскәүдә вазгыять үзгәрде. Бүген биредә элеккеге союздаш җөмһүриятләрнең сәнгати эзләре юк дәрәҗәсендә, ул эзләрне яңа гына фани дөньядан бакыйлыкка күчкән бөек җырчы Мөслим Могамаев та алып китте, аны да Мәскәүдән Бакуга кайтарып җирләделәр…

Союздашлар булмагач, «Мәскәү сәхнәләрен үзләреннән кала кемнәр тутыра соң?» дигән сорау да туарга мөмкин. Чит ил вәкилләре кайный хәзер анда. Афишаларны яртышар ел алдан элеп куялар, концерт буласын белмәгән, күрмәгән кеше калмый. Бу уңайдан үзебездә булган бер хәл искә төште. Татарстаныбызның бер халык артисты белән бер районга концерт куярга баргач, мәдәният йорты директоры (безнең милләттән түгел иде) тарафыннан кулдан гына аннан-моннан яздыртып элдергән, карасы да кипмәгән кәгазь кисәге – афишаның бердәнбер экземплярын күреп шаклар каткан идек. Ә район халкы, белмәдек, хәбәр булмады, дип, озак вакытлар җырчыга үпкәләп йөргән…

Мәскәүдә совет елларында күпме сөйләп тә, Муса Җәлилгә куелмаган һәйкәл, ниһаять, октябрь аенда 1186 нчы татар этнокомпонентлы мәктәп ишегалдына куелды. Һәйкәл бюст дип күзалланса да, аны чын һәйкәл дип тә әйтергә була. Ул биек. Бөегебез күкрәктән генә түгел, бил тиңентен зур итеп сурәтләнгән.

Мәскәү сәхнәләренә хәзер татарлар да кирәк. Биредә сүз безне яраталармы, юкмы икәнлеге турында бармый. Татарлар Мәскәүгә кирәк. Элекке заманнарда да, Русия империясен төзер өчен, ярдәмчеләр сыйфатында татарлар кирәк булган… Читләргә дәүләт төзеп бирүчене татардан башка бүтән милләтләр арасыннан эзләп кара син, табалмассың…

Хәзер Татарстанның сәнгать коллективлары чыгышлары Мәскәү филармониясенең абонемент концертлары программасына да кертелә. Моңа чаклы булмаган хәл. Менә шундый ике концерт П.Чайковский исемендәге Зур концерт залында үтте. Беренчесе – Максим Скалозубов җитәкчелегендәге «Шарм» исемле шоу театры тамашасы. Бу бик зур коллектив: берничә төркем, аннан кала, төркем эчендә төркем. Яшь аралары да зур: кече яшьтәге мәктәп балаларыннан алып җиткән кызлар һәм егетләргә кадәр. Алар барысы да диярлек җырлый да, бии дә. Татарстанның суверенитеты куәтлерәк елларда бу коллективның шактый гына дәрәҗәдә татарлашканын күрергә мөмкин иде. Бәләкәй генә кызлар-малайлар да табаннарыннан ут чәчрәтеп татар биюләрен башкара иде. Хәзер программа нык үзгәргән. Урыс халык биюләре, дөнья халыклары биюләре күбәеп, шулар янына дөньядагы бүгенге ритмнар кереп кунаклаган. Шулай да ансамбль тәртип-тәүфыйкны югалткан дип әйтеп булмый, бер биюдә генә кызлар итәкләрен югарырак күтәрергә тырышты. Дөрес, алар барыбер да озынракыштан кигән иде…

Итәк дигәннән, шунысы кызык, урыс биюләрен башкарганда кия торган сарафаннар да өч-дүрт катлы балитәк белән тегелгән, кызларның башка күлмәкләре дә барысы да балитәкле… Безнең өчен бу фал яхшымы, начармы икәнлеген әйтүе дә кыен. Заманында татар Ширәмәт нәселләре, башкалары да, барып, безнең төньяк күршеләрне күлмәкле, сарафанлы, кафтанлы, итекле-читекле иткән, әмма соңыннан ул тарафлардан безгә рәхмәт сүзләре әйләнеп кайтмаган кайтуын…

Мәскәү программасына кертелгән ике татар номерын башкаручы егетләрне, кызларны да матур итеп киендергәннәр иде: ак ефәк күлмәкләр, өрфия яулыклар, кечкенә килешле калфаклар, егетләрнең кара түбәтәйләре «без татар» дип кычкырып торды. Чыгышларның берсе «Батыр егетләр һәм кошкызлар турында легенда» дип атала, ә икенче чыгышта кызлар биюе «Әни» дигән җыр фонында башкарылды. Чибәр кыз җырлады, исеме Алина, фамилиясе Лабаза… Шундый хәлләр. Шулай да кыз баланың татар икәнлеге кычкырып тора. Тавышы да матур.

Ниндидер репортерлар килеп, коллектив «Шарм» исеменә туры киләме, лаекмы, дип тә сорады. Лаек инде, лаек. Ут чыгарып бииләр, әйбәт җырчылары бар. Казанлыларны тамашачы бик яратты. Кечкенә балалары, укучылар белән килгәннәр, яшьләр, олылар да күп иде. Ни әйтсәң дә, дөньяның зур сәхнәләреннән берсе саналган Чайковский исемендәге концертлар залында чыгыш саен диярлек «Казан шәһәре, Татарстан җөмһүрияте» дип яңгырап торуы күңелгә рәхәт, горурланасың…

«Шарм» концерты 2 ноябрьдә булса, 4 ноябрьдә өр-яңа шатлык – шул ук залда Татарстан дәүләт симфоник оркестры концерты булды. Бу концерт бөек дирижер, оркестрның сәнгать җитәкчесе, милләттәшебез Фуат Мансуровның 80 яшьлек юбилеена багышланган иде. Маэстроның оркестрны мәһабәт гәүдәсе белән биек мәрмәр кыя кебек яклап-саклап торуына, бик тә гармоник рәвештә музыкаль әсәр һәм башкаручылар арасында берлек тудырып дирижерлык итүенә тамашачы ихлас сокланды. Концертның программасы, билгеле, дөнья классикасы әсәрләреннән төзелгән, анда Ж.Бизе, И.Брамс, П.Чайковский әсәрләре белән беррәттән безнең бөек композиторыбыз Р.Яхинның «Фортепьяно өчен концерт»ы да бар иде.

Бу концертка төрле милләт вәкилләре, классик музыканы яратучы тамашачылар җыелган иде. Р.Яхинны, Ж.Бизене, И.Брамсны, П.Чайковскийны тыңлап хушланырга, шул ук вакытта барысы да Ф.Мансуровка карап сокланырга килгән иде.

Татар халкы бертуктаусыз йолыккаланып торса да, талант ияләрен тудырып кына тора. Рөстәм Яхинның «Фортепьяно өчен концерт»ын да оркестр белән бергә татарның өр-яңа таланты Рэм Урасин башкарды. Бу яшь, уңган, мөлаем егетебезнең уйнавын дөнья тамашачылары бәһаләп өлгерсә дә, ул үзенең туган халкы улы икәнлеген онытмаска, ягъни алга таба да концерт программаларына татар композиторларының әсәрләрен дә кертәчәге турында вәгъдә биргән, иншаллаһ.

Бездә, татарда, үз эшенең остасы турында әйткәндә, ул йөзә, диләр. Рэм Урасин да фортепьянода йөзеп уйный. Андый башкаручыларның ун бармакны берьюлы егерме итеп уйнаулары өстенә төп көйче – йөрәк-күңел дә уйный. Аурупа меломаннары, Рэмны тыңлаганда, безгә Шопен кайтты, диләр икән…

Татарда элек тә шул фортепьяно дигән уен коралында йөзеп уйнаучылар бар иде, билгеле. Бу урында бер Марат Сираҗетдинов исемен атау да җитә. Ләкин, әлеге дә баягы, совет чорындагы аң лабиринтының зигзаглы караңгылыгы автономияләргә зур дөньяга чыгарга мөмкинлек бирми иде. Әмма татар тыңлаучылары Марат Сираҗетдиновка бик тә рәхмәтле, татар композиторларының әсәрләрен һәрдаим башкаручы булды ул. Хәзер дә шулай. Чит ил композиторлары әсәрләреннән техник яктан иң катлаулы саналганнарын да Марат бик оста итеп, яттан уйный.

Татар композиторлары әсәрләренең совет чорында актив башкарылуын да аерым билгеләп үтәргә кирәк. Бу елларда композиторларга матди стимул да булдырыла иде. Ә менә бүгенге кыргый капитализм чорында татар композиторларын еш кына эзләп та табып булмый. Рөстәм Яхиннар, Алмаз Монасыйповлар буыны бакыйлыкка күчте, сирәк үсентеләр булып калган берничә шәхестән гайреләре, гади көйчегә әверелеп, көн күреп ята. Яшьләр дә шул юлда. Еш кына чын композиторларыбызның ничек җан асраганын белүче дә юк… Чөнки хәзер әдәбият-сәнгать, совет вакытындагы кебек, хакимияткә хезмәт итәргә тиешле идеологик корал түгел инде… Хәзер бердәнбер идеологик корал – ул акча. Әмма шул идеологик корал рухи байлыкны аңлаучылар, бәһаләүчеләр кулында түгел. Әлегә. Шуңа күрә әдәбият-сәнгать мәрхәмәтле, аңлы татар байларының ярдәменә мохтаҗ.

*2008*

## МӨБАРӘК ТӘСБИХ ӨЗЕЛМИ

Моң дәрьяңның вәкаләте белән
Син милләтнең гаярь илчесе,
Канатында җырның ак татарны
Киләчәккә, алга илтүче.

Мин җыр тыңлыйм. Гүя мин җырны бер бинада түгел, ә урман ешлыкларында, чәчәкле болында, шаулап аккан елга буенда, хәтәр биек тау башларында тыңлыйм. Бу җыр карурманның үз шавы бугай. Бу җыр чәчәкле болында кояш нурларының йөгерешүе түгелме соң? Шаулап аккан елганың дәртле гөрелтеседер ул... Ә бәлки, биек тау башында шоңкарларның каң-каң итеп канат кагыну җиледер? Ә юк, бу җыр табигать бүләге генә түгел, аңарда татар халкының гасырлар буе йөрәгендә кайнап, үсеп, җыелып, сакланып килгән тетрәндергеч моңы яңгырый. Җырны мин табигать хозурлыгында йөреп түгел, гадәти бүлмәмдә тыңлыйм. Җырлаучысын да беләм. Ул – Татарстанның халык артисты, якташым Мирсәет Сөнгатуллин.

«Наласа авылы көе»н без Таһир Якуповның аңа гына хас өзгәләнеп җырлавында тыңларга өйрәнеп беткән идек инде. Бу көйне хәзер Мирсәет башкаруында тыңлыйм, тагын тыңлыйм, тагын кабатлап тыңлыйм, тыңлаудан туктап булмый. Чын татарча, милли җырыбыз «Кошлар кебек»не тыңлый

башлагач та, әле «Наласа»дан айнып булмый, җыр җибәрми, җырчының йомшак-моңсу, сызланучан тавышы йөрәкне айкый, ә «Кошлар кебек»тә чын ирләрчә горур, киң сулыш белән дөньяга матур аһәңнәр тарата, күңелгә бәлзәм индерә. Җыр агыла да агыла. Сихри «Галиябану»ны сихерләнгәндәй тыңлыйм. «Сагынам, дуслар» көен ничек уратып узасың инде? Уратып узмый, җырлый Мирсәет.

Сагынам, дуслар, сагынам, дуслар,
Сагынам туган илкәйне.
Илкәй белән бергә сагынам
Яшьли сөйгән иркәмне.

Шулай инде, борынгыдан килгән гадәт: сөйгән ярын жуя да татар үзәкләрне өзәрлек көй чыгара, газиз туганнарыннан, эти-әнисеннән аерыла да тагын моңланып гомер итә, бердәнбер илкәен дә ничәмә мәртәбәләр кулдан ычкындырган шул ук татар ич, бу хәлдә моңлану масштаблы, тирән, ярсулы. Бүгенге көндә дәүләтчелек төсмерләре булган Татарстаныбыз киләчәге өчен дә борчылып, уйланып, моңланып яши татар баласы. Бу яшәүне хәтта замана чуарлыклары, иләс-миләслекләре, төрле-төрле Иблис токымнарының сикерешепаздырырга тырышулары да, нигездә, үзгәртә алмый... алмас, Аллаһы боерса. Чөнки татарны татар итеп тотып торучы алтын баганаларыбызның берсе, татар тормышының төп байлыкларыннан берсе классик халык җырларыбыз бар. Ул җырларга җан өреп торучы классик халык җырчыларыбызның мөбарәк тәсбихе өзелми: буын артыннан яңа буынны – көчле-куәтле, бер үк вакытта моңлы тавышлы җырчыларны халкыбыз тудырып тора. Тәсбихнең бисмилласын әйтеп, Камил Мотыйгыйдан башлап, уртага Габдулла Тукайның үзен дә куеп (чөнки шагыйребез халкыбызның җыр хәзинәсен саклау турында иң беренчеләрдән булып чаң сугучы гына түгел, үзе дә әкрен генә көйләп йөргән), алга таба тәсбих төймәләрен шудырсак, Газиз Әлмөхәммәдов, Галия Кайбицкая, Сара Садыйкова, Мәрьям Рахманкулова, Гөлсем Сөләйманова, Габделхак Шаһиев, Шәфика Котдусова, Рәшит Ваһапов, Җәвәһирә Сәлахова, Фәхри Насретдинов, Рәйсә Билалова, Таһир Якупов, Габдулла Рәхимкулов, Азат Аббасов, Хәйдәр Бигичев, Илһам Шакиров, Әлфия Авзалова, җырчы сандугачыбыз Зилә Сөнгатуллина һәм халкыбызның классик җырларын, композиторларыбызның әсәрләрен башкаручы, бүгенге көндә иҗатының чәчәк аткан чорын кичерүче, гөрләп-шаулап торган, шул ук вакытта моңлы тавышлы Мирсәет Сөнгатуллин исемнәре калкып чыга.

Безнең борынгы җырларыбызның тарихын да бераз чамалап була кебек. Бик күп төркиләрне дә үзләренең яулап алу уенында катнаштырып алып килгән монгол ханнары безнең җирлектә тирмәләрен корып җибәргәч, җырчылары да шунда ук урнашкан дип уйларга кирәктер. Аларның җырлары-көйләре Кытай җирендә өч йөз ел буе династия тоткан сөн төркиләре алып чыккан аһәңнәр булган бугай. (Мәсәлән, Нәҗип Җиһановның борынгы көйләребезгә нигезләнгән симфонияләрен кытай көйләре белән чагыштырып тыңлап карарга була.) Бу көйләр гадәти көнкүреш җырлары да, героик әсәрләр дә булырга мөмкин. Ә менә безнең халыкның тормышы трагик вакыйгаларга баеган саен, шул көйләргә өр-яңа эчтәлек – сүзләр салына башлаган. Әле хәтта без дә күпме көйләрнең сүзләре алышыну шаһитлары булып яшибез. Музыка белгечләренең әйтүенчә, болгарлык чорында башкача җырулар җырланган диләр һәм алар шактый ук күтәренке рухтагы яңгыраштa булган, имеш...

Буласы булган, әмма татар җыр сәнгатен «Урман», «Озату», «Уел», «Су буйлап», «Олы юлның тузаны», «Эскадрон», «Тәфтиләү», «Шахта», «Хәмдия» һ.б.дан тыш күз алдына да китереп булмый. Тирән драматик, еш кына трагик лиризм белән сугарылган җыр җәүһәрләребезнең ничә гасырлар буе халкыбыз күңелен агартып, чистартып-пакьләндереп, рухландырып, киләчәккә өмет уятып яңгырауларыннан һәм башка бик күп күркәм якларыннан тыш (безнең җырларның эстетик югарылыгы үзе генә дә нинди югары бәһа тора!), тагын бер мактауга лаек сыйфаты бар дип хисаплыйбыз. Эш шунда ки, әйтик, Аурупа илләрендә опера сәнгате алга киткән. Опера уңышлы булсын өчен сүтелми торган драматургия һәм, иң мөһиме, төп герой, героиня башкара торган күңелне йә иркәләп, йә алгысытып-канатландырып, йә йөрәкләрне парә-парә китереп яңгыраучы бик тә матур аһәңле көй – ария кирәк санала. Йөрәкләрне айкап чыгучы, күңелләрне хушландыручы, искиткеч моңлы да, югары зәвыкка да ия булган «Гөлҗамал», «Сибелә чәчәк», «Каз канаты», «Зиләйлүк», «Хафизәләм иркәм», «Асылъяр», «Галиябану» һәм башка шундый бик күп классик җырларыбыз теләсә нинди операларны бизәп торырлык. Бу җырлар татар тормышында әйтеп бетергесез драматик, трагик хәлләрнең кайтавазы булып дөньяга килүен исбатлап торасы юктыр да. Болар безнең классик әсәрләр. Алар безнең операбыз да, симфонияләребез дә. Электән, борынгыдан яраткан безнең халык киң полотнолы, масштаблы әсәрләрне. Совет хакимиятенең беренче елларындагы демократия җилләренең уңайга исүе хәтта Әстерханнан ук, көймә-пароход җилкәннәрен киереп, татарларны Казанга хәтле үк татар операсын тыңларга китереп җиткерә торган булганнар. Яраткан безнең халык операны. Булган шундый заманнар – шул еллардагы матбугат теркәп калдырган. Безнең бүгенге операбыз да «Алтынчәч»тә туктап калмас, иншаллаһ. Күренеп торган һәм күренмәс кара көчләрнең басымы мәңге булмый ул. Тик бүгенге көндә хәтта гади эстрада сәхнәсен дә бөтенләй башка төрдәге җырлар басып алды. Бу инде атаклы Әлфия Афзалова һәм Илһам Шакиров иҗатлары чәчәк аткан алтын чор түгел. Җитди, көйле-

моңлы җырларыбыз ятимләнеп калды. Аларны башка җыр сыман нәрсәләр таптап, каплап китмәкче... Бүгенге көндә иректә баштан халык җыр җәүһәрләрен саклауны, яклауны, яшәтүне үз өстеңә аласың икән, берүзең эзлән, уйлан, юлын тап. Ә бүгенге көн, бүгенге заман ниндидер бер көчләрнең кеше күңеленең өрфия кебек нечкә оят пәрдәсен ертып, болгап-болгап пычракка атмакчы теләкләре белән характерлана бугай. Мондый хәтәр безнең халыкка да яный. Хәтта кайбер язучыларыбыз да зиначылыкны һәм кыек эшләрне генә эченә алган вакыйгалардан торган әсәрләр яза башладылар. Менә шундый заманда чәчәкле болындай бизәкле, киң кырлардай иркен тавышлы җырчыбыз Мирсәет Сөнгатуллинның булуы, үзенең иҗатын, нигездә, борынгы классик халык җырларын башкаруга һәм пропагандалауга багышлавы күңелдә бер җылылык, ышаныч хисе тудыра. Тик әйткәнебезчә, бүгенге көндә бу эшләрне алып бару ифрат дәрәҗәдә авыр һәм четерекле. Әмма ләкин чын егет кеше елап яшәми, җырлап яши. Җырлый Мирсәет. Зур-зур концерт залларын алырга аренда өчен акча җитми икән, дусларың, татар җыр сәнгате җәүһәрләренең кадерен, бәһасен белүчеләр ярдәмендә аудио кассеталар, компакт- дисклар чыгару дисеңме, музыкаль киоск хуҗалары озын көйләрне таратуга-сатуга чыгаруга ашкынып тормыйлар икән – аларны бу җырларның кадерен белүчеләргә бүләк итү – бушлай тарату дисеңме, эфирдан борынгы җырларыбыз хәзер еш яңгырамаса да, барыбер аларны студиядә яздыруны дәвам итү, сәнгать советы аша үткәреп, алтын фондка – саклауга тапшыру дисеңме – менә шундый гамәлләр белән янып-җырлап яши Мирсәет Сөнгатуллин. Аңа табигатьтән буй-сын, көч-куәт, егәрлек бирелгән, гүя Ходай Тәгалә: «Үз чорыңдагы читенлекләрне җиңәрлек итеп, камил яраттым мин сине, Адәм баласы», – дигән. Тормышның салкын җилләре өшетеп алганда да, кискен дулкыннар бәреп егам дигәндә дә югалып калмый җырчы, туктап ял да итмичә яңа көрәшкә ташлана. Бер җирдә концерт үзе теләгәнчә үк барып чыкмый икән, икенче сәхнәләр эзли, киң халык массасын элеккеге еллардагы кебек борынгы көйләребезне тыңларга җыеп булмый икән, таррак даирәдә иҗат итә. Заманасы шундый. Бигүк хаклы юллар белән килмәсә дә, безгә дә капитализм, аның да әле йөзе чәрдәкләнгәне, килеп ята. Ә капитализмда югары сәнгать салоннарга күчүчән, моннан һич тә котылып булмый. Безнең җырчыларның да гел хәерче генә булып та яшиселәре килмәскә мөмкин. Өстәвенә, алда күрсәткәнебезчә, безнең яшьләребезне дә, хәтта урта яшьтәгеләребезне дә әллә кайсы тарафларның юлларына кертеп җибәрүләре күз алдыбызда башкарыла. Ләкин барыбер, татар җыры өчен яну-көюләр аркасында бик яшьләй арабыздан киткән бөек җырчыбыз Хәйдәр Бигичев әйтмешли, чакырсалар, безнең җырчылар бәрәңге капчыгы өстенә басып та халык өчен бушлай җырларга әзерләр.

Мирсәет Сөнгатуллин борынгы классик җырларыбыз белән бергә хәзерге татар композиторларының әсәрләрен ир-егетләрчә яңгыратып булырдайларын сайлап алып яңгырата. Салих Сәйдәшев, Сара Садыйкова, Александр Ключарев, Илгиз Закиров, Сафьян Ибраһимов, Зиннур Гыйбадуллин, Фәрит Хатипов, Рәис Нәгыймов, Фәрзәнә Галиева һ.б. ның җырларын бик теләп җырлый. Җаны җыр белән тулгангадыр инде, сәхнәдә басып җырлаганда болын-кырларны әйләнә-әйләнә кайтып яңгыраучы көчле тавышы авызы ярым ачык килеш кенә ургылып чыга. Чыны – көе вөҗүденнән-йөрәгеннән ташый. Әйе, чынлап та Мирсәет моң иясе. Үзе дә матур-матур көйләр иҗат итә. Соңгы елларда Мирсәет Сөнгатуллинның сөекле җырчыбыз Зилә Сөнгатуллина белән икәү бергә дуэт җырлаулары да нур өстенә нур булды. «Моңлану», «Һаман яратам»ны тыңлаган саен тыңлыйсы килеп тора, ике ялкынлы йөрәкнең бер булып тибүедәй кабул итәсең җырны.

Мирсәет Сөнгатуллин тагын кемнәр белән иҗатташ дуслыкта соң? дигән сөальне бирсәк, иң беренче безнең күз алдыбызда баянчы Рамил Курамшин йөзе пәйда булыр. Сүзне Рамил бәйнең үзенә бирик әле: «Заманында мин Илһам абыйга баянда күп уйнадым, хәзер менә Мирсәет белән бергә эшлибез. Мирсәетнең халык җырларына зур игътибар итүе һәм зур осталык белән башкаруы сөендерә мине. Халык көйләрен уйнарга сусаган идем инде. Мирсәет һәр җырны җиренә җиткереп башкара. Зур талант иясе ул. Әле күптән түгел генә Мирсәет белән унсигез чын халык көен ике көн эчендә Милли мәдәни үзәкнең студиясендә яздырдык. Искитмәле темп һәм уңганлык! Халкыбызның милли рухы, тарихы озын көйләрдә ачыла. Мирсәет шул миссияне бик матур итеп үти. Хәзерге вакытта Мирсәет җырламаган татар халык көе калмады да бугай инде».

Уйга каласың. И безнең бөек татар халкы! Әйе-әйе, нинди генә драматик, трагик хәлләрне кичереп яшәсә дә, бөек ул безнең халкыбыз. Хәер, трагизмнар бөекләрне сагалап тора да инде. Халкыбыз үзе кебек булдыклы, талантлы улларын тудыра, үстерә тора. Иң кызыгы, татарның шундый улларын, кызларын, гадәттә, кечкенә генә татар авыллары бирә. Тукаебыз «нәкъ Казан артында бардыр бер авыл» дигәндәй, Мирсәет Сөнгатуллин да нәкъ Болгар артындагы Татар Борнае дигән авылда туа. Менә шул авылның болыннарында, кырларында, урманнарында җырчы кошлар белән ярыша-ярыша җырлап үсә ул. Олы дөньяга юлы шул авылдан чыгып китә дә Җир шарының татарлар яшәгән бик күп җирләрен җырлап урап чыга. Менә алар: Казан, Әлмәт, Чистай, Буа, Ульяновск (Сембер), Самара, Сарытау, Ырымбур, Уфа, Чиләбе, Ташкент, Тольятти, Төмән, Екатеринбург, Мәскәү, Петербург, Хельсинки, Истанбул, Иске шәһәр, Анкара һ.б., һ.б. Ләкин җырчыбыз бервакытта да үзенең чыгып киткән юл башын – туган авылын, туган Әлки – Болгар ягын бер дә онытмый, анда даим кайтып тора, якташларына җырлый, туган авылына багышлап җыр яза. Гомумән дә, Мирсәет Сөнгатуллин бик күп

авылларыбызга багышланган җырларны бик теләп, үзенең изге гамәл кылганын аңлап башкара. Чынлап та, мактауга лаек гамәл бу. Безнең бик күпләребезнең очып чыккан оясы – авыл, сайрашу сәхнәсе – Казанга шул оялардан җыелган татар балалары без.

...Күңелләрне айкап җыр яңгырый: «Эскадрон», «Хафизәләм, иркәм», тагын, тагын бик күп шәп җырлар! Мин горур! Чөнки җырлаучы – бу көннәрдә үзенең илле яшьлек алтын юбилеен билгеләп үтүче якташым, Татарстанның халык артисты Мирсәет Сөнгатуллин. Мин дә аны шигъри юллар белән котлыйм:

Килә бер көй кырлар, урман шаулап,
Әйләнепләр килә болыннан:
Йөрәк дәвалары ала халкым
Мирсәеттән – җырчы улыннан.

Моң дәрьяның вәкаләте белән
Син милләтнең гаярь илчесе,
Канатында җырның ак татарны
Киләчәккә, алга илтүче.
Галәмнең йолдызлары эчендә
Тылсымлы кояшы бар, ае...
Асыл җырчы бүләк иттең безгә,
И мөкатдәс Татар Борнае!

Туган ягың моң сакчысы булгач,
Горурлыгы артыр кемнең дә.
...Таң җилләре көйләп хәбәр сөйли:
«Бүген бәйрәм Татар илендә!»

*2003*

## МОҢНАР ҺӘМ УЙЛАР...

Музыкант булмаган кешегә башваткыч-ребус кебек күренгән билгеләр – ноталар үтеп чыкмаслык карурман, урман-чытырман яисә чүпләп бетерә алмаслык булып сибелгән йөзләгән-меңләгән мәрҗәннәрдән чигелгән гүзәл калфак кашыдыр кебек тә тоелырга мөмкин. Кара мәрҗән, ак мәрҗән. Татар кешесе музыка дөньясын шулай сихри итеп кабул итә.

Композитор Шамил Шәрифуллинның балет, симфония, оратория һәм башка әсәрләре язылган партитура битләрен ачкалап карап утырганда менә шундый уйлар туды; әле шунысы да бар, музыкант булмаган кеше өчен генә түгел, ә беркадәр музыкаль белемле, шул өлкәдә эшләп йөргән кеше өчен дә урман-чытырман ул катлаулы әсәрнең партитурасы, ә Шамил Шәрифуллин күбрәк нәкъ менә шул катлаулы симфоник музыка өлкәсендә иҗат итә. Бу уңайдан бер кызыклы «деталь»не күрсәтеп үтәсе килә: мәсәлән, композиторның тәмамлап килә торган «Йосыф-Зөләйха» балеты партитурасының бит исәбе инде... биш йөздән узып бара икән. Менә шундый мәрҗәннәр-сәйләннәр...

Шамил Шәрифуллин, чын һәм бик тә үзенчәлекле композитор буларак, 1975 елда үзенең «Мөнәҗәтләр» исемле хор өчен язылган концерты белән аваз салды. Бу хәлнең «мөнәҗәтләр» дигән сүзне әйтергә дә ярамаган елларда булганлыгын искә төшерсәк, без авторның гражданлык батырлыгын күрербез. Бу батырлыкның рухи кыйммәте тагын шунда ки, халыкның рухи байлыгына новаторларча якын килеп, моңа хәтле без ишетмәгән-белмәгән, әмма тарих төпкелләрендә, үткән чорлар тирәнлегендә яткан авазларны яңадан тергезүендә, катлаулы бизәкле монолит олы полотно хасил итүендә. Әсәрне Казан дәүләт консерваториясенең Семен Казачков җитәкчелегендәге хоры башкарды. Бу коллектив турында төрле кешенең төрлечә фикере булырга мөмкин, әмма шунысы да мәгълүм: бу хор үзенең олы хезмәте белән классик һәм киң полотнолы милли әсәрләрне башкарырга хакы бар дигән статусны яулап алган хор. Ул Казанда, Россиянең көчле музыкаль үзәкләре булган Мәскәү, Петербург һәм башка шәһәрләрендә, чит илләрдә дә концертлар бирә, ә «Мөнәҗәтләр»нең бу коллектив репертуарыннан төшеп калганы юк әле.

1976 елның көзендә «Мөнәҗәтләр» киң татар җәмәгатьчелеге өчен язучыларның Габдулла Тукай исемендәге клубында яңгырады. Бу концертка килгән кайбер иҗатчы алыпларыбызның исемнәрен генә санап китү дә күп нәрсә аңлата. Нәкый Исәнбәт, Бакый Урманче, Мөхәммәт Гайнуллин, Сибгат Хәким, Гомәр Бәширов, Гариф Ахунов, Әбрар Кәримуллин һәм башка бик күп атаклы язучыларыбыз, композиторларыбыз, артистларыбыз һәм, гомумән, бик күп музыка сөючеләребез белән Тукай клубы шыгрым тулган иде. Катлаулы биеклеккә, сихрилеккә, даһилыкка күтәрелеп иҗат ителгән һәм башкарылган, йөрәкләрдә яшертен вулкан булып кайнап яткан музыкаль көчнең шаулап бәреп чыгуын тыңлаучылар, көчле кул чабулар, «афәриннәр», котлаулар белән каршы алды; бу хәл халкыбызның

борынгы музыкаль байлыгының иреккә чыгуы кебек кабул ителде. Хөрлеккә, азатлыкка, үткән бөеклекне аңлауга зур бер адым иде ул. Әнә шундый чыгышлардан соң, мөнәҗәт жанры турында авыз тутырып сөйләү гадәткә кереп китте; музыка белгечләре дә бу юнәлештә эшли башладылар.

Шамил Шәрифуллинның икенче бер әсәренең – инструменталь триосының (автор аны әбисенә багышлый) премьерасы шаһиты булырга туры килгән иде. И.В.Әүхәдиев исемендәге музыка училищесының концерт залы, тыңлаучылар белән шыгрым тулы. Бусында тамашачылар арасында Фасил Әхмәтовның, Ренат Еникеевның, Мирсәет Яруллинның, яшь композиторлардан Шамил Тимербулатовның, Разия Еникееваның, Фәрит Шәрифуллинның һәм башка урта буын композиторларның, консерватория һәм училище студентларының булуы күзгә бәрелеп тора иде. «Трио»ны бик тә билгеле башкаручылардан Әлфия Бурнашева (фортепиано), Гөлфирә Сафина (виолончель) һәм Фәридә Закирҗановадан торган состав уйнады. Ул кичне залда, тыңлаучыларның күңелләрен актарып ташлап, кара урманнарда йөрткәндәй алгысытып, кояшлы аланнарга алып чыгып, шатландырып, тагын да диңгез төпкелләренә чумдырып, сихри моң яңгырады; ниһаять, сулыш бетә дигәндә генә аннан тартып алып, әкрен генә соңгы аккорд сүнде... Тыңлаучылар бермәл айный алмый тордылар; залда (беркем юк диярсең!) берничә дәкыйка секундка гына тирән тынлык хөкем итеп алды; аннан – эссе мунча ташына кайнар су сиптеләрмени – өермәдәй кул чабулар, алкышлар башланды... Бу – олуг сәнгатьнең тантана итүе иде.

Мәгълүм ки, һәрбер иҗат өлкәсенең үзенә генә хас үзенчәлекләре бар: язучы, әйтик, иҗат җимешен китап нәшер итеп укучысына ирештерергә тырыша, композиторга исә хезмәтен күрсәтү өчен музыкантлар һәм тыңлаучылар кирәк. Шул рәвешчә, 1983 елда тамашачы-тыңлаучылар Казан дәүләт консерваториясенең зур концертлар залына җыелды, бу юлы Шамил Шәрифуллинның «Җыен» исемле әсәре – зур симфоник оркестр өчен язылган концерты башкарылачак иде. Гадәттәгечә, авторның иҗат принципларына хас булганча, әсәр музыка теленең яңалыклары, новаторлык рухы белән сугарылган иде; халык җанының – сабан туеның гүзәл бизәкләре, картиналары музыкаль авазлар белән шундый да оста тасвирланган ки, әйтерсең лә син кешеләр һәм урындык-креслолар белән шыгрым залда түгел, чәчәкле болында таллар-куаклар, зифа каеннар арасында туганнарың, якыннарың белән тамаша карап-тыңлап утырасың... Соңыннан бу «Җыен» концерты турында да матбугатта матур-матур фикерләр әйтелде.

Шамил Шәрифуллин иҗаты турында сүз алып барганда, аның җыр өлкәсендәге уңышларына күз йомып үтсәк, бу гөнаһ булыр иде. Ул җыр өлкәсенә дә яңалык алып килгән композитор. Биредә композиторның бу өлкәдә дә яңача музыкаль «телгә» ия булуын ассызыклап билгеләп үткән хәлдә, тагын бер нәрсәне дә искә алып китәсе килә. Сүз «Сабан туе» белән «Син биергә мине чакыр» җырлары хакында бара. Шамил Шәрифуллинның «Сабан туе» җыры туганчы, безнең атаклы бу бәйрәмебез турында халыкныкы булып канунлашкан, «Сабан туе хезмәт туе, бәхет һәм шатлык туе» дип башланып китә торган җырыбыз гына бар иде кебек. Хикмәти Хода, композиторның сабан туе хакында язылган җырыннан соң, бу темага байтак яңа җырлар туды. Бу яңа җырлар, бигрәк тә сабан туе бәйрәме көннәрендә, бер-берсе белән ярышып яңгырыйлар хәзер. «Син биергә мине чакыр» көе белән дә шундыйрак хәл булды. Моңа чаклы күрелмәгәнчә, биергә чакырган төрле-төрле җырлар барлыкка килде, хәтта бии белмәгән кешеләр дә биергә өндәлә, чакырыла башлады, чынлап та, халык әйткәнчә – «биючегә сүз әйтмәгез, бии-бии остара».

Сибгат абый Хәким Шамил Шәрифуллинның үзенең шигырьләренә җырлар иҗат итүеннән бик канәгать иде. Атаклы шагыйребезнең «Йөгерә чәчәкләр» исемле шигыренә язылган лирик-романтик характерындагы җыр бөтенләй сүрелгән күңелгә дә яшәү дәрте өрерлек көчкә ия, ул яшәү учагын кабызырлык өметләр уята ала. «Әйлән-бәйлән» көенә дә шагыйрь югары бәһа бирде. Кешеләрне бер-берсенә карата игътибарлыкка, мөлаемлыкка, дусларча бердәмлеккә чакырган бу җырларны безнең җирлектәге бүгенге адәм баласына ишеткәләп тору бер дә зыянга булмас иде югыйсә. Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле солисткасы Флүзә Җәләлова «Сөембикә» журналында әйтеп үткәнчә, «хәзер күбрәк кан саркып торган яралы җырлар яңгырый... җырда сер калмады».

Композиторның шагыйрь Равил Фәйзуллин шигыренә иҗат иткән «Иясез шатлык» җыры да аерым игътибарга лаек. Бу җыр бик тә үзенчәлекле тавышка ия булган Регина Сәйфи башкаруында күңелләргә тирән эз салды, аның трагик яңгырашлы тавышы йөрәкне уеп-уеп ала.

Композиторның «Яфрак төшкән инде юлга» исемле әсәрен алыйк. Бу көйне үзәкне өзәрлек моңсу булганы өчен генә түгел, ә бәлки, якты моңсулык, яктылык биргәне өчен, гүяки көзге ак каеннар арасында, кул болгап, канат җилпеп йөрүче көзге якты рух өчен дә ярата лар.

Гомумән, Шамил Шәрифуллин иҗатына контрастлар хас. Фәлсәфи-дини эчтәлекле «Мөнәҗәтләр» циклыннан соң ул яп-якты, үтә дә нәфис, мәхәббәт лирикасы белән сугарылган «Авыл көйләре»н халыкка тапшырды. Бу юлы да иң беренче булып җырларны Казан дәүләт консерваториясе хоры башкарды, хормейстеры Нурия Жураева иде. «Авыл көйләре» дә «Мөнәҗәтләр» кебек үк Татарстан радиосы фондына язып алынды.

Шулай, Ш.Шәрифуллин иҗаты бертөрле үлчәү калыбына гына сыймый. Шәхес буларак, ул тирән белемгә вә бай энциклопедик мәгълүматларга ия. Мәскәүдә аспирантурада укыган елларында аңа Америка индеецларының халык җырларын тыңларга туры килә. Тарихи-географик хата аркасында индеецлар дигән гомуми исем белән аталып йөрүче, чынында һәрбер кабиләнең үз атамасы булган (науа, майя, кичуа һ.б.) халыкларның көйләре төрки халыклар теленә бик якын булуына ул шунда игътибар итә. Ә кайбер көйләре исә хәтта ки «Мөхәммәдия» китабы көйләре белән авазлаш булып, җырларының сүзләре арасыннан «ана», ата», «тау», «ак», «атау», «алып» һ.б. сүзләр аңлашылып тора икән. Менә шуннан соң композитор бу халыклар турында мәгълүматлар эзли башлый. «Латин Америкасы» дигән журналдан вә башка чыганаклардан шактый кызыклы материаллар табыла. Татар халкының «Чикамыш» (җыр «Чикамыш» дип калыпланса да, сүз «чыгу» тамырыннан, кияүгә чыгу мәгънәсендә) туй җыры текстына бик нык авазлаш җырларын да таба. Сүз уңаенда тагын бернәрсәне искәртеп китик: композитор татар халкының бик борынгы чорындагы яшәеш-тормышына, бигрәк тә музыкага караган хәзинәләрне үзе табарга, алар турында академик дәрәҗәдә мәгълүмат булдырырга тырышучы кеше. Һәм... төрки-татар белән Америка индеецлары көйләре уртаклыгын ачу белән рухланып, «Чәчәк турында җыр» исемле балет музыкасы яза. Соңыннан, академик Әбрар ага Кәримуллин белән танышып, үзенең фикерләре белән уртаклашкач, язылган әсәре турында да хәбәрләшкәч, бу өлкәдә (Америка индеецлары вә төрки-татар уртаклы мәсьәләсендә) шактый эзләнүләр алып барырга өлгергән галим йөзендә үзенең теләктәшен вә фикердәшен таба, тик ...балет партитурасы композиторның өстәл тартмасында кала бирә. Балет кадәр балетны безнең шартларда кузгатып җибәрү, сәхнәгә куйдыру – ай-һай! Авыр шул. Чөнки үзебезнеке булып саналган, Муса Җәлил исемен йөрткән опера һәм балет театры җитәкчелеге гомумән дә безнең композиторларның әсәрләрен сәхнәләштерү турында мәсьәлә кузгалгач, калын бронялы битараф калканга әйләнә. Шамил Шәрифуллинның башкаручысын көтеп яткан башка әсәрләре дә байтак. Моның сәбәбе артык серле түгел, бүгенге көннәрдә хәтта бер җырны халыкка чыгару өчен дә автордан (!) шактый күләмдә акча таләп итеlә. Менә шундый аптыраулы мәсьәлә...

Шамил Шәрифуллин контрастлар белән эш итәргә яратучы шәхес дигән идек. Композитор хәзерге музыка-көйләребезнең болгар бабайларыбыздан калган тамырларын шактый өйрәнгән кеше. Ул – магнитофон күтәреп, авыл-шәһәрләр буенча йөреп, халык авыз иҗатын җыеп та, теоретик яктан нигезләп тә, практик эшкәртеп тә, шул чордагы музыкаль картинаны күзалларга тырышучы галим-композиторларның берсе. Болгар чорындагы музыка үлчәм-метрикасын хәзергедән, татар-кытай-япон яңгырашлы үлчәмнән, шактый аермалы булган дип саный ул. Әйтик, бер генә мисал. Ул әнием ягыннан туганым – туганый апам, инде мәрхүмә Мәгузәдән (Болгар ягы кешесе) язып алган мөнәҗәтләргә хәзерге Болгариянең борынгы халык җырлары үлчәмнәренең туры килүен үзе шул илгә барып өйрәнеп кайта. Шул өйрәнүләр, экспедицияләр нәтиҗәсе буларак, «Болгар моңнары» дигән ун кисәктән торган цикл туа. Бу көйләр, әгәр музыка турында шулай әйтергә ярасa, өрфия кебек үтә күренмәле нәфисләр, гүзәлләр, күңелләрне бизи, сафландыра, ерак-еракларга да һәм үз күңелең төпкелләренә дә чакыручылар дияр идем. «Болгар моңнары» да Татарстан радиосы аша эфирда яңгырый.

Агымсу бер урында тормый, ага да ага ул, ә иҗатны мин агымсу белән дә чагыштырырга мөмкин дип саныйм; шул рәвешчә композитор Шамил Шәрифуллин да хәрәкәттә – иҗатта. Менә ул инде берничә ел, тирләп-пешеп, яңа балет – «Йосыф-Зөләйха» әсәрен яза. Миңа әсәрнең кайбер фрагментларын тыңлап карау бәхете эләкте. Искиткеч аһәңнәргә бай музыка; биредә Синай атавы, Мисыр һәм Мавритания һ.б. әкияти илләрнең сихри музыкасын, татар-төрки пентатоникасын – берсен дә чит күрмисең: бер сүз белән әйткәндә, әсәр катлаулы синтезга ия. Бөек шагыйребез Кол Гали, эзләнүчеләрнең фикеренчә, дүрт мең еллар чамасы вакыт ераклыгындагы көньяк илләрендә әкияти дә, чын да булган һәм җетелеге белән илаһи рәссамның бик зур форматтагы фантастик картиналары сыман, күңелне үзенә магниттай тартып торган вакыйгаларга шигъри сүз белән мөрәҗәгать иткән шикелле, балет та шул җирлектәге музыкаль культураны исәпкә алып иҗат ителә...

Әйе, чын иҗатчының иҗат колачы киң, күптармаклы. Шамил Шәрифуллинның Казан дәүләт консерваториясендә, музыка мәктәпләрендә педагоглык эшчәнлеген истә тоткан хәлдә (танылган композитор Риф Гатауллин, композитор һәм дирижер Рөстәм Абязов, яшь композитор Илһам Байтирәк аның укучылары), музыкантыбыз иҗатының тагын бер тармагына игътибарны юнәлтәсе килә. Сүз – композитор хезмәтләренең китап булып дөньяга чыгуы хакында. Композиторның җырлары тупланган беренче китабы 1984 елда Татарстан китап нәшриятында басылып чыккан иде. Инде берничә дистә еллар буе Ш.Шәрифуллин халык җырларын җыю, нотага салу, эшкәртү, аңлатмалар, искәрмәләр, кереш сүз язу һәм матбугатка яңа китап итеп тапшыру эшләре белән шөгыльләнә. Шуларның берсе – тугыз йөз битле «Урта Идел буе татарларының җырлап уку традициясе» кульязмасы 1992 елда ук нәшриятка тапшырылган. Әмма бүгенге көннәрдә андый кульязмаларның юллары озын, китап булып чыгу вакытлары билгесез...

Шулай да, Ш.Шәрифуллин кул кушырып утыручылардан түгел, 1994 елда «Борынгы халык җырлары» дигән икенче бер, юка булса да, зур форматлы китап дөнья күрә. «Мөхәммәдия» китабы көйләре, «Сак-Сок» бәете, мөнәҗәтләрнең кайберләренең көйләре, «Йосыф китабы» көе, «Шәһри Болгар бәете» көйләрен эченә алган китап Казан дәүләт консерваториясе белән бергәләп чыгарылган. Ә менә «Сак-Сок» бәете, матур рәсемнәр белән бизәлеп, Татарстан китап нәшриятында күптән түгел генә дөнья күрде. Композиторның «Татар халык музыкасы. Балалар музыка мәктәпләре өчен программа» китабы да аерым әйтеп, тукталып үтүне таләп итә. Гомумән, татар мәктәпләре, музыка белән кызыксынучы һәркем өчен дә бер хәзинә дип атап була ул программаны. Композиторның шундый хезмәт куюын чып-чын патриотизм дип исәпләргә кирәктер, чөнки моңа чаклы андый киң колачлы программаның төзелгәне юк иде әле. Программадагы берничә теманы гына күрсәтеп үтик. «...Татар халык музыкасының үзенчәлекләре. Аның башка халыклар музыкасыннан аермасы. Милли моң, ритм, формалар шәкелләшүенең озакка сузылган тарихи юлы. Халыкның аеруча яраткан образлары, темалары, сюжетлары. Кешене тумыштa чолгап алган жанрлар. Азан һәм мәҗбүри гыйбадәт догалары. Бишек җырлары. Практик юнәлешле уен җырлары (такмаклар, әйтемнәр һ.б.). Мәктәп җырлары. Шәкерт җырлары. Коръәнне көйләп уку. Хезмәткә бәйле музыкаль фольклор. Яшьләрнең уен һәм әйлән-бәйлән җырлары. Балаларның күмәк музыкаль уеннары. Татар халык музыка уен кораллары. Халык бәйрәмнәре. Татар халкының эпик лирикасы...» һ.б., һ.б. әнә шундыйлардан.

Хәзерге вакытта композитор бу программа буенча дүрт китаптан торган «Татар халык музыкасы антологиясе»н төзи.

Башыңа төшсә, башмакчы буласың, ди безнең халык, алда атап кителгән, дөнья күргән китаплар өчен һәм балет өстендә эшләү мәшәкатьләренең кайберләрен күтәрешер, ярдәмләшер өчен дә спонсорлар эзләргә вә табарга туры килә. Ул аларга чиксез рәхмәтле.

Рәхмәтләр әйтүне искә төшердек икән, Шамил Шәрифуллин рәхмәтләрнең иң-иң зурларын үзенең укытучыларына һәрдаим ирештереп әйтә килә, үзенең алар алдындагы бурычын талантлы иҗат нәтиҗәләре белән үтәргә, түләргә тырыша. Композиторның әйтүе буенча, менә аның остазлары-укытучылары: беренчесе, кызганыч ки, инде мәрхүм бик тә күренекле композиторыбыз Нәҗип Җиһанов; икенчесе, үзенчәлекле олы талант иясе Алмаз Монасыйпов; өченчесе, әле күптән түгел генә вафат булган күренекле композитор вә педагог Альберт Леман.

Җиң сызганып, көнен – төнгә, төнен – иртәгә ялгап, тирләп-пешеп, сәламәтлеге шактый чамалы хәлдә иҗат итүче композиторның әсәрләре киң халык массасына барып ирешә, ирешә тора дип авыз тутырып әйтеп булмый әле. Радиодан аның әсәрләре сирәк яңгырый, өстәвенә бүгенге көннәрдә менә-менә тематик зуррак тапшырулар башланып китәргә тиеш кебек сәгатьләрдә эшләү вакыты бетә, эфир вакыты бүтән каналларга күчә... Бүгенге көн татар телевидениесе турында сүз алып барганда, җитди музыкаль һәм интеллектуаль тапшырулар алып бару мөмкинчелеге хакында уйларга да урын калмады бугай инде. Башка илләрнең, башка милләтләрнең дистәләгән телепрограммалары эшләп тору сәбәпле, аларга нинди тапшыру карыйсы килсә, шуны сайлау мөмкинчелеге бар; безгә исә андый сайлану мөмкинлеге булмагач, шул сәгать ярым вакытны этик-эстетик таләпләрдән чыгып сарыф итәсе генә кала... Үзебез турында тапшырулар булмагач, татар йә тавыклар белән бергә ятып йокларга, йә хәшәрәт фильмнарны карап утырырга мәҗбүр була... Заманга иярәбез дигән булып, затлы татар тапшырулары кысылып бетте; ә бит чынында татар үзенең тарихи трагик язмышын аралап, һәртөрле замана шаукымнарына бирешмәү сәбәпле генә исән-сау калган... Авторыбызга әйләнеп кайтып шуны да әйтергә ярыйдыр: әсәрләренең сирәгрәк яңгыравы автор характерының шактый үзенчәлекле булуы (чын иҗатчының кайсының җайлы-майлы холкы булганы бар?), үзгәрмичә бертөрле калуы, кайчагында хәтта «шырпылы» булуы аркасында туган аңлашылмаучылык сәбәпләре белән дә бәйледер. Тик барыбер талантны томалап куеп булмый, чын әсәрләр үзенә юл яра. Музыка мәктәпләрендә, консерваториядә, пединститутның музыка белеме факультетында, культура академиясендә, музыка училищеларында Шамил Шәрифуллинның төрле характердагы вокаль һәм инструменталь әсәрләре даими өйрәнелә. Димәк, традицияләр-чылбырлар бәйләме өзелми, дәвам итә.

*2000*

# 5. Юлларда еллар күренә

**УҢГА КАРАСАҢ ДА, СУЛГА КАРАСАҢ ДА...**

«Чит илләргә чыксаң, озак торма, гыйбрәт алыр өчен чык икән» дип җырлана халкыбыз җырында. Чыны да шулай. Оҗмах кебек илләрдә оҗмах кебек шартларда урнашсаң да, бер атнадан үлеп Казанны, туган җиреңне сагына башлыйсың. Барысы әйбәт, бар да бар, әмма туган җир түгел, әллә нәрсә, әллә ни җитми. Ни җитмәсен, билгеле инде, әле син йокыдан торыр-тормас ук, сәгать җидедән алып сигезгә

хәтле генә, ярты-йорты гына булса да татарча эшләгән «Чулпан» программасы, тыңлаучылары белән сәгать сигез тулар-тулмас ук саубуллашса да, Татарстан радиосы юк. Шулар җитми күңелгә.

Ә менә Чехиядә урнашкан кечкенә генә шәһәрчектә яшәүче халыкка рәхәт – Карловы-Варының үз радиосы һәм телевидениесе көне-төне эшләп, күрсәтеп, сөйләп тора. Югыйсә бер үк чех бит инде үзләре, бер үк диндә, «ярамаганмы» аларга тапшыруларны Прагадан гына карасалар, тыңласалар, югыйсә акча «әрәм» итеп яталар. Чех хакимиятләре кеше психологиясе белән санлаша, күрәсең: кешенең бит иң беренче үзен, үз тирә-юнен беләсе килә.

Менә шулай, нигә сез үзегезнең шәһәр сүлендә шулхәтле кайнап быгырдыйсыз, димиләр, тыгылып тыкшынмыйлар, күрәсең. Аннан бит, карагыз әле, теге, без белгән Чехословакия дигән ил дә шыпын гына икегә: Чехиягә һәм Словакиягә аерылды да куйды – ник берсе әйтсен, син, Чехия, Словакиядән башка яши алмыйсың, дип яисә, киресенчә, син, Словакия, Чехиядән башка яши алмыйсың, дип. Ә бит без суверенитет өчен көрәшеп йөргән елларда «Татарстан Россиядән башка яши алмый» дигән сүз төп аргумент итеп файдаланыла иде. Ә менә Чехословакиядәге ике халыкның берсе мөселман динен тотучылар булса, хәлнең тавышсыз-тынсыз гына чишеләсенә ышанып буламы? Ай-һай!.. Мөселманнар белән христианнарның төрле мәзһәбенә караган халыклар яшәгән Югославия хәлләрен искә алыйк. Көнбатыш демократиясе дә бик сәер нәрсә икән бит ул, ислам динен үгезне котырткан чүпрәк итәргә тырышыпмы-тырыша... Миттеран, Һельмут Коль ише әфәнделәр дә Чехословакия мәсьәләсендә артык эндәшмәделәр кебек, ягъни эш астан гына, тавышсыз эшләнде, тыштан кырмыска оясына таяк тыгып бутамадылар. Чехлар, славян булсалар да, сөйкемле сөяк – яраткан католиклары бит... Аның каравы, Карловы-Варыда йөргән Мәскәү түтәйләренең иреннәре һәр көнне бүлтәя: иртән, көндез, кичен тәмле итеп әзерләнеп китерелгән ашамлыклардан гаеп тапмый калмыйлар – сүзнең соңы « один язык, один народ», нигә кирәк иде бүленү дигән сыманрак мыгырдану белән бетә. Мин, затлы ризыклар алдында уңайсызланып, фәрештәләр канат япсын ризыкларга, дип утырдым.

Аурупаның нәкъ үзәгендә булса да, халкы тырышып-тырышып холык-фигыльләрендә немецларга охшарга теләп яшәсә дә, Чехиядә әле генә социализм булып киткәнлеге күренеп-сизелеп тора. Шуның бер күрсәткече: һәрберсе уникаль бина рәвешендә, готик-немец стилендә һәм дә әле, бәлки, немецлар тарафыннан төзелгән өйләрнең бездәгечә үк җимерелүе димәсәм дә, шактый ук бетеренүләре. Бүгенге көндә шул матур биналарны берәм-берәм ныклап, озаклап, ремонтлап-сипләп, яңартып яталар. Ягъни мәсәлән, социализм тузанын кагалар. Кагалар дигәч тә, бөтен һавага тузан очмый, төзелеш-сипләү эшләрендә тузан күрсәтмиләр. Монда урамнарга пычрак таратмау, төзү һәм сипләүнең үзеннән дә мөһимрәк санала. Кая ул пычрату, тиеш булмаган җиргә эт аягы да бастырмыйлар. Мәсәлән, бакчаларга, чирәмлекләргә. Этеңне муенчагы, бавы белән алып чык та артыннан үзең җыештыра да бар... Аннан һава суларга алып чыккан этләре дә маэмайлар гына: көчекләр, акбайлар, сарбайлар ише генә. Бездәге кебек бозау хәтле, юлбарыс яисә бүре сыман, зур күсе кебек куркыныч этләр күзгә-башка чалынмады...

Тагын да бер генә мизгелгә социализм сүзенә әйләнеп кайтыйк әле. Аурупада социализм төшенчәсендәрәк җәмгыятьтә яшәп яткан илләр бар. Мәсәлән, кайбер Скандинавия илләре. Чынлап та, анда социаль-җәмгыяви гаделлеккә чын күңелдән ирешергә тырышалар. Ә менә шул сүз Россиягә килеп эләккәч һәм шул сүз белән илнең строй-режимы атала башлагач, дөнья халкы бу сүздән курка башлады. Чынлап та, шактый куркыныч режим булып чыкты бит ул. Милләтләрне бер казанга салып болгату! Менә хәзер капитализм дигән нәрсә тешләрен ыржайта! Авырлыклары хәттин ашып китсә дә, милли мәктәпләр тотарга артык нык комачау итмәсәләр, түзәргә кала инде. Мин юкка гына тотарга димим, үзебезгә тотарга, әйе! Беркемгә ышанмыйча. Милли мәктәп, беренче сыйныфтан югары мәктәпкә кадәр. Капитализмда чиләнеп булса да, үз мәктәбеңне тотарга кирәктер бит инде?!

Менә безнең юмор-йомрыбыз шундый инде, тормышыбыз да усал шаяру сыман. Аннан соң искә төшереп шуны да әйтәсе килә: Чехословакия, Венгрия, Польша һәм тагын берничә башка илгә СССРдагыча «социализм» көчләп кертелгән иде. Бу «социализм»ның Швециядәге социализм белән уртаклыгы юк иде шул. Хәтта якын да килми. Хәзер менә Россиядәге капитализмның да рәтле-башлы капитализм белән уртаклыгын табу, йомшак итеп әйткәндә, читенрәк бугай. Аш өстеннән булмаган өрене тотып, җыеп кара... Россия дигәндә, социализм яисә капитализмны гаепләүдән мәгънә юк бугай.

Яңа шартларга килеп эләккән чехлар да зарлана. Анысы да дөрес, тик аларның зарлары безнекенә охшамаган. Пәри башка, җен башка. Телевизорның төймәсен баскан саен, икенче, өченче, дүртенче, бишенче һ.б. телләрдә барган тапшыруларга юлыксаң да, әйткәнебезчә, Карловы-Варының көне-төне күрсәтеп, сөйләп торган үз каналы, Праганың үз каналы.

Һәркемнең кай җире авырта, шуны сөйли дигән кебек, бу безне бик тә кызыксындырган вә кызыктырган нәрсә шул, үзебездә дә мөстәкыйль телевидение каналы булдыру турында хыялланасың. Мәскәүдән өч-дүрт сәгатькә теләнеп алган кеше каналы кызыкмыни ул? Әгәр дә бу көннәрдә «ирешелгән уңышны» – татарча тапшыруларны кичке алтыдан тугызынчы яртыга кадәр генә алып баруны искә төшерсәң, нәрсә килеп чыга? Ут та алмыйча, тавыклар белән бергә ятып йоклагыз, татарлармы? Сезнең таңнан торып эшлисегез бар, тапшыруларны төне буе аксөяк булган халык кына

карарга хокуклымы? Татар яшьләре татарча тапшыруларга күз дә салмасынмы? Алар тапшыруларны, чынлыкта, кичке тугыздан соң гына карый башлыйлар ич.

Шулай да Карловы-Вары турында да иде бит әле сүзебез. Дөньяга танылган курортлар шәһәре ул. Бөтен кыйтгалардан килгән халык мыжлап тора. Чисталыкка мөкиббән китүләрен күрсәтүдән тыш, килгән халыкка нинди мәдәни программалар тәкъдим итәләр соң чехлар? Урамда афишалар карап йөрибез. Менә бер кичтәге белдерүләр. Шуларның берсе атаклы чех композиторы Антонин Дворжак әсәрләреннән төзелгән симфоник концертка чакыра, икенчесе шул ук кичне, шул ук Дворжакның әсәрләрен халык музыкасы уен кораллары оркестры башкаруында тәкъдим итә, өченчесе Антонин Дворжакның операларыннан арияләр тыңларга дәшә. Мизгел эчендә «Ә бездә нигә алай түгел, нигә Салих Сәйдәшев, Фәрит Яруллин, Нәҗип Җиһанов әсәрләре шундый хөрмәттән мәхрүм?» дигән уй уза. Шулай ук башка данлыклы композиторларыбыз да онытканда бер искә алына.

Карловы-Варыда бездәге кебек ялангач диярлек кеше төшерелгән афиша-сурәтләрне, яшьләребезне, үрмәкүч эләктергәндәй, үзләренең ятьмәләренә эләктерүче «дини» секталарның чакыру белдерүләрен дә күрмәссең. Билгеле, аста, кеше күзенә чагылмый торган урыннарда, ночной клуб дигәннәрендә «иреклеләр» бардыр ул, христиан дөньясы бит. Безнең җаныбыз «иреклелек» – бозыклыкларда христиан дөньясын уздырып җибәргән Казаныбыз, халкыбыз өчен әрни...

Көн тудымы, Карловы-Вары урамнарын туристлар басып ала, шимбә-якшәмбе көннәрендә шыгрым була; бигрәк тә немецлар күп. Һәрбер өйне, һәрбер ташны җентекләп карыйлар, кайберләре – картлары үзләренең өйләрен дә таныйлар, ахрысы. Картлары дигәннән, өлкән яшьтәге, җитмеш-сиксән яшьтәгеләр, аннан да өлкәнрәк немецлар дөнья буйлап шыбыр килеп йөриләр икән. Менә шундыйрак немецлар янымнан беркөнне шактый гына кыеш-мыеш атлаучы бер хатын-кыз үтеп бара иде (югыйсә атналар буена бер эчкән-исерек кешене күргәнебез булмаган иде), немецлар, карты-яше бергә кушылып, калгып-калгып көлделәр. Менә сиңа немец бюргерлары, әхлаксыздан тәгәрәп көләләр икән ич! Эчеп-исереп, акча туздырып йөрсәләр, немец картлары гына түгел, яшьләре дә һәр елны җылы диңгезгә барып, ял итеп йөри алмаслар иде шул. Искә төшә: Ленин үзенең күп кенә язмаларында немец бюргерларыннан – сак булудан һәм сакчыллыктан көлә. Күрәсең, тешенә тигән булгандыр.

Немецлар турында сүз кузгалгач, тагын бер генә нәрсәне әйтеп китәсе килә. Эш шунда ки, безнең көннәрдә дә татар халкының таралуы дәвам итә, татар һаман читкә китә. Германия-Алманиягә яңа күчүчеләр дә байтак. Яннарына кереп чыккан да бар. Менә шуларның күршеләре – немец кешеләре матур итеп, ачык йөз белән: « Гутен таг, гутен таг», – дип исәнләшеп йөриләр. Бар да әйбәт кебек, әмма беркөнне яңа күчеп килүчеләргә полиция килеп төшә. Сәбәп нәрсәдә соң? Хикмәт шунда: боларның түбә итәге күршеләр ягына нәкъ унбиш сантиметрга төшеп тора икән ич! Түбәңнең итәген кис, штрафыңны да түлә. Искә төшерик әле, бездә шуңа охшаш мәсьәләләр ничек хәл ителә? Күршең синең түшәмеңә, бүлмәңә еллар буе су агыза, әрләшеп бетәсең... Әмма су агызу дәвам итә.

Әйе, чит илләргә чыксаң, гыйбрәт алу өчен генә чык икән. Хәзер менә Мәскәүгә дә чит илгә барган сыманрак барып кайтабыз, бигрәк тә билет бәяләрен истә тотсаң. Гыйбрәт алып була Мәскәүдә дә, тик гыйбрәт башка төрлерәк. Бигүк килешеп бетмәсә дә, Мәскәүдә мунчага баргач булган хәлне әйтергә туры килә. Бердән, мунча бәясе шактый кыйммәт: кырык сум, әле бу унҗиденче сентябрьгә кадәр – тоташ, отыры кыйммәтләнүгә хәтле булган хәл. Билгеле инде, теге атаклы Сандун мунчасы түгел, гади мунча. Шуңа карамастан (кыйммәт булгач) әби-сәбиләр, бәбиләр күренми, мунчага керүчеләр яшьләр, яшь хатыннар, урта яшьтәгеләр һәм әле алары да аз: кыр кебек озын, зур юыну бүлмәсендә барысы унбишләп хатын-кыз. Гадәттә, мунчага кергән мәлдә, пар бүлмәсенә кереп, җылынып чыгасың. Сеңлем Лилия белән без дә кереп чыктык, бераз юынгач, тагын пар иснәп чыгасы килде. Ләкин нигәдер парлы бүлмәнең ишеген шар ачып куйганнар. Бүлмәнең икенче ягында ишек тә тыш якка таба киерелеп ачылган – өерелеп суык керә. Тукта әле, бу ни хәл, озак торырга безнең вакыт та юк, ишекне ябып, җылынып чыгыйк, дисәк, команда «отставить», дүсмән хәтле хатын якын да җибәрми: «Көтеп торыгыз, нәрсә, «тәртип»не белмисезме әллә?!» Әстәгъфирулла! Бусы нәрсә инде тагы? Боз кебек җирдә инде нәрсә эшләргә? Душ астына качтык. Шул арада юынучылар, култык асларына себерке сыман нәрсәләрен кыстырып, пар бүлмәсе ишеге төбенә ... чиратка баса башладылар. Әкәмәт! Мәскәүдә инде бернәрсәгә (акчаны санамаганда) чират калмаган вакыт иде бу. Болар чиратны сагынганнар түгелме соң? Чиратны уйлап чыгарып та була микәнни соң? Мунчада кеше аз ич, пар бүлмәсе бик зур, анда берьюлы утызлап кеше кереп җылынырлык. Шунда алдарак торучыларның берсе, куркыбрак кына: «Ивановна, керикме әллә?..» – ди. «Валяй!» – гөбедән чыккан кебек гөбердәвекле тавыш рөхсәт бирә. Хатын-кызлар берәм-берәм ләүкәгә менеп бастылар, главарь-башлык уртада калды. Сүз мужикларның чебен кебек кырылуы, ир-атның калмавы турында бара... Боларга карап, гасыр башында Григорий Распутинга Россиядә, көтүләп хатын ияртеп, мунчага йөрү ике тиен бер акча кебек гади генә нәрсә булган икән дип уйлап куясың. Ә бит мунчага килүчеләр гади халык түгел, болар хәллеләр, болар бизнеска күчкән белемлеләр, болар мунчада, сыра эчә-эчә, көннәр буе утыралар. Главарь-башлыклары да мунчачы түгел, мунча керергә килүче, тик барысында да көтү

(табун) психологиясе. Боларга шәхес иреге кирәкми, боларга берәр вожак кирәк... Россиянең бөтен хәлен дә шушы әкәмәт мисалдан да күреп буладыр төсле...

И, укучым «уңга карасам да – юк, сулга карасам да – юк» шушы буладыр инде. Көнбатыш демократиясе дә безне якларга уйламый, аларга үз динендәгеләр кадерле. Үз хакимиятләре астында яшәтеп килгән мәскәүлеләрдән дә үрнәк алып булмый, яклау да өмет итә алмыйсың. Ләкин бит шунысы да бар: нигә соң әле үз язмышың, милләтең язмышы башкаларга бәйле булырга тиеш? Нишләп башка кавемгә тормышың белән идарә итәргә мөмкинчелек бирергә? Уйлап карасаң, Көнбатыш үз кануннары, традицияләре белән яши, Мәскәү дә үз дигәнчә, ягъни гасырдан-гасырга берәр каты куллы патша-вожак килеп чыгуын көтеп, шуңа еш кына ирешеп тә яшәп ята...

Менә шулай, берәр җиргә барсаң, үзең турында, ягъни татар турында, тагын да өзелебрәк, әрнебрәк уйлыйсың, хисләрең яр комына эләккән балык кебек тырпылдый, янәдән суга сикермәк була. Чыннан да, шундый хикмәтле юл белән котылган балыкларны үземнең дә күргәнем бар...

Ә сүзне шигырь белән тәмамлыйсы килә. Эш шунда ки, мин анда (Аурупада) «Альп таулары» дигән атаманың нәрсә аңлатуын сораштым. Җавапларын: «Зур таулар», – дип бирделәр, димәк ки, Алып таулары. Билгеле, без аны шулайдыр дип фаразлый да идек...

**Аурупада**

Мендем Алып тауларының башына,
Карадым үзәннәр төбенә:
Елгачыклар ага, исеме, бәлки,
Кайсы Зөя, кайсы Гөбенә?..
Төрки бабам булган, исеме аның
Җиһанда бер яугир Атилла.
Яуларының кайтавазы калган –
Төркичәләп таулар атала.
Гел таныш та кебек бу тирәләр:
Баштан-башка тоташ болынлык;
Кичү белән Әлки арасыдай,
Яшел җәйгән хозур бер тынлык.
Уйламыйсың Үзәк Аурупаның
Нәкъ уртасы диеп бу җирләр;
Технократик җәннәт корсалар да,
Табигатьне саклый чын ирләр.
Хушбуй сипкәнмени, тәмле һава,
Йә Ходаем, әйтмим көнләшеп,
Кодрәтеңдә бары – үз иркеңдә,
Без дигәнчә булмый өләшеп.
Өләшергә... ул садака түгел,
Ходай биргән түгәрәк бәхет.
Тик шулай да үзләренә булсын,
Туган җир – безгә алтын тәхет!

*1998*

## ЫКНЫҢ АРЪЯГЫНДА

Уфа–Казан поезды. Ык елгасы аша салынган күпергә җитә башлауга, күптән билгеле бер гыйбарәне онытмауларын күрсәткәндәй, берничә пассажир берьюлы: «Дөньядагы иң озын күперне чыгабыз», – дип әйтеп салды. Бу сүзләрнең ни өчен әйтелгәнен аңлатып: «Күпергә кергәндә сәгать өч иде, хәзер сәгатьләрегезне бишкә төзәтегез, күперне ике сәгать чыктык», – диде тагын берәүсе. Бу шундый «шаян» чынлык инде...

Сүзне Уфа–Казан поезды дип башлагач, төп мәсьәләгә күчкәнче, яманаты чыккан бу «атаклы» поезд турында бер нәрсәне әйтеп үтәсе килә. Тфү-тфү, күз тимәсен дигәндәй, вагон эчендә хәзер тынычлык. Аллаһыга шөкер, акыру-бакыру юк, эчүчелек тә сизелми сыман. Әмма вагоннарның искелеге, андагы пычраклык-шапшаклык элеккечә. Югыйсә составның исеме яңгыравык, матур лабаса: Уфа–Казан. Гүяки шул исем кемгәдер ошамый да шуңа пычратырга тырыша...

Баргалыйм мин Ыкның аръягына, еш кына дияр идем. Анда минем олы абыем Госман гаиләсе белән яши. Абыемның хатыны яраткан Хәлимә җиңгәчәм телефоннан сөйләшкәндә сүзне кистереп әйтә, кил, фәлән көндә, фәлән сәгатьтә, поездга төшеп каршы алырбыз, дип, ике уйларга да ара калдырмый. Рабига апам да гаиләсе белән шунда яшәп ята. Таралмаса, сибелмәсә, татар татар да булмыйдыр инде. Минем абыйлар, апалар күчкәндә әле хәлләр дә башкачарак иде. Болгар дәүләте заманнарыннан ук әби-бабаларыбыз яшәгән Ыкның аръягыннан Уфага хәтле җирдәге шәһәр-авылларда әле 60–70 елларда да шаулап-гөрләп эшләп торган татар мәктәпләре булганда, монда тордың ни дә, тегендә тордың ни – шул ук бер татар мохите дип уйларга мөмкин булган. Безнең барлык кода-

кодагыйларыбыз, кодачаларыбыз да татар мәктәбендә укыган кешеләр. Ләкин соңгы берничә дистә елларда татар мәктәпләре хакында сагынып сөйләргә генә калган иде инде...

Минем барып йөри торган җирем Мулла иле дигән татар авылы эргәсендә төзелгән Октябрьский дигән нефтьчеләр шәһәре. Зур нефть аркасында заманында шактый шаулаган бу кала хәзер тынып калган. Мине, билгеле, нефть тә, базарда тезелеп киткән чит ил әйберләре дә кызыксындырмый. Монда, халыкның яртысын диярлек милләттәшләребез тәшкил иткән шәһәрдә, татар мохите бармы? Мине кызыксындырган нәрсә шул. Сүз уңаеннан гына шуны әйтергә кирәк, халык кирәк-ярак, тауар тулып ятуга каршы түгел, тик менә акча ягы... Акча анда да җитми, биреләсе дә вакытында бирелми икән. Нефть азайганнан соң, эштән бушаган нефтьчеләр җир мае чыгарырга Себергә йөри башлаганнар. Ләкин анда да эш хакын күбрәк... әйберләтә бирергә тырышалар икән. Әмма нефтьчеләр алыштырган бартер энә генә түгел инде, ул – дөя. Мәсәлән, өч нефтьченең эш хакына бер машина туры килә.

Сүзебез татар хәлләре хакында иде. Элеккеге татар мәктәпләренең берсе торгызылган, башка кайберләрендә татар сыйныфлары бар, диделәр. Мәчет эшли. Октябрьскийда бик шәпләп Ислам мәдрәсәсе эшләп киткән иде. Әмма кемнәргәдер аның читтән килгән спонсорлары ошамаган икән... Шәкертләр ач һәм укытучысыз калган. Шәһәр уртасына дип планлаштырган мәчет кала читендәге Төрекмән авылына салынган, картларга барып йөрүе читен. Теләсә кем белән бөтенләй башка нәрсә турында сөйләшсәң дә, шул мәчет хәлен искә төшерми калмый. Барып булмый, ерак. Әмма халык барыбер ничек булса да яши бит инде ул. Үзе оеша. Мин барганда Рамазан шәриф ае иде. Һәр көнне (һәм чират белән әле!) авыз ачтыру – ифтар мәҗлесләре. Менә шунда рәхәтләнә икән инде халык, былбыллар кебек чүкердәшә. Яшь «абыстайлар» һәм ять-яшь ир-атлар да шытырдатып дога, аять-сүрәләр укыйлар. Шаклар катып тыңлап утырасың. Мәҗлестәшләрнең яртысы – яшьләр. Әйтик, Гөлсем ханым, бишенче сыйныфта укучы кызлары Роза вә җәмәгате Марат әфәнде. Өчесе дә уразаны калдырмыйча, Коръән аятьләрен укып, чын мөселманча тормыш алып баручылар. Мәҗлес хуҗалары – яшь пенсионерлар Камәрия ханым ире Рәзиф әфәнде белән пенсиягә чыктык дип тормыйлар, хәрәкәттә бәрәкәт дип яшиләр. Һөнәре буенча балаларны көйгә-моңга өйрәтүче яшь кенә Тәнзилә ханым да башта мәдрәсәгә йөргән, аннан үзлегеннән дә өйрәнеп гарәп имлясы белән укырга өйрәнгән, догаларны яттан белә. Бирердәге халыкның ачыклыгы, кунакчыллыгы миндә һәрвакыт соклану хисе тудыра иде. Ишегалдында йөрүче берәүнең урамнан узып баручы таныш түгел кешене дә «Исәнмесез!» дип кычкырып сәламләве баштарак миңа хәтта мәзәгрәк булып тоелганын хәтерлим...

Шулай итеп, Ыкның аръягындагы кардәшләребезнең рухи тормышының бер ягы миңа бераз ачылды кебек тоелды. Тагын да уйлыйсың. Болар радио-телевидениедән кемне тыңлый, нәрсә карый икән дип тә шигаясең. Тыңлаганнары – Казан, караганнары – Казан. (Хәзер алай түгел, башкорт трансляциясе шулай көйләнгән...)* Мәскәүдән, билгеле, бер-ике ел рәттән бара торган чит ил сериалларын карыйлар. Уфаны караганнарын бигүк күрмәдем.

Менә карап утырабыз Казанны, хикмәт, биредә үзебезнең тапшыруларга чит кеше кебегрәк бәя биреп утырам икән (эчтән генә билгеле). Телевидениедәге ярлылык күзгә бәрелеп тора. Өйдә алай ук тоелмый иде. Әйе, беләбез телевидение аппаратурасының 30–40 елга артка калганлыгын, студияләрнең җиһазлары, мебеле искедән-иске икәнлеген беләбез. Әйткәнемчә, биредә икенче җөмһүрияттә утыргач, үз туганнарың арасында булсаң да, уңайсызрак. Тиз генә Казанга шылтыратып, матур итеп төшерегез әле, абау, өстәлләрегез, абау, култыкса-урындыкларыгыз, дип әйтәсе килә... Мәскәүнекеләр андый түгел бит, ялык-йолык килеп ялтырап тора. Бөтен бала-чаганы, яшь-җилкенчәкне һәм... картларны да тартманың эченә керерлек итеп үзенә тартып тора. Кеше дигәнең әле кайчан аңына килеп, кешелек йөзен кайтарып, теге секс-мекс, үтереш-бетереш күренешләреннән туяр, шундый чирканыч нәрсәләрне карамый башлар, билгесез. Әмма безгә бу араны якынайту өчен, шул ук телевидениенең аз булса да үзебезгә бирелгән вакыт аралыгындагы татар тапшыруларына таянырга кирәк. Ләкин безнең ул тапшыруларыбызны да әйбәт дип кенә әйтеп булмый. Аның бит әле шул кыска вакыт эчендә дә безнең телдә булмаганы бар. Менә алар тапшыруында бүгенге көннең негатив якларын тутырырга тырышалар. Күзләре наркотик белән тулган әллә нинди музыкантлардан, кем әйтмешли, «на полном серьезе» интервью алу дисеңме, бала-чаганы гына түгел, олыракларны да куркыта торган тимер музыка яңгырату дисеңме, болар хәтта Россия каналларының да төнге уникедән соң гына күрсәтелә торган тапшыруларына охшаган. Әйтсәң сүз дигәндәй, ә инде Рамазан шәрифнең гает кичәсендә мәҗүсилек атрибуты Вакх – аракы алласының бәйрәмен балет биюе итеп күрсәтүне һични белән дә аклап булмый. Әле бу шундый фестиваль икән. Адәм рәтле фестивальгә кем дә каршы булмас иде. Нигә әле Салих Сәйдәшев исемендәге фестиваль чышын-пышын гына уздырыла? Нигә Нәҗип Җиһанов исемендәге фестиваль яисә конкурс юк? Бу ике төрле бәйрәмгә якыннан да, әллә кайдан ерактан да төрки, угыр-фин, мөселман илләреннән дә һәм теләсә кайсы башка илләрдән дә катнашучыларны чакырып булыр иде. Чөнки бу ике талантыбызның да музыкасы сандугач кебек сайрап тора.

Татарча яңгырый торган «Җиһан. Хәбәрләр»не алсак, анда гел авылны гына түгел (дөресе, кешеләрен әйтмибез, ә машина-трактор күрсәтү галәмәтен), башка хәбәрләргә дә бераз игътибар бирүгә ирештек бугай, ләкин төрлелек һаман да аз. Авылга үзенә аерым тапшыру багышлау шулай ук әйбәт булыр иде. Әмма телевидение тапшыруларының эчтәлеген киңәйтү, яңарту, сыйфатын күтәрү аның матди хәлен яхшырту белән бергә барырга тиештер инде ул. Безнең халыктагы талант ияләрен һәм кызыклы темаларның күплеген әйтеп бетереп булмас иде. Иң өстә яткан, күзгә бәрелеп торган җыр сәнгатебез өлкәсеннән генә бер мисал китерәсе килә. Мәсәлән, Зилә Сөнгатуллина иҗатына багышлап, заман югарылыгында, киләчәкне дә истә тотып, шул киләчәктә дә буяуларын җуймый торган төсләр, колорит белән кызыклы итеп, бәлки маҗаралы да фильм төшерелгәне бармы соң? Юк бит. Ул безнең җырда чәчәкле киң болыннарыбызны, тирән дәрьяларыбызны, куе урманнарыбызны, мул уңышлы кырларыбызны хәтерләтә. Сандугач хәтле генә, сандугач кебек кенә Гөлсем Сөләйманова безнең өчен французларның Эдит Пиафы булса, Зилә безнең Мирей Матьебыз бит ул. Гаҗәп хәл, бу ике җырчыбызның тавышлары белән генә түгел, хәтта тышкы кыяфәтләре белән дә әлеге бөек француз җырчылары белән охшашлыклары бар кебек. Билгеле, тик безнең халыкка гына хас булган холык-фигыльләре белән аерылып та торалар.

Менә тагын бертөрле, кем әйтмешли, музыкаль мизгел: «Җомга көн, кич белән» тапшыруына нишләптер шактый еш кына яшь (һәм кайвакыт тавышсыз) җырчыны чакырып, башкаручыны уңайсыз хәлдә калдыралар. Ул бер җырда гына ачыла да алмый, үзенең каушавын да җиңә алмый. Ә бу тапшыруны бик тә таләпчән тамашачылар караганы билгеледер, шәт. Яшь җырчыларга чирканчык алдыру, телевидениегә күнектерү өчен аерым тапшыру – җомга түгел, «шимбә өмәсе» кирәктер, бәлки?

Хуш, телевидение мәсьәләсе шулайрак тора кебек. Утларда янса да, суларда калса да, тагын да меңтөрле һәлакәтләргә очраса да, татар халкының үзе кебек үк, барыбер исән калган китабы бар бит әле. Аның хәле ничек Ыкның аръягында? Берничек тә түгел, юк ул кибетләрдә. Октябрьский шәһәренең нәкъ үзәк урамында урнашкан китап кибетендә татар телендә бер китап бар иде барлыгын. Ул да булса, Татарстан китап нәшрияты тарафыннан 1996 елда башкорт шагыйре Рәми Гариповның татарчалаштырып чыгарылган шигырь китабы. Кибеттә тагын да башкортча язган язучыларның китаплары бар, Уфадан килгән, билгеле. Моны басым ясап әйтүнең мәгънәсе шунда – Рәми Гариповның да китабы Уфа аша килгән. Казаннан китап килми. Кибетчеләр, Казанга хәтле барып алырга хәлебез җитми, диләр. Вәссәлам. Ә халык нишли соң? Халык китаптан бизә, радио-телевидениедән өстән-өстән генә алынган мәгълүматка канәгать булып яши. Почта чыгымнарының чүпрәдәй күпереп үсүе аркасында Татарстанда чыга торган гәҗит-журналга да язылмыйлар хәзер. Элекке елларда «Сөембикә» («Азат хатын») журналын һәрбер өйдә диярлек очратырга мөмкин иде. Бу күренеш соңгы елларда юкка чыккан. Шулай итеп, халык яңа шартларда олы кәүсә-куакның – мәдәниятнең зур тармагы булган татар китабыннан аерылган хәлдә яши. Берничә кеше генә, Татарстан ягына чыгып, Баулы, Ютазы тирәсеннән әйләнә. Хәер, көндәлек хаҗәткә әйләнеп барган китаплар да бар икән. Бу – мәчетләрдән ала торган дини китап. Күркәм фал, билгеле. Әмма Ходай Тәгалә адәм баласына тулы канлы тормыш белән яшәргә боерган. Коръән Кәрим, иҗтиһад итегез, ди. Матур әдәбият укымаган кешенең гармонияле булып үсүен моңа кадәр тарихның исбат иткәне юк әле. Көнчыгышның бөтен бөекләре матур әдәбиятның ләззәтен татыган кешеләр алар.

Дөресме-түгелме икәнен расларга алынмыйм, Башкортстан ягы хакимияте башкорт китабын үзе китереп, хәтта бушлай тарата дигән сүз йөри халыкта. Бушлай таратмасак, бәлки, безнең хакимият татар китапларын илтеп тапшыру ягына булса да булышыр иде? Югыйсә иң күп халкыбыз яшәгән Башкортстанда татар китабын оныту мизгеле нәкъ төшлеккә җиткән, тәгәрәп төшеп китүгә көч куллану да кирәкми... үзеннән-үзе түбәнгә таба шуып кына бара торган эш ул. Ләкин шулкадәр халкыбызны онытырга безнең хакыбыз юктыр ич инде?

Шундый күңелсез уйларны таратырга теләгәндәй, Октябрьскийдагы дусларым: «Безнең «Туган як» гәҗите әйбәт чыга. Әле менә күптән түгел җидееллык юбилеен үткәрдек. Халык күп иде, утырып түгел, басып торырга да урын җитмәде», – диделәр. «Туган як» кечкенә форматлы, дүрт битле гәҗит икән. Матур гына. Эчтәлеге дә әйбәт, мәгънәле.

Безнең халыкның иң төп сыйфаты ни икән дип уйлансаң, ул сыйфат зарланмаудыр дигән фикергә киләсең. Берәр нәрсәгә, кешегә дәгъва-кинә белдерү гадәте юк. Кайвакыт сөйләшкәндә ялгыш кына телдән ычкына – җирле телевидениедә татарча тапшыру юк икән, радио да татарча сөйләми. Уфадагы гимназияләрдә күпчелеге татар балалары булса да, аларга татарча сөйләшмәгез дип әйтелгән кисәтүләр хакында да сүз арасында ялгыш кына әйтелә. Ә Габдулла Тукай истәлегенә Уфада куелган тактага татарча язарга рөхсәт бирелмәве хакында Октябрьскийда белмиләр дә белмиләр инде...

Россия шартларында язмыш адәм баласын тегендә йолкый, монда йолкый, пәри-җеннәр күтәргән җил-давыл эченә бөтереп алып кереп китә. Анда бар җелек-җегәрен суырып, кабыргаларын санап, җиргә сылый. Каһкаһә белән көлә. Безнең милләттәшләр дә бу мәхшәрдән читтә кала алмый, тик менә бирешмәүләрен бер Аллаһтан үтенү лязем. Туганнар туганлыкларын онытмастыр, шәт?

*1997*

**УЙЛАГАНГА УЙ КИЛӘ**

Төркия... Безнең өчен тылсымлы бу сүз ничә дистә еллар буе тыюлы булып килде. Әмма без татарларның Төркиясе һәрвакыт бар иде. Без үзебезнең иң борынгы мәдәни халыкларның берсе булган төркиләр кабиләсенә кергәнебезне теләсә нинди авыр заманнарда да онытмаганбыз ич. Хәтта баш хәрефтән языла торган Төркия дә совет елларының теләсә кайсы дәверендә дә татарча укый белә торган кеше өчен бөтенләй үк телдән төшеп калган сүз булмагандыр. Берәр «искерәк» китаптамы, гәҗиттәме, әдәби әсәрдәме Төркия дигән сүз килә дә чыга, килә дә чыга иде. Ишетеп белә идек, безнең татар халкы күпләп киткән икән анда. Тукайның «Китмибез»е колакта тора.

Аннан соң Төркия хакында урыс телендә кайбер китаплар күренә башлады. Аннары менә Миргазиян Юнысның роман, повестьлары китте. Аның Босфор турында язулары... Үтереп Босфорны күрәсе килә. Һәм бөтен Төркияне дә. Менә әле, теге, торгынлык елларының ахырындарак булса кирәк, бер төркем язучылар Төркиягә җыена башлады, мин дә бармакчы булам. Әллә никадәр характеристикалар, документлар җыелды. Үзебезнең эштәге партсекретарь Валентина Шакирова белән, гәрчә ки коммунист булмасам да, партия райкомы комиссиясенә дә әйбәт кенә барып килдек кебек. «Нигә барасың Төркиягә?» дигән сорауга, шартлатып: « Назыйм Хикмәтнең ватанын күрәсем килә», – дип җавап бирдем. Әмма барыр көн килеп җиткәч, беленде: мин исемлектә юк икән бит, минем фотолар югалган... Документлар Мәскәүгә җибәрелмәгән, имеш. Югыйсә мин шул документлар җибәрүче кешеләрдән әллә ни еракта да эшләп йөрмим, фотоның икенчесен дә биреп була. Аллаһыга шөкер, хәзер хәл үзгәрде, бар, йөр. Ә минем Төркиягә барасым килә. Инде шактый кеше Төркиядә, Истанбулда булып, күреп кайттылар. Барысы да мактый, ошата. Әмма ул кадәр үк булыр дип уйламыйсың әле.

...Анталия дигән җир чәчәк арасы икән, шул чәчәкләрнең иң зурысы зәңгәр чәчәк – диңгез икән (Ак диңгез диләр). Бөтен дөнья халкы Төркиянең көньяк яры буйлап шыгрым тулган. Бал кортлары кайда бал барын яхшы белеп очкан кебек, дөнья халкы яхшы урынны сайлап җыелган икән. Дөнья җәннәте дигән сүз бар, шул буладыр инде бу. Төркиянең туризмнан кереме ил табышының кырык процентын тәшкил итә, диделәр безгә. Шулайдыр, дөнья стандарты дәрәҗәсендә хезмәт күрсәтелә туристларга. Башкача булса, бөтен матур җирләрне күрергә өлгергән инглизләрне, немецларны бер үк урынга кабат-кабат китерә алмассың. Әнә алар биредә үзләшеп, халык, хезмәткәрләр белән дуслашып беткәннәр. Гарсон-официантлар, таксистлар аларның иске танышлары икән. Ире үлеп, өч-дүрт бала белән калгач, эшкә кергән төрек хатыны (гадәттә, гаиләле төрек хатыны эшләми) кай арада өйрәнеп алган? Ике-өч телдә иркен сөйләшә. Без дә бераз төрек телен өйрәнеп барган идек, татарча да, төрекчә дә сөйләшеп йөрдек.

Безнең ашый-эчә торган җиребез кыр кебек зур-зур өч зал. Төрле-төрле халыклар җыелганга күрә, менюлар сәламәтлек өчен күптөрле кешеләргә дә яраклы дип табылган «шведский стол» рецептларыннан чыгып төзелгән.

Заманында минем дөньяның иң бай илләреннән булган Швециядә һәм аның күршесе бик тә мөлаем ил Финляндиядә булганым бар иде. Хәтерлим андагы «шведский стол» тәгамнәрен. Әмма Төркиядә гаҗәп хәл: ике атна буе һәркөнне диярлек үзгәреп торган йәмәкләрнең(ашамлыкларның) исәбенә-санына чыгып булмады. Әле шунда ук төрек милли ашлары аерым була. Төрекләр үзләрендә үскән күптөрле яшелчә вә җимешләрнең барысын да диярлек дөгеле-итле, яшелчәле яисә баллы фарш итеп тутырып пешерергә ярата лар икән.

Өйгә кайтырга вакыт җитә. Диңгездән аерыласы килми... без китәбез... кала диңгез...

Шөкер, гүзәл җирләрне күрдек. Гүзәл икән безнең төрек туганнарыбыз, эшчәннәр икән, намуслылар, самимиләр икән.

Шулаен шулай да, гасырлар шәһәре борынгы Истанбулны, Босфорны күрмәгән ич әле, шуларны күрмәгәч, Төркияне күрү була диме инде ул? Форсат та чыгып тора, барырга кирәк Истанбулга!

...Истанбул урамнарын бераз әйләнеп йөри башлагач, симметриясе бөтен җирендә дә сакланып бетмәгән чуар, матур зур келәм белән чагыштыра башлыйсың аны. Менә нинди икән ул безнең эрага хәтле үк салына башлаган шәһәр! Калынлыгы бишәр метрлы дивар-стеналы бина лары барлык заманнарның төсен саклаган хәлдә бүгенгегә килеп кергән Истанбул. Әнә Айа София мәчете, чиркәү вакытындагы кебек, бер җире дә ватылмаган да, җимерелмәгән дә. Төрекләр аны, мәңге җимерелмәслек итеп, эчтән дә, тыштан да ныгытып куйганнар, хәзер инде ул музей. Аның күршесендә генә торган Солтан Әхмәт мәчетенең матурлыгын сөйләп бирер өчен хәтта ки сандугач теле дә җитмәс иде. Төзи белгәннәр төрекләр дисең дә тел шартлатасың, баш чайкыйсың.

Истанбул шулай да Анталия түгел, тоташ чәчәклек дип әйтеп булмый, әмма ул, әйткәнебезчә, үзе чәчәк-келәм. Шул келәмдә, чәчәкләр өстендәге бал кортлары сыман, халык, төрекчәләп әйтсәң, калабалык, гүяки бүлмәләрдә беркем калмаган. Биредә урамнан башлап кибет эчләренә кадәр моңа

чаклы мин күрмәгән базар – урам озынлыгындагы чуар товар конвейры. Шул базарда майкалар, күлмәкләр, чалбарлар, куртка-туннар, итек-читек, туфли-ботинкалар бер кулдан икенчесенә күчә, җыелып зур-зур өемнәр барлыкка килә. Икенче караганда, ул өемнәр алагаем капчыкларга төялгән була. Бераздан капчыкларны, әллә нинди озын зур автобусларга төяп, аэропортларга озаталар. Автобуслар «Карго» (без, билгеле, карга дип атадык) дигән фирманыкы...

Әнә шулай, Төркия базарыннан алынган товарлар БДБ илләренә кайта. Аурупа халыкларының да төрекләрдән шактый гына әйбер алганнары күренә. Алар күбрәк кыйммәтле кибетләрдә йөри, андый кибетләрнең дә очы-кырые юк. Безгә очсыз товарлар да бик ярап куя әле. Ходай кушып, безнең халык та бер баер әле... Ә бездәге бәяләрнең югары икәнлеген төрекләр белә икән. «Сездә кыйм-мә-әт» диләр алар. Югыйсә өстәге түрәләр «Без дөнья бәяләренә таба барабыз» дип сөйләнергә ярата. Баксаң, төрекләр күзлегеннән караганда, бездә әллә кайчан дөнья бәяләре икән. Әллә без һаман да «куып җитү, узып китү» томанлыгында вә томаналыгында яшибезме? Истанбулда ит кыйммәт тауар, аның бәясе егерме биш мең сум, башка әйберләр, яшелчә-җимеш арзан, уртача хезмәт хакы бер миллион. Йөз мең сум, уртача пенсия дә шул чама. Пенсия дигәннән, егерме ел хезмәт стажы булган хатын-кыз һәм егерме биш ел эшләгән ир-ат теләсә кайсы яшьтән пенсия ала икән. Сакалны сыйпаганчы көтү юк. Уйлана белгәнгә уйланырлык.

Бигрәк мактыйсың инде Истанбулны, Төркияне, диярсез. Әйе инде, килеп киткән кешегә ничек күренә, шулай язу.

Чынында, төрекләр дә адәм баласы, алар да зарлана. Әллә яхшыдан яхшыракны телиләр, әллә зарланырлык зарлары бар... Телевизор митинг, пикет, демонстрация, забастовкаларны күрсәтеп кенә тора. Төркия үзен демократик ил дип, һәр сәгать, һәр көн тәкърарлый. Чынлап та, шулай икәнлеге шактый нык сизелә. Президентның, башка башлыкларның җитешсезлекләрен күзләренә карап әйтүне дә шул ук телевизор күрсәтә. Мондый эшләрне төрле партияләрнең җитәкчеләре, активистлары, зур галимнәр, икътисадчылар алып барганлыгын карап беләсең. Аннан кала, исәпсез-хисапсыз булган җәмәгать оешмалары атна ахырында шулай ук җыелышып, төрек хәле, конулары – проблемалары хакында сөйләшәләр. Ничекләр итеп төрекне, Төркияне алга җибәрергә. Бу сөйләшүләрдә шулай ук икътисадчылар, галимнәр, наширләр, эш адәмнәре, гомумән, теләгән һәркем катнаша ала. Без, килгән кешеләр, тыңлап кына утыручылар көнләшми (яхшы мәгънәсендә) нишлисең инде? Бездә шулай халыкның бер өлеше генә булса да, җыелып, татарны, Татарстанны ничек алга җибәрү турында сөйләшәсе иде дип әйтсәң, ышанмаслар, «син нәрсә, әнә дәүләт кешеләре бар, уйласыннар, уйлыйлардыр әле» дип китеп барачаклар. Ә дәүләт кешеләре дигәннәребез Ленин заманыннан калган оппозиция сүзен тартып чыгарып шунда ук дошман эзли башлаячак кебек яисә бездә безнең профсоюзлар кебек кенә «оппозиция» булачак. Төркия хөкемдарлары бу сөхбәтләшүләргә постларында тагын да яхшырак эшләп җавап бирергә тырышалар төсле, экономистларның фикеренә колак салалар, диделәр безгә.

Без, Татарстаннан килүче татарлар, Төркиядә яшәүче милләттәшләребез белән дә аралаштык. Күбесе туган телне әйбәт белә, төрекләр белән ихластан дус, тату яшиләр, әмма Туган илне нәселдән нәселгә, буыннан буынга күчеп һәрберсе сагына икән. Шулай итеп, ничә йөз елларга тулган тоташ сагыну килеп чыга. Шат чырай белән килеп күрешкән, танышкан милләттәшеңнең күз карашының төбендә әллә нинди, үзәк өзгеч сагыну күреп, йөрәк әллә нишли, күзгә-күз карамаска тырышып сөйләшәсең. Сүзләр ярдәм итә, ашыгып-кабаланып алар сораштыра, син дә елмаеп җаваплар бирәсең. Алар берсе дә, безнеңчә әйтсәк, төшеп калган кешеләрдән түгел, көйләнгән тормышлары бар, тырыш хезмәтләре аркасында имин яшиләр. Мәсәлән, кем дигәндә, әле без барында гына да нәкъ менә, нигездә, татарлар катнашкан һәм җитәкчесе дә татар кешесе булган «Тумата» ансамбле Истанбулның Җамал Рәшит Рәй исемендәге иң затлы зур концерт сараенда чыгыш ясады, концерт бирде. Әмма ансамбль программасының күп җырлары «Җилләр исә... җилкетә... Туган илгә ни җитә?..» дигән кебек сүзләр белән чигелгән...

*1997*

**ЮЛЛАРДА ЕЛЛАР КҮРЕНӘ**

Моңа чаклы бер-ике мәртәбә Төркиядә булып, аның гүзәл зөбәрҗәт диңгезләрен, оҗмах бакчасыдай матур яшел үзәннәрен, киң кызыл-сары далаларын, таш-тауларын, әкияти матур, пөхтә шәһәрләрен күреп хозурланган идем инде. Әмма менә бөтен дөньяга атаклы Истанбулны күрергә насыйп булмаган иде әле.

Ниһаять, мин Истанбулда! Гүзәлләр, Ләйсәннәр белән төрек телен өйрәнеп йөрибез. Өгрәтмән – укытучыбыз искиткеч гүзәл Кадрия хоҗа (хөрмәтләү сүзе) – Кырым татары. Шулкадәр дә татарларны сөяр икән, йөрәген ярып бирер иде. Дәрестә сүз саен диярлек татарларны аерымлап, мактап тора, безгә

зур ышаныч белдерә. Үгрәнҗеләр – укучылар чуар: кыргыз, хакас, чичән, яһүд, уйгыр, калмык, украин һ.б. Уку барышында кайберәүләр төрекләргә төрле мәшәкатьләр дә китереп чыгаргалады, ә татарларның бар эше – яхшы уку икән.

Кадрия ханым чын мәгънәсендә миллиятче-милләтче. Йосыф Акчура тарафыннан төзелгән Төрек Учагының Истанбулдагы бүлегенең оештыру мөдире ул. Барлык оештыру эшләре аның куллары аша үтә. Сүз уңаеннан шуны да әйтергә кирәк, бу оешманың бүлекләре бөтен зур шәһәрләрдә һәм башка җирләрдә дә булып, бер-берсе белән бәйләнештә эшлиләр. Гомумән, Истанбулдагы төрле җәмгать оешмаларының очы-кырые юк. Алар халыкны «йоклатмау» юлында әйтеп бетергесез зур эшләр эшлиләр. Оешмалар зур-зур тарихи биналарда, бай, зиннәтле сарайларда урнашкан. Бездә генә ул нишләптер митинглар заманы үтте дип, җәмгать оешмаларының ролен кечерәйтеп күрсәтергә маташу, аларны бер кысан бүлмәләреннән дә куу гадәте һаман яшәп килә. Истанбулда Казан татарлары җәмгыятенең үзенең зур бинасы бар. Төркиядә, гомумән, татарларга аерым мөнәсәбәт. Алар безне «шималь төреге» диләр дә элеккеге СССР туфрагында яшәгән бөтен татарларны Казан белән бәйлиләр. Анда Пенза да юк, Нижгар да юк, Төмән татары да юк, гафу, Уфа татары да юк. Шул бер сүз: Казан татары. Нишләп татарларга аерым урын икәнлеге аңлашыла булыр. Татар исеменә канат куеп, Төркиядә Йосыф Акчура, Садри Максуди, Рәшит Арат Рәхмәти, Гаяз Исхакый, Зәки Вәлиди, тагын да җәмгатьчелек белгән һәм белмәгән уннарча, уннарча исемнәр калка.

Истанбул университеты буйлап йөрибез. Менә Зәки Вәлиди кафедрасы, аның шәхси китапханәсе, менә ул утырып эшләгән өстәл. Менә Рәшит Арат Рәхмәти кафедрасы, шунда ук китапханәсе, менә ул утырып эшләгән өстәл. Әлеге кафедра бүлмәсендә хәзерге мөдир, профессор Серткая утыра, Рәшит Аратны илаһи бөеклектә күрүче Серткая.

Барысын да беләләр, ядкарьләрен саклыйлар. Шуннан соң үзеңнән-үзең уйлыйсың: кайда безнең Казан университетыннан Үзбәкстанга куылган Җәвад Алмазның кафедрасы, китапханәсе, өстәле? (Китапханәсе, шөкер, кайтты бугай. Мәрхүм үзе барыбер Казанга дип васыять итеп калдырган.) Кайда безнең Казан университетыннан Азәрбайҗанга куылган Үзбәк Акчура кафедрасы, китапханәсе, өстәле? Ул гаҗәеп кызыклы, тирән белемле галим иде. Кайда безнең Латыйф Җәләй кафедрасы, өстәле, урындыгы, китапханәсе? Кайда безнең шул ук Казан университетыннан куылган Шамил Мөхәммәдъяров кафедрасы, өстәле, урындыгы? (Әле бит ул, Аллаһыга шөкер, исән-сау диярләр. Соң, сау булгач, үтенеп, кире кайтарырга кирәк.) Фәннең һәртөрле техник һәм башка тармаклары буенча читкә тибәрелгән, куылган галимнәрнең исәбе-хисабы юк. Әле бүгенге көннәрдә дә күпмеләре бөтенләй дә чит илләргә китеп барды...

Истанбул кадәр Истанбулга килгәч, без элеккеге елларда шыпырт кына, Катанов китапханәсе... ул Төркиядә икән дип сөйләнелгән китапханәне дә күрәсе иде бит. Ләкин мин кем әле ул кадәр? Төркиядә мин бары тик бер татар баяны (хатыны). Шул әлеге алда сөйләнелгән бөекләребез аркасында ачылды да инде Катанов китапханәсе ишекләре минем алда. Гадәттә, анда беркем дә кертелми икән. Ә миңа исә күрергә, тотып карарга кирәк иде, татар тотып карамый ышанмый инде. Чынлап та, анда минем һәм күпчелегебезнең башы-зиһене колачламаслык байлык саклана икән. Бу белем чыганаклары үз вакытында Казанда булган бит дип уфтанудан башка чара юк инде безгә.

Шулай итеп, йөрим Истанбулда. Кибетләргә кергәләп, вак-төяк нәрсә алган буласың. Төрекчәне бераз сукалагач, тел чарларга тырышып, сатулашкан булып та кыланасың. Төрекләр мөкиббән китә, сораша башлый. «Басын, чалыш бәнемлә – әйдә, минем янга басып эшлә, дия башлый. Урысчалап тауарны мактап, рекламалап торырга чакыра. Чөнки Россиядән килеп, шундыйрак хезмәттә булучыларның исәбе-хисабы юк икән. Ләкин үз дәрәҗәңне белеп эш итәргә дә кирәк: « Тәшәккүр, икинҗи заман – рәхмәт, икенче бер вакытта», – дип китеп барасың.

Истанбулда йөрим, күп нәрсәләр күренә, төрле нәрсәләр хакында уйланыла, әмма минем уй-фикерләрем башкада. Иң мөһим уем – Гаяз Исхакый хакында. Тик төрекләр аның турында бигүк сөйләмиләр. Иң төп эшем итеп, аның каберен зиярәт итү дип хисаплап йөрим. Бөек Җиһүнең Әдернә капысы (капкасы) ягындагы зиратта җирләнгәнен беләм. Урамның кайсы тарафына карап китәсен дә беләм. Әмма үзең генә барып тапмый кайтсаң? Мине анда алып барырга Кадрия хоҗам вәгъдә итә итүен. Минем белән укучы яшь кызларыбыз мәсьәләгә алай ук җитди карый алмыйлар. Аларның Истанбулда укучы безнең яшьләр белән йөрисе җирләре дә күп шул. Төркиядә укуын тәмамлаган яшьләребез дә бар. Әмма әлегә берсенең дә илгә кайтуы ишетелми кебек. Төрле илләрдә эшкә калганнар икән дигән хәбәрләр йөри. Ләкин, барыбер, Төркиягә яисә башка бүтән илләргә барып укуга каршы сүз әйтергә кирәкмидер, укысыннар, күзләре ачылсын, киң дөньяга чыксын татар. Берсе кайтмаса, икенчесе кайтыр, иншаллаһ. Озаграк тоткарланганы да кайтыр, хикмәт бит чикләрнең ачык булуына гына бәйләнгән. Яшьләребезнең чит илләрдә белем алуына сабыр гына шатланып торыйк, сыктамыйк, еламыйк. (Дөресен әйткәндә, безнең Мәгариф министрлыгы, Төркиядә укучы һәрбер студентны исәптә тотып, алдан илдә урын әзерләп, чакырып, кайтарып торырга тиештер инде ул.) Еласак, безгә татарның 444 ел буе Россия шартларында йотылуына еларга кала, әмма елап кына эшне төзәтеп булмый, чарасын күрү ляземдер. Шулай да Төркиядә бер нәрсә күзгә ташлана. Татардан шунда

ук, улың бармы, кызың бармы, дип сорыйлар. Улы-кызы булса, өйләндерик, дигән тәкъдимнәр дә чыгарга мөмкин. Һич булмаса, үзең, бәлки, берәр төрек агаена кияүгә чыгарсың... Безнең белән барган Гүзәл дигән кызыбызны да аспирантурага (һәм... кияүгә) бик тә алып калмакчы иделәр, шөкер, кызыбыз өйдә, татарның әйбәт егетенә кияүгә чыкты.

Әйткәнемчә, миңа зиратка барырга юлдаш кирәк. Әмма төрекләр безне йөртмәделәр дип һич кенә дә әйтеп булмый. Ул Топ Капы, Долма Бакча – солтаннар сарайлары, берсеннән-берсе гүзәл мәчетләр дисеңме; Богазга – Босфорга чыгу, Өскүдар ягына кунакка барулар; төрек иҗтимагый үзәкләре белән танышу һ.б., һ.б. Театр, кинолар да калмады... Мине зиратка алып баручы да табылды. Саин Сәми Йауруҗук бәй иде ул. Саин – хөрмәтле дигән сүз. Чынлап та бик хөрмәтле кеше, аңа башкача эндәшмиләр дә. Әлеге дә баягы татарларны яратучы төрек. Горбачев заманы килеп, чикләр ачылгач, берүзе, күрер өчен, нәкъ менә Казанга килеп киткән икән. Билгеле, безнең мондагы хәлләргә шактый аптырап, «Татарстан» кунакханәсендәге әдәпсезлекләргә хәйран калып кайтып киткән. Миңа « әйе, кунакханәләр әлегә мактанырлык түгел, татарча түгел» дип ык-мык килүдән башка чара калмады.

Белмәдем бит, Әдернә капкасы ягы бик якында – биш-алты тукталыш арасы гына икән. Ә менә зират – юлның ике ягында да. Бездә бераз рәтлерәк каралган дип саналган зиратлар яшел паркка охшабрак торса, биредә зират – бер этаж биеклегендәге мәрмәр корылмалар, мәрмәр шәһәр кебегрәк икән. Менә ул атаклы Әдернә капысы мазары. Биредә күбрәк олы язучылар, олы сәнгатькәрләр һәм хәлле кешеләр җирләнгән бугай; гаилә-гаилә, буыннан буынга җыелган утарлыклар булып мәрмәр корылмалар күтәрелгән. Саин Сәми бәй, мин сезгә сюрприз ясыйм, дип, алга таба берничә адымнар ясаган идек... чып-чын Сөембикә манарасы каршына килеп туктадык. Сөембикә манарасының тәбәнәгрәк өй биеклегендәге макеты! Бу манара безнең Йосыф Акчураның кабер өсте. Исең китүдән тел шартлатып торасың, югыйсә елармын инде дип барган идем. Акчурадан уң тарафка таба биек, озын арка башына «Мәхмәт Акиф Эрсой мәйданы» дип язып куелган. (Мәхмәт Акиф Эрсой зур шагыйрь, җәмәгать эшлеклесе, Төркия җөмһүриятенең дәүләт гимны авторы.) Мәрмәр кирмән-корылмалар. Бу бөек шагыйрьнең тирәсендә башка атаклылар... Күп икән, күп атаклы төрек язучылары, кабер өсләре – сәнгать әсәре. Йосыф Акчура каберен күрү тәэсиреннән айнып булмаса да, күңелдә Гаяз Исхакый өстен тизрәк күрү теләге. Ә Саин Сәми бәй миңа һаман башка олы төрек язучыларының каберләрен күрсәтә. Минем түземсезләнүемне аңлап, белеп тора, шуңа күрә сүз аралаш «һемен-һемен» дип (хәзер бик тиз барып җитәбез максатка дигән сыманрак) аңлата. Әмма ни хикмәт, табып булмый бит әле Гаяз Исхакый каберен. Әнә инде безгә зират караучының тугыз белән ун яшьләр арасындагы кызы, угылы да «һемен-һемен» дип, йөгерә-йөгерә эзләшәләр. Күренеп тора, бу ике бала татар язучысының каберен табып биргәләгәннәр булыр. Әмма еш түгел, хәтерләре ялгышырлык озак заман үткән, ары-бире байтак йөгерделәр. Йосыф Акчурадан шактый арырак, түбәндәрәк җирдә табып бирделәр алар Гаяз Исхакый каберен. Номеры да бар: 10/89. Димәк ки, унынчы һәм туксан тугызынчы аллеялар кисешкән җирдә. Зуррак сандык кебегрәк бер урын. Кабер кырыйлары сандыктан биегрәк итеп мәрмәр белән каймаланган. Каберне эзләп йөргәндә әллә сизелмәгән дә, вак кына җиз иләктән иләп яңгыр ява икән ич. Күздән аккан яшькә яңгыр бөртекләре кушылып китә. Бервакыт, беренче мәртәбә Болгарга баргач та, капыл гына яңгыр ява башлаган иде, анда да күз яшенә яңгыр кушылды...

Йосыф Акчура кабере янында фотога төшкәндә, Сөембикә манарасының ае миннән әллә кайда өстә торды. Гаяз Исхакый янында фотога төшкәндә исә баш очына:

Тәңре рәхмәт әйләйә

Әдиб вә мөхәррир М.Аяз Исхакый Иделле

Идел-Урал төрекләренең кортылыш* хәрәкәте рәхбәре**

«Казан 1878 Анкара 1954» дип язылган такта миннән түбән булмасын өчен нык кына иелдем...

Миңа күп еллар читтә мөһаҗирлектә яшәгән безнең ватандашыбыз Минһаҗ Исмәгыйли белән сөйләшергә туры килгән иде. Ул Гаяз Исхакыйның соңгы сәгатьләре хакында болай сөйләде. Бөек әдип, авыр хәлдә ятканда, вакыт-вакыт күзен ачып: «Мин кайда? Мин кайда үләм? Идел-Уралда үләмме?» – дип сораган. Ә менә «Мөхәммәд Гаяз Исхакый. Тормышы һәм эшчәнлеге. Тууына 100 ел тулу уңаеннан» дип аталган һәм кызы, кияве, якыннары, дуслары тарафыннан 1979 елда Анкарада төрек телендә чыгарылган китапта әдипнең кызы Сәгадәт Чагатай-Исхакый әтисенең соңгы көннәре, сәгатьләре хакында язганда әлеге сорауны «Мин кайда, урынымдамы?» дигән мәгънәдә яза. Бер яктан, безнең Сәгадәт ханым сүзенә ышанмау гамәлебез булмастыр да кебек, ләкин бер нәрсә бар. Ул елларда хәтта Төркиядә дә «Мин кайда үләм? Идел-Уралдамы?» дигән сүзне әйтү һәм аны язып чыгу куркыныч бер хәл булган икән. Сталинның кулы анда да бик шәп озаерга мөмкин булган. Советлар басымында бик күп мәчетләр ябылган булган. Сталин режимының кәсафәте Төркиядә дә төрле яклап сизелгән. Бүгенге көндә дә шуның бер чагылышы булып, марксизм-ленинизм әдәбиятының массакүләм масштабта төрек теленә тәрҗемә ителгән тиражлары белән кибетләр һәм урам тулган иде. Анда коммунистларның террорлык хәрәкәтләре тукталганы да юк икән. Бер генә мисал. Йавуз Бүләнт Бакиләр исемле танылган төрек язучысы һәм шагыйре үзенең 1992 елда бишенче мәртәбә басылган (беренче басмасы 1986 елда – элеккеге СССРда үзгәртеп кору заманының икенче елында дөнья күргән)

«Төркестан, Төркестан» дигән китабында түбәндәгечә яза: «Бервакыт, 1976 елда Анкарада «Нисар» («Көй») журналы мөдиренә «Төркестан» исемле шигыремне укып күрсәттем дә «бастырып чыгарасызмы?» дип сорадым. Мөдир, ике кулын җәеп, эндәшми торды. «Ошамадымы әллә?» дигәч: «Ошады. Әмма Мәскәү яклы коммунистлар идарәмдә бомба шартлатсалар, нишләрмен?» – дип җавап бирде.

Икенче яктан, укучыда Гаяз Исхакый Төркиядә әллә бик начар торганмы, әллә төрекләр аңа карата начар мөгамәләдә булганмы дигән фикер дә туарга мөмкин. Иң әүвәле шуны әйтергә кирәк, Төркия Гаяз Исхакыйны исән-сау саклап калган һәм яшәткән ил. Әгәр төрекләр аны Йосыф Акчураларга караганда азрак белә икән, аның хикмәте – Г.Исхакыйның төрекләрдә аерым бер билгеле эштә эшләмәвендә. Һәм аның башка татар эмигрантлары кебек турыдан-туры төрекләргә аерым хезмәткә кермәве – анысы инде бөтенләй башка мәсьәлә. Кем әйтмешли, пәри башка, җен башка. Моны бары тик Гаяз Исхакыйның үз халкының язмышына иксез-чиксез дәрәҗәдә бирелгәнлеге белән генә аңлатып була. Ул үзенең эшчәнлеген «Идел-Урал» җәмгыятен җитәкләп барудан тыш күз алдына да китермәгән. Эмиграциядәге бөтен гомерен татар халкының азатлык көрәшенә багышлап, үзенең туган халкы өчен җан атып, озак заманнар билгесезлектә калып, үзенең хезмәтенең, иҗатының халкына кайчан барып ирешәсен белмәгән хәлдә, шуңа тирән ышанып, иҗат итеп, көрәшеп, батырлыкның да батырлыгын күрсәткән изге бөегебез ул безнең!

...Истанбул күгеннән вак яңгыр сибәли. Минем уйда төрекләргә олы рәхмәт хисе һәм... ничек кенә булса да, шул олугыбызның, затлыбызның – әдип вә көрәшче Гаяз Исхакыйның җәсәден туган җиргә – Идел яры өстенә кайтарып җирләү теләге. Аңлатып бирсәң, моны халкыбыз да, төрекләр дә дөрес аңлаячак. Шулкадәр дә Туган җир, Туган ил дип ут йоткан кешенең Туган җир җылысын тоеп ятарга тулы хакы бар...

*1997*

**Литературно-художественное издание**

**Рахимова Бике**
**(Файзуллина Миннебике Рахматулловна)**

ВЕЧНАЯ ПЕЧАЛЬ

Казань. Татарское книжное издательство. 2009

На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

**Рәхимова Бикә**
**(Фәйзуллина Миңлебикә Рәхмәтулла кызы)**

БАКЫЙ САГЫШ

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
**http://tatkniga.ru e-mail: tki@tatkniga.ru**